PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2020 АВГУСТ № 8

# СӨЕМБИКӘ

Ләйсән Фәйзуллина
театр – тормышымдагы
БЕР ЧОР ГЫНА

кемне көйләргә
ЯШЬ ӘТИГӘ
игътибар җитми

УЧАКТА –
кунак сые
«Казан-кебаб»

Сания
ШЕВЧЕНКО:
«Мин туган телемә гашыйк!»

PRESSA

75 ЖИҢҮ! 1945–2020

# Хәтер – мәңгелек...

Хәтер – мәңгелек...

Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас...

Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.



Әбиемнең абыйсы Айтуганов Ягъсуб Кәрам улы 1921 елда хәзерге Актаныш районы Иске Бикчәнтәй авылында туган. 1929 елда алар гаиләләре белән хәзерге Әгерҗе районы Нарат авылына күченә. Ягъсуб абый 1930 елда мәктәпкә барганда инде укый-яза белгән. Шуңа күрә аны беренче чиректән соң 2 сыйныфка күчергәннәр. Мәктәптә укыганда кыска хикәяләр, шигырьләр яза, кайберләрен район газетасына да биреп бастыра. Кечкенәдән үк шаян, зирәк бала була. 1936 елның көзендә, мәктәпне тәмамлагач, укытучы булырга хыялланып Казанга китә. Әмма укытучылар әзерли торган уку йортына инде документлар кабул итү тәгәлләнгән була, шунлыктан ул сәүдә техникумына укырга керә. Әмма хыялына тугры булып кала Ягъсуб абый! Үзе экономист булып эшкә урнашса да, укытучылар әзерләү курсларын тәмамлый, Казан педагогика институтының физика-математика факультетына читтән торып укырга керә. Аны тәмамлагач, районга кайтып, Үтәгән мәктәбендә укытучы булып эшли башлый. Тальян гармунда уйный, спектакль-концертларда катнаша, матур итеп җырлый. 1942 елда абыебызны сугышка алалар. Сугыштан нибары ике хаты килгән, без аларны әле дә кадерләп саклыйбыз. Шушы ук елның ноябрендә хәрби комиссариат аның «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүен, медальнең тапшырылмавын хәбәр иткән.

Декабрь азагында Ягъсуб абыйның 1942 елның 25 августында Орел өлкәсенең Передель авылы янында батырларча һәлак булуы турында кайгылы хәбәр килгән... Әбием аның каберен гомере буе эзләде.

2012 елда – һәлак булуына 70 ел узгач кына тапты: Калуга өлкәсе Уколица авылында Туганнар каберлегенә 2963 сугышчы белән бергә җирләнгән ул. Ягъсуб абыебыз дөньядан бик яшьли китсә дә, зур батырлык белән лаеклы эз калдыра алган.

Нәргиз АЙТУГАНОВА.
Казан.

Обязательно все графы заполнять полностью.

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

Фамилия, имя и отчество Айтуганов Ягсуб Карамович

Военное звание Рядовой

Должность, часть Стрелок 2-ой стр. роты 1-го О.С.Б. 257 отд. стр. Бригады

Представляется к медали «За отвагу»

1. Год рождения 1921 2. Национальность Татарин

3. С какого времени состоит в Красной Армии с III-1942 4. Партийность чл. ВЛКСМ

5. Участие в боях (где и когда) с 11-16.08.42 в районе дер. Передел Запад. фр.

Имеет ли ранения и контузии Не имеет

Чем ранее награжден (за какие отличия) Ранее не награждался

Каким РВК призван Краснобаровским Р.В.К., Татарской А.ССР

Постоянный домашний адрес представляемого к награждению или его семьи)

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

За время боев с 11-16.08.42 ходил несколько раз в контр-атаку и в общей сложности уничтожил 12 гитлеровцев.

Командир 1 ОСБ Капитан

Военком Политрук

# *Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!*



© «Сөембикә» 2019




Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

**Баш мөхәррир**
Л. Н. Маликова

**Редколлегия:**
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77

**Җитәкче урынбасары** 222-09-78
Рәмзия Кашапова
**Баш мөхәррир урынбасары** 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
**Җаваплы сәркатип**
Лариса Маликова
**Әдәби мөхәррир**
Эльмира Закирова
**Сайт мөхәррирләре:**
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.


**Тышлыкта:**
Сания Шевченко
Фото: Юлия Вохминцева

**Верстка:**
Резеда Галиуллина
**Бүлек мөхәррирләре:**
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Фотокорреспондент**
Анна Арахамия
**Гамәли хезмәткәрләр:**
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды:
24.07.2020 ел.
Заказ А-1937
Тираж 4827

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»




ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
**www.syuyumbike.ru**
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

PRESSA



# 30 АВГУСТ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ

Гамил АФЗАЛ

**_Татарстан таңнары_**

*Дулкынланып тирбәлә җыр:*
*Сандугач кунмас инде.*
*Ямьле булса да торган җир,*
*Туган җир булмас инде.*

*Сакта торам ил чигендә,*
*Басмаган җир калмады.*
*Кайда йөрсәм дә күңелдә*
*Татарстан таңнары.*

*Таныш чәчәкләр җыясың,*
*Болынга чыгасың да.*
*Әллә ничек үз тоясың*
*Аен да, кояшын да.*

*Кошлары сайрый тирәктә,*
*Сыгылып үсә таллары.*
*Кайда йөрсәм дә йөрәктә*
*Татарстан таңнары.*

*Зәңгәр тәрәзә каршында*
*Үрмәле гөлләр үсә.*
*Чишмә буе тау астында*
*Фирүзә җилләр исә.*

*Кызара җәйләр кичендә*
*Алмаларның аллары.*
*Кайда йөрсәм дә исемдә*
*Татарстан таңнары.*

*Тургай тавышларында да,*
*Елга камышларында,*
*Җанга якын моңнары бар*
*Сөю сагышларында.*

*Басуларда эшләп үсә*
*Кызларның уңганнары.*
*Сагындырып искә төшә*
*Татарстан таңнары.*

Фото: Анна Арахамия

# Безнең тышлыкта

«Туган телен белмәгән кешедә аны өйрәнергә теләк тудыру, аңын «уяту», милли тамырларын искә төшерү дә бик мөһим. Рухи ихтыяҗ кирәк!»




26 Татар мәгарифе министры
Гөлнур Сафиуллина


## Заман һәм без




6 Иң матур җыр – иртәгә
Эльмира Закирова

20 Әтисез буламы соң?!
Раилә Хәялиева





24 Ирек яратам...
Чулпан Галиәхмәтова






16 Җиргә күктән дә карарга кирәк
Ландыш Әбүдәрова

## Татар дөньясы




30 Шушма буе талларыннан
Лилия Гәрәева

## Мәдәни тормыш



36 Гомерлек сер
Роза Мулланурова



44 Аккош оча...
Флүрә Дәминова

## Яшәеш



52 Артистлана белмәгәнмен



54 Без белгән һәм белмәгән Башкортстан
Зәлия Ахунова

## Хуҗабикә



60 «Казан-кебаб»



**Без аны күбрәк телевизор аша Дәүләт Советы сессияләрендә күрәбез. Болгарны һәм Зөя утрау-шәһәрчеген яңадан торгызуда алны-ялны белми эшләгән көннәрен искә төшерәбез. Бүген полилингваль мәктәпләр проекты белән янып йөрүләре күз алдыбызда. Ул колачлаган өлкәләр бихисап! Депутатлык эше, социаль мәсьәләләрне хәл итү, ветераннар белән эш, мәгариф, сәламәтлек саклау, хәйриячелек, мәдәният, тарих, мирас... Белемле, эрудицияле, зыялы-зәвыклы, төгәл, тыйнак, эшлекле, кече күңелле, һәрнәрсәне алдан күрә белгән... Нинди генә җаваплы эшләргә алынса да, сынмыйсыгылмый торган Татьяна Петровна ЛАРИОНОВА ул. Егәрләгән вазыйфалары да бит ни җитте генә түгел! Президент ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Возрождение–Яңарыш» фондының башкарма директоры, Дәүләт Советындагы хатын-кыз депутатларның «Мәрхәмәт–Милосердие» берләшмәсе җитәкчесе... Республиканың сәяси-иҗтимагый тормышында кайнаган тынгысыз җитәкче җаваплы эшләргә алынганда кемнәргә таяна, кемнәрнең эш стилен үзенә үрнәк итеп ала икән? «Сөембикә» укучыларына ул хатын-кыз буларакниләр сөйли, нинди киңәшләр бирә ала? Татьяна Петровна сөйләгәннәрдән үсмер кыз Таняны да күрәбез, университет аудиторияләрендә дә утырабыз, комсомол тормышын да сагынабыз. Дәүләт Советы сессияләре. Халыкны социаль яклау юнәлешендә эшләү өчен медицина институтында укып икенче югары белем алу. Борынгы Болгарның, Зөя утрау-шәһәрчегенең әкияттәгедәй танымаслык булып үзгәрүе. Яңа эшләр, яңа бурычлар... Хыяллар... Ул сөйләгәннәр тыңлап туймас матур хикәя кебек.**



Эльмира ЗАКИРОВА

# ИҢ МАТУР ҖЫР – ИРТӘГӘ

### *Без – ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегендә!*

*«Җитәкче булу – димәк, алдан күрә белү».* Минтимер Шәймиевнең шул сүзләрен гел искә төшерәм. 2010 елда «Возрождение–Яңарыш» фондын булдырганда без әле ниләр эшлисебезне дә күз алдына китерә алмый идек. Ә ул нәрсәләр эшләргә, ничек эшләргә икәнен алдан ук белде! Президент постын калдырып, тарихи һәм мәдәни мирасыбызны торгызуга юнәлтелгән Фондны оештырды ул. Ислам кабул ителгән изге Болгар җирләрен, православиенең энҗе бөртегенә тиң Зөя утрау-шәһәрчеген торгызу кебек колачлы проектка алынды. Татарстан өчен генә түгел, бөтен Россия өчен зур тарихи вакыйга, бөтен җәмгыять өчен эталон булды ул.

*Минтимер Шәрипович 2010 елда ук инде Болгарны һәм Зөя утрау-шәһәрчеген ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни мирасы объектлары исемлегендә күрде!..* Һәм шулай булды да! Россиядә әле беркемнең шулай эшләгәне юк иде! Сигез ел эчендә (ә ул бик аз вакыт!) шул эшләрне башкарып чыгу – бу инде таң калырлык гамәл! Минтимер Шәрипович куйган бурычлар, бу чор өчен төзегән үзара хезмәттәшлек

алгоритмы сокланырлык. Эшебез нәтиҗәләре белән республикабыз, илебез, бөтен дөнья горурлана. Үз тарихыбызны торгызуга министрлыклар һәм ведомстволар, район хакимиятләре, бар халык кушылды. Безнең башлангычны өйрәнергә, тәҗрибә тупларга бик күп төбәкләрдән килделәр. Үзләрендәге тарихи әһәмиятле объектларны аларның да ЮНЕСКО исемлегенә кертәсе килә иде. Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы бездә бу темага махсус семинар уздырды.

***Болгар һәм Зөя турында сәгатьләр буе сөйли алыр идем...*** Атна саен барып йөрергә туры килде аларга. Бу нормага, кагыйдәгә әйләнде. Эш дәверендә бик кызыклы, талантлы кешеләр белән аралаштым. Төзүчеләр, реставраторлар, проектчылар, рәссамнар... Экспертлар һәм белгечләрне чит илләрдән дә китерттек. Инфраструктура өчен төзелгән корылмалар шулай ук уникаль. Зөядәге археологик агач музееn гына алыгыз. Суда төзелгән музей бит! Ә Болгардагы мәчет, академия, кунакханә, елга вокзалы... Алар шушы тарихи урынның инфраструктурасы өчен кирәк иде. Һәр корылма йөзек кашы булырлык!

***Ак мәчет манаралары Мәдинә мәчетендәге кебек!*** Теләгән һәр кеше Мәдинәгә үк бара да алмый бит. Ә шуны хәтерләткән манаралар Болгарда менә күз алдында. Монысы да Минтимер Шәрипович идеясе. Мәчетнең ак төстә булырга тиешлеген дә ул әйтте. Чөнки ак төс – чисталык, пакьлек, ышаныч символы, безнең халкыбыз гомер-гомергә ак төсне яратты, диде ул. Бу җирләрнең мөселман руханиларыныкы булуын әйтеп, биредә уку класслары ачарга тәкъдим итте. Аннары инде ул академиягә үк әйләнде. Су, фонтаннар янында урнашып, сурәте суда чагылса, мәчет тагын да матуррак күренәсен архитекторларыбыз уйлап тапты. Андагы ландшафтны күрсәгез! Үзе бер сәнгать бу! Иртә яздан биредә ак лаләләр каршылый, бераздан алмагачлар ак чәчәккә күмелә, җәй буе ясминнәр ап-ак булып утыра... Һәм, ниһаять, ак розалар. Ак мәчет янында ак чәчәкләр генә үсә!

***Елга вокзалы яр җимерелүдән саклар өчен төзелде.*** Һәр корылманың кызыклы тарихы бар. Иделнең биек урынында яр җимерелүдән саклый торган корылма – причал төзергә кирәк була башта. «Бу җирләргә беренче тапкыр аяк басучылар тарихка күз салсын иң элек», – ди Минтимер Шәрипович. Күпләр хәзер аны, елга вокзалыннан бигрәк, Болгар цивилизациясе музее буларак белә. Ул Россия Федерациясенең иң яхшы музейлары рәтендә.

***Ибн Фадлан бирегә дөягә атланып килгән!*** Болгарда менә ни өчен дөя фермасы да бар. Археологлар исә дөя сөякләрен дә тапканнар. Бер очраклы әйбер дә юк биредә. Безнең дөрес юлдан баруыбызны, тарихны дөрес яктыртуыбызны халыкара экспертлар да таныды. Чит ил туристлары күпләп килә хәзер. Ә алар, гадәттә, дөньякүләм кыйммәткә ия урыннарга сайлап кына киләләр.

***Татарстан мондый югарылыкка ничек ирешә алды?*** Республикабызга килгән кунаклар еш кына уңышларыбызның сере белән шулай кызыксына. Миңа калса, сере бик гади: руслар һәм татарлар, төрле диндәге кешеләр үзара килешеп, бер-берсен ихтирам итеп дус яши.

***Татарстанда хәйриячелек буенча шактый эшләр башкардык.*** Республика советы оештырып, авыру, мохтаҗ кешеләргә, инвалидларга ярдәм итә башладык. Колясkалы инвалидларга яхшы коляскалар табу проблема иде. Ә без барлык инвалидларны да дөнья базарында билгеле «Meyra» немец фирмасы коляскалары белән тәэмин итәргә булдык. Минтимер Шәрипович эшне үзебездән башларга тәкъдим итте. Ул вакыттагы Премьер-министр Рөстәм Нургалиевич икенче көнне үк беренчеләрдән булып 10 коляска сатып алды. Аның урынбасарлары һәркайсы – 5, министрлар 3 әр коляска алды. Менә шундый шәхси үрнәк! Аннан инде район башлыклары, предприятие җитәкчеләре күтәреп алды! «Мәктәпкә җыенырга булыш!» акциясе дә бик игелекле гамәл булды. Шушы эшләрдән соң Президентыбыз мине «Возрождение–Яңарыш» фондының булачак башкарма директоры итеп күрде. Борчылыбрак та кабул иттем бу хәбәрне. Чөнки Фонд ул – финанс та, мәдәният тә, тарих та, төзелеш тә... Минем өчен бөтенләй яңа эш, яңа бурычлар, яңа кешеләр... Фонд үзе дә «Возрождение–Яңарыш» дип атала. Ә мин аны үзем өчен җәя эчендә «Созидание» (*Яңаны иҗат итү* – авт.) дип язып куйдым.

## Мин кабат мәктәп дөньясына әйләнеп кайттым...

***Балалар бакчасында ук нәниләр өч телдә сөйләшә алсын. Укучылар рус һәм татар телләрен дә, инглиз телен дә бердәй дәрәҗәдә камил үзләштерсен.*** Фонд тагын яңа проектка алынды: полилингваль комплекслар төзибез. Быел яңа уку елында беренче ике



■ Без башкаларга юл ачтык. Минтимер Шәрипович кына шулай булдыра ала! Иллегә якын тарихи һәйкәлне реставрацияләү, ике дистәләп яңа тарихи-мәдәни корылмалар төзү, 28 уникаль музей булдыру, Болгар һәм Зөяне туристлык, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы белән тәэмин итү...

комплекс ачыла: Беренче Казан комплексы һәм Алабуга комплексы. Алар структуралары буенча аерыла. Чөнки шәһәрләр дә, шартлар да төрле. Алабугада эшне ике балалар бакчасыннан башлыйбыз. Нәниләр өч телдә сөйләшергә өйрәнеп, туптуры 1224 урынга исәпләнгән полилингваль мәктәпкә укырга киләчәк. Казан комплексы куәтле ресурс үзәге итеп планлаштырыла. Балаларның рус һәм татар телләрен бердәй яратулары һәм тирән үзләштерүләре, инглиз телендә иркен аралаша алулары бик мөһим безнең өчен! Көндәшлеккә сәләтле яшьләр үстерү максатын куйдык. Өч тел белү – ул норма, стандарт кына әле. Факультатив рәвештә башка телләрне өйрәтү дә каралган. Инглиз телен тирәнтен өйрәтүче 165 нче мәктәп башлангыч мәктәп итеп реконструкцияләнде. Читтән килеп укучылар интернатта яшәячәк. Җылы күчү юлы аркылы ул мәктәп белән тоташа. Комплекс өчен укытучыларны Казан федераль университеты әзерли. Якын киләчәктә андый комплекслар алты булачак: Чаллыда, Түбән Камада, Әлмәттә төзеләчәк алар. Әнә шундый мәктәп моделе ике дәүләт телле теләсә кайсы регион өчен үрнәк булырлык. Ә Россиядә андый төбәкләр – 22. Бүген әнә шундый проект белән яшибез. Бу комплекслар – киләчәгебез, иртәгәсе көнебез. Әлеге проектның перспективалары искиткеч!

Президентыбыз Рөстәм Нургалиевичның тырышлыгы, Фондка күрсәткән ярдәме, зур игътибары турында аерым сөйләрлек. «Возрождение–Яңарыш» фондының полилингваль белем бирү проекты белән шөгыльләнә башлавы минем өчен икеләтә шатлык булды. 11 ел мәктәптә эшләгән кеше бит мин!

***Мәктәп директорым Роза Гарифовна Хәсәнова беренче остазым иде.*** Үзе инде арабыздан киткән булса да, эш-гамәлләремне аныкы белән чагыштырып карыйм, аңа карап тигезләнергә тырышам. Сигезенчедә укыганда мине мәктәпнең комсомол секретаре итеп сайладылар. Ә икенче елны инде мине, тугызынчыда укучы кызыйны, мәктәпнең планеркасына чакыралар иде. Анда мәктәп директоры, өч завуч, парт-оешма секретаре, профком председателе һәм мин булабыз. Завучларның берсе – минем рус теле укытучым, партоешма секретаре физикадан укыта, ә профком председателе минем класс җитәкчем иде. Ул елларда вокал-инструменталь ансамбльләр бик популяр иде. Мәктәпнең ансамбле булсын дип хыялланып йөрибез. Тимер-томыр тапшырып акча эшләмәкче булабыз. Кая! Ул тиеннәрне дистә еллар җыеп та бер гитара алалмыйсың! Тагын киңәшкә директорга йөгерәм. «Уйлагыз! Синең комсомол оешмаң бар бит! Үзем дә уйлармын», – ди. Берничә көннән сорый бу, трамвай тукталышындагы белдерүләрне карыйсыңмы, ди. Караштырдым... Көчек сату, фатир сатып алу турында гына язып элгәннәр. «Начар укыйсың, – ди Роза Гарифовна. – Мәктәп янында гына трамвай-троллейбуслар идарәсе бар, аларга дворник кирәк! Безнең никадәр әби-бабайлар бар бит, шуларны урнаштырыгыз да, график буенча класслар кар көрәсен, территорияне чистартсын. Менә сезгә акча, менә сезгә оркестр!» Аның каравы, алган инструментларыбызны инде күз карасыдай сакладык.

***Укытучы булу – балачак хыялым иде.*** Университетның тарих факультетына имтиханнар тапшырдым: ике «дүрт»ле, ике «биш»ле. Әмма конкурстан уза алмадым. Өстенлек армиядән кайткан егетләргә бирелде. Ә үзем укыган 82 нче мәктәптә пионервожатый урыны бар, һәм директорыбыз аны минем өчен саклап калган иде. Кичке бүлеккә укырга кердем. Чөнки гаиләбез бик тыйнак яшәде. Әнием Зоя Петровна күп балалы гаиләдә үскән, сугыш чоры баласы, еш авырый. Әтием Петр Иванович – гади шофер. Ике бала үстек, мин зурысы идем. Бернинди блат та, танышлар да юк. Шуңа күрә әни гел: «Бар да үзеңнән генә тора. Сиңа укырга кирәк. Һәм бик яхшы укырга! Тормышың үз кулларыңда!» – дия иде. Кичке якта укып, яраткан мәктәбемдә эшләдем, уку белән эшне бик рәхәтләнеп алып бара алдым.

Пионервожатый булып эшләгәндә мәктәпкә бер генә данәдә «Воспитание школьников» дигән кызыклы журнал килә иде. Директорбыз беренче булып танышып чыга да укырга миңа бирә. Аннары озаклап сөйләшеп утырабыз. Ул һәрвакыт: «Мәктәп өчен нинди яңалык таптың? Үзең өчен нәрсәләр ачтың?» – дип кызыксына. Шулкадәр күп сораулар бирә, укып кына калмыйча, анализлый да белергә, кайбер әйберләрне үзебезнең эштә дә кулланырга кирәк була. Икенче курста укыганда инде мин 4 нче «А» һәм «Б» классларында тарих дәресләре алып бара башладым. Ә Роза Гарифовна 4 нче «В»га үзе керә. Дәресне ничек үткәрергә, планны ничек төзергә, һәр баланы ничек тыңлый белергә... Барысына өйрәтте ул!

***Дүртенче курста... оештыру эшләре буенча завуч идем!*** Бөтен Казан өчен гайре табигый хәл булды ул! Роза Гарифовна РОНОны да, ГОРОНОны да минем эшли алуыма ышандырган тәки!

***Аның киңәшләрен алтын кагыйдәләргә тиңлим.*** Мин партия райкомында эшли башлаганда, директорыбыз инде пенсиядә иде. Аңа республика ветераннар советын җитәкләргә тәкъдим иттем. Анда да ул күп нәрсәгә күзләремне ачты. «Таня, син нәрсә, әллә күрмисеңме? Аларның бит пенсия акчасы бик аз! Инвалидлык буенча ник ел саен документ-кәгазь тутыртып, китертеп җәфалыйлар? Аларның аягы үсеп чыкмый бит кабат!» – дип, җан әрнүе белән әйтә иде.

Үзем Социаль яклау идарәсендә эшли башлагач, ялынып, аны беренче тернәкләндерү үзәгенә завуч итеп чакырдым. Тәҗрибәле укытучым анда да акыллы киңәшләре белән бүлеште. «Таня, ул балаларга хезмәт күрсәтүче персонал кирәкми. Авызларына каптырып, артларыннан җыеп, без аларны мөстәкыйль тормышка әзерли алмыйбыз. Аларга киләчәктә үзләрен генә яшәргә өйрәтә торган күнекмәләрне бирергә кирәк», – диде. Гаҗәеп талантлы укытучы, шәп психолог иде ул. Үзен һәрвакыт пионер директоры дип йөрттеләр. Хәер, укытучыларымның һәркайсы зур шәхес иде!

### *Яраткан хатын, килен, әни, дәү әни*

***Бар кешегә дә эләкмидер андый бәхет!***

Тугызынчы класста укыганда безгә күрше 44 нче мәктәпнекеләр дә килеп кушылды. Егетләр дә шактый. Шулар арасында Ларионов Евгений да бар. Менә шул бер күрүдә гашыйк булган миңа! Без бер-беребезне мәктәптән үк яхшы беләбез. Мәктәп һәрвакыт кешеләрне танырга өйрәтә, минемчә. Күрәм: ул бик җаваплы, тәртипле, аңа таянырга була. Исеме үк намуслы, турылыклы дигән мәгънәне аңлата. Бик ихлас, сабыр кеше. Хатынының кайчак тәүлекләр буе эшләвенә, өйдә кайнар аш та булмавына башка ирләр риза да булмас иде.

Искиткеч гаилә җанлы ул. Монысы инде тәрбиядән киләдер, аларда гаилә традицияләре көчле, әти-әнисе бик акыллы кешеләр иде. Мине үз кызлары кебек кабул иттеләр. Мин аларның яраткан, һәрчак көтеп алына торган кадерле кешесе булдым.

***Тиз генә әзерли торган ризыклар әйбәт килеп чыга минем.*** Кыздырган бәрәңгемне и мактыйлар инде. Бәйрәм табынына һәрчак үзем ясаган салатларны куям. «Беркем дә синеке кебек тәмле «Селедка под шубой» ясамый», – ди кызым. Яшь чакта тортлар пешерергә ярата идем. Талонга алынган каймак, он, шикәрне бергә туглап пешерәсең дә, телеңне йотарлык «Каймаклы торт» әзер!

***Кызыбыз Юля бик креатив!*** Әтисе ягына охшап (Евгений КАИ тәмамлады), математика юнәлешеннән китте: финанс-икътисад институтын тәмамлады. Башта социаль учреждениеләрдә баш бухгалтер булып эшләде, аннары банкка күчте. Ләкин барыбер дә иҗади характеры үзенеке итте: ТИСБИда укып, психолог дипломы алгач, күңеленә хуш килгән эштә – балалар үзәгендә эшли хәзер.

***Оныгым тугач, әби булуымны бөтен дөньяга ишеттерәсем килде!*** Полинабызны беренче тапкыр кулыма алгач, бәхеттән нишләргә белмәдем! Бәби белән машинада кайтып барганда, юлда Сбербанкта туктап, сөенечтән «Возрождение–Яңарыш» фондына кечкенә оныгыбыз Соловьева Полина исеменнән акча күчердек. Белмим, шулай эшләү дөрес булгандырмы, ләкин мин Полинкабызның бу тормышка игелекле гамәлләр белән аяк басуын теләдем. Үскәч, үзе дә шундый изге эшләр башкарыр әле ул! Минтимер Шәриповичка да бу хакта әйттем. Шундый ошады аңа! Соңрак, минем исемемне әйтмичә генә: «Хәтта яңа туган сабыйлар да хәйриячелеккә кушыла, ничек шатланмыйсың моңа!» – диде.

Озакламый Полинабызга ун яшь тула. 6 нчы гимназиядә укый ул. Укытучылары искиткеч! Үскәч кем булыр, әйтә алмыйм. Компьютерлар белән дә кызыксына, берара ветеринар булам дип йөрде. Яраткан мәчесе Джесси әнә дүрт песи баласы алып кайткан. Күңелле бездә!



■ Мин бик бәхетле кеше! Аңа кияүгә чыгуым да язмыш булгандыр. Янәшәмдә башка кеше булса, тормышымда бу югарылыкка күтәрелә алмас идем. Шушы эшемне яратканымны, хатын-кыз буларак шуның белән бәхетле икәнемне аңлый ул, мине ничек бар – шулай кабул итә.

## АНЫҢ ГОМЕРЛЕК КАГЫЙДӘЛӘРЕ

■ **Кызлар, исегездә тотыгыз! Ничә яшьтә булуына карамастан, хатын-кызның прическасы һәрвакыт матур, аяк киеме теләсә кайсы очрак өчен уңайлы булырга тиеш!** Мәктәптәге йорт эшләре укытучыбыз, үзен гел карап, матур булып йөрергә ярата торган Нонна Андреевна, безгә әнә шул кагыйдәне бик яхшы сеңдерде.

■ **«Баскыч юарга гына чыксаң да, син инде урамда – халат кимә, күлмәк ки! Кеше арасында матур йөр...»** Әнинең шул сүзләрен еш искә төшерәм. Без ул чакта Әмәт бистәсендә яши идек.

■ **Диплом эше итеп... үземә пальто тектем!** Мин дипломлы тегүче бит. Өч ел буена Менжинский исемендәге клубта эшләүче курсларга йөрдем. Киемгә аерым мөнәсәбәтем шуннан киләдер. Мәктәптә эшли башлагач, бар күлмәкләремне үзем тегә идем. Әтигә дә күлмәкләр тегеп кидердем. Әтине бик ятаткнга, алар аеруча матур килеп чыга иде.

■ **Син бу көнне барысыннан да яхшырак күренергә тиеш!** Монысы – Идел буе партия райкомының беренче секретаре Ольга Ермакова киңәшләреннән. Аны без җитәкче хатын-кыз эталоны итеп кабул итә идек... Ул әзерләгән беренче пленум мәгариф темасына багышланды, ә мин ул чакта инструктор идем. Кирәкле барлык материалларны тупладым. Пленум өчен бөтенесе әзер кебек. «Ә син нинди киемнән буласың?» – дип сорап куймасынмы! «Бу – синең пленумың, синең темаң. Бу көнне син барысыннан да яхшырак, матуррак күренергә тиеш!» – диде.

■ **Онытма, киемеңә карап каршы алалар, акылыңа карап озаталар, дияргә ярата иде әни.** Һәм шуннан үзең өчен нәтиҗәләр ясыйсың инде. Матур ясалган чәч белән генә ерак китә алмыйсың әле. Башыңда да нидер булырга тиеш.

■ **Киңәшмәдә йә берәр чарада чыгыш ясарга җыенсам, күп нәрсәне алдан ук ачыкларга, күп укырга тырышам.** Бу очракта Минтимер Шәрипович эталон, әлбәттә! Ул Президент чагында Президент ярдәмчесе булып эшли башлагач, аның игътибарлылыгына, һәр нәрсәдән хәбәрдар булуына таң калдым.

■ **Иң матур җырым җырланмаган әле!** Бу – тормыш девизым минем. Бар җырларым да шәп. Мәктәптә эшләгәндә дә, социаль яклау өлкәсендәге елларымда да, Президент ярдәмчесе булганда да, «Возрождение–Яңарыш» фондында, Дәүләт Советында яңа идеяләр белән янганда да... һәр чорның үз җыры булды. Лирика да, күңелле ноталар да, моң түгелеп торганнары да, күз яшьләре дә... Ләкин иң матур җыр алда әле. Ул нинди, әйтә алмыйм, ләкин ул алда, иртәгәсе көнебездә!

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020


Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да… Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

# АК ХАЛАТТАН УЗГАН ЮЛ
















































Фото: Анна Арахамия

**Равилә ДАИШЕВА: Гадәти тормышта мин дә куркам. Әмма ак халатымны киюгә ул хис юкка чыга. Үземне сәхнәдәге артист кебек сизәм – монда бары үзеңә генә ышана аласың. Әнинең нәсихәтен дә беркайчан истән чыгармадым – «Авыру кеше урынына үзеңне куеп кара».**

1975 ел. Казан. Шәһәр читендә – бүгенге ДРКБ (Республика балалар клиник хастаханәсе) урнашкан урында ак каеннар шаулый. Зур төзелеш башланырга әле бераз вакыт бар. Ә менә булачак хастаханәнең баш табибы Евгений Васильевич Карпухин инде кадрлар туплау белән мәшгуль. Сәмәркәнд медицина институтын тәмамлап кайткан педиатрны монда биш куллап каршы алалар. Яшь табиб инде Термез шәһәрендә иң тәҗрибәле оториноларингологларның берсе Мария Чубаровадан әлеге белгечлекнең күп серләренә төшенергә дә өлгергән. Казанда белемен күтәреп, балалар оториноларингологы таныклыгына ия була.

ДРКБ 1977 елда беренче кечкенә пациентларын кабул итә. Колак-борын-тамак авырулары бүлегендә – медицина фәннәре кандидаты, КДМИның ЛОР авырулар кафедрасы ассистенты Рудольф Андреевич Нечипуренко кул астында эшли башлый Россиянең сәламәтлек саклау отличнигы, югары категорияле табиб-оториноларинголог, фониатр Равилә Даишева. Санитар авиация белән республикабызның иң ерак почмакларына кадәр барып, сабыйларны дәвалаган яшь табибәнең даны тиз тарала. «Бөтен өметебез сездә», – дип, әти-әниләр аңа килә. Берсе бигрәк тә күңеленә кереп калган. «Өч-дүрт яшендәге бер малайны алып килделәр. Моңарчы куелган диагнозы – яман шеш. Ул елларда әле балалардагы яман шешләргә операцияне Мәскәүдә генә ясыйлар иде. Баланы карый башладым, чынлап та, онкологиягә охшаган. Әмма ныклабрак тикшерә башлагач, күрәм: шешнең структурасы ничектер бүтән, үлекле. Мамык белән акрын гына чистарта, үлектән аралый башладым. Беләсезме нәрсә тартып чыгардым? Губка кисәге! Ул инде яры белән капланган, кан тамырлары белән уратылган иде. Аны бит инде миңа кадәр ничә табиб караган, әнисе күпме күз яше түккән. Шул көнне үк балага дәва биреп, стационарга салдык. Бер атнадан ул инде шатлыктан сикергәли-сикергәли өенә кайтып китте». 1986 елда ординатура тәмамлап, хезмәт юлын МВД сырхауханәсендә олылар табибы булып дәвам иткәндә дә «балачакта мине дәвалаган идегез», дип, хәзер үз балаларын җитәкләп килүчеләр күпме була әле!

Равилә Һидиятовна Даишева – «Азат хатын»ның 1980 елгы февраль саны тышлыгы героинясы. Табибәнең иң гадәти бер көне була ул февраль иртәсе. Сменага утызар баланы кабул итеп өлгерәсе бар. Ни өчен фотога төшерүләрен сорарга да вакыт тими кала. Термиздан әнисе – үзе дә табибә-гинеколог Тәслимә ханым Әбүбәкерова шалтырата: «Үзең күрдеңме соң, сине бит журналда чыгарганнар!» – ди.

Ә бит Равиләнең юлы бөтенләй башкача башлана – музыка мәктәбен тәмамлаган кызны имтиханнарсыз гына музыка училищесына кабул итәләр. Әмма кызның гына күңеле канәгать түгел. Хәер, бернәрсә дә очраклы түгел. 1987 елны Киевта О. С. Коломийченко исемендәге отоларингология институтын тәмамлап, фониатр белгечлеге алуында музыканы тоя-ишетә белүе мөһим роль уйный. 2010 елдан Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында җырчыларның тавыш ярыларын дәвалый Равилә Һидиятовна. Бик сирәк белгечләрнең берсе ул.

Лилия ГӘРӘЕВА

PRESSA



**1984 елда Асия тормышында бик зур вакыйга була – аңа фатир бирәләр. 26 яшеңдә үз фатирың ишекләрен ачып кер әле! Алай гына да түгел – проектын үзең сызган йорттан! Бу ике шатлыкның, мөгаен, икенчесе беренчесенә караганда зуррак та булгандыр... («Җаваплылыгы да!» – дип өсти ул үзе!) Инженер буларак, аның иң беренче эш тәҗрибәсе «Оргсинтез» заводы белән бәйле. Аннан С. Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концертлар залын, Казан Милли мәдәният үзәген төзүдә катнаша. Казан дәүләт университетының актлар, спорт заллары корпусларында да хезмәтенең эзләре калган. Бу исемлек бик озын... Әлеге биналарның берсе диварына да аның исеме язылмаган: яннарыннан узганда, аларга карап, керткән өлеше турында үзе генә искә төшерә. Ә бу язманы укыгач – сез дә искә төшерерсез. Республиканы, Казаныбызны төзекләндерү, шәһәрбистәләренең йөзен заманча үзгәртү, бизәү белән беррәттән аның бу тормышта тагын бер бик зур максаты бар: туган авылын – Яшел Үзән районының Югары Ширдан авылын яшәтү, авылдашы, бөек мәгърифәтче Каюм Насыйриның туган җирен замандашларына таныту, исемен мәңгеләштерүгә үз өлешен кертү.**
**«Акведук» проект компаниясе директоры, Татарстанның атказанган төзүчесе Асия Наил кызы ГОБӘЙДУЛЛИНА белән ул узган юл, шәһәрдә ул төзегән биналар, ул кылган игелекле гамәлләр турында сөйләшәбез.**

# «ИРТӘГӘ СОҢ БУЛУЫ БАР...»



Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

**– Асия Наилевна, минемчә, сезнең уңышларның башы мәктәп елларыннан ук башлана: сабый гына килеш, алдыгызга зур максатлар куеп, калага укырга юл алуыгыздан...**

– Безнең Югары Ширданда сигезьеллык мәктәпне башлангыч итеп үзгәрткәч, укуны дәвам итәр өчен ике юл калды. Берсе – бездән җиде чакрым ераклыктагы Олы Ачасыр урта мәктәбенә йөреп уку, икенчесе – Казандагы 10 нчы интернат-мәктәптә белем алу. Әнием: «Үзең сайла, кызым», – диде. Мин шәһәр мәктәбендә укуны әйбәтрәк булыр дип таптым. Бу вакытта миңа унбер яшь. Казанга баручы поезд безнең авыл яныннан иртәнге сәгать өчтә үтә. Шулай итеп, ул елны сентябрьдән башлап, һәр дүшәмбе сәгать ике тулганчы торып, букчамны күтәреп, поездга чыга башладым. Дөрес, ялгыз түгел идем. Казанның Шамил Усманов урамында урнашкан, хәзер 2 нче гимназия дип үзгәртелгән интернат-мәктәптә, төрлебез төрле сыйныфларда булсак та, байтак авылдашларым белән бергә укыдым.

**1975 елда мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Казан төзүче-инженерлар институтына укырга кергәнсез. Кыз баланы нигә нәкъ менә төзелеш өлкәсе үзенә тартты икән?**

– Сере бик гади: абыем Рушан шунда белем ала иде. Күреп торам – яратып укый. Бер көнне аңардан: «Институтыгызда кызлар да бармы?» – дип сорадым. «Студентларның яртысы кызлар», – дип җавап бирде ул. Әнием: «Табиб булырсың дип уйлаган идем», – дисә дә, теләгемә каршы төшмәде. Без, аның дүрт баласы, бүгенге көндә ирешкән уңышларыбыз, тәрбиябез, тормышка карашыбыз – барысы белән дә әниебез Саниягә бурычлы. Әнинең йогынтысы зур булды: барыбыз да югары белем алдык. Чит җирләргә китмичә, Казанда төпләнергә, бер-беребезгә булышып яшәргә, авылны беркайчан да онытмаска, туган йортны ташламаска тиешлекне дә күңелләргә ул сеңдерде. «Балаларым теләсә кайда яшәп интекмәсен», – дип, булган акчасына Казанда йорт сатып алды. Мәктәпне тәмамлагач, мин дә шунда яши башладым. Студент елларында дүрт туган бергә тордык. Безнең өйдә коммунизм хөкем сөрде: булган акчабызны бер урынга куябыз, кирәк кеше шуннан алып тота иде. Ул чакта олы абыебыз Рәшит белән апам Наилә инде А. Е. Арбузов исемендәге институтта фәнни хезмәткәрләр иде, Рушан абый белән мин – студентлар. Шимбә көнне барыбыз бергә авылга кузгалабыз. Анда әни көтә! Әнинең бөтен яшәү мәгънәсе без идек!

Без – фронтовик балалары. Кызганыч, әтиебез Наил кыска гомерле булды. Шуңадыр, бик ашыгып яши һәм күп эшкә өлгерә ул: Казан елга техникумында укый, рус теле һәм әдәбияты укыта, 1943 елның ноябрендә инде фронтка китә. 1945 елның февралендә Кенигсберг шәһәре өчен барган канкойгыч сугышларда каты яралана. Санитарлар аны очраклы рәвештә мәетләр арасыннан табып алалар... Сугышта булган бер ел да биш ай вакыт эчендә күрсәткән батырлыклары өчен әтиебез ике тапкыр «II дәрәҗә Дан ордены», «III дәрәҗә Дан ордены», «Кызыл Йолдыз» ордены, «Батырлык өчен», «Сугышчан казанышы өчен», «1941–1945 елларда Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә. Үзүзен аямый көрәшә! Госпитальдә дәваланып, туган авылыбызга әйләнеп кайткач, эшен дәвам итә: мәктәптә укыта, читтән торып Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый, мәктәп директоры вазыйфасын башкара. Ул елларда бөтен авыл халкы аңа тартыла: кемдер киңәш сорап килә, кемдер документ тутыртырга... Мәктәпне уңышлы тәмамлаган балаларны югары уку йортына әзерли, авыл активы белән эшли, төрле җыелышларда үтемле чыгышлар ясый... Авыл халкы боларны әле дә хәтерли. 1964 елның 20 июлендә гаиләбезгә генә түгел, бөтен авылга кара кайгы килә: йөрәге туктап, әтиебез су коенганда суга бата. Нибары 38 яшендә...

## Борынгы Римда, Грециядә су китертү җайланмалары акведук дип аталган.

**Асия Наилевна, сез бүген җитәкче-директор. Мондый зур дәрәҗәгә бер көндә генә ирешмиләр...**

– Институтны 1980 елда тәмамладым һәм юллама буенча «Главтатстрой» оешмасы карамагындагы 2 нче төзелеш трестына эшкә урнаштым. 1921 елда ук нигез салынган, зур уңышларга ирешкән, талантлы җитәкчеләре, алдынгы төзүчеләре белән даны еракка таралган дәрәҗәле оешма иде бу. Өч меңнән артык кеше



## Аларның проектлары буенча төзелгән биналар Казанда да, республикада да аз түгел.

генә эшли! Мине проектлар бүлегенә билгеләделәр. Безнең трестка шәһәр күләмендәге әһәмиятле, җаваплылыгы зур булган төзелеш объектлары бирелә иде, мин дә, инженер буларак, алардан читтә калмадым. Унсигез ел эчендә гади инженердан проектлау буенча баш белгечкә кадәр күтәрелдем. Беренче ун елымны сайлаган һөнәремә өйрәнү еллары дип атасак, икенче унъеллык туксанынчы елларга туры килде. Илдәге сәяси һәм икътисадый үзгәреш җилләре кешеләрнең уй-фикерләренә шактый йогынты ясады. Бер яктан, авыр вакытлар дип искә алсак та, нәкъ менә шул елларда яңа мөмкинлекләр ачылды. Мин дә яшем, тәҗрибәм буенча әйләнә-тирәдәге вәзгыятьне аңлап эш итәргә әзер идем.

**Димәк, «Акведук» оешмасы шул елларда дөньяга аваз салды?**

– Төзелеш өчен проектлар әзерләүче «Акведук» оешмасы 1998 елда барлыкка килде. Мин үзем проектлау буенча баш инженер вазыйфасын башкарам. Коллектив артык зур түгел, әмма барысы да талантлы, фикерле кешеләр. Менә шулай уңга-сулга тайпылмыйча, сайлаган һөнәребезгә тугры калып, бер-беребезне аңлап, тату гына эшлибез. Оешманың иң зур байлыгы, әйткәнемчә, бер-берсен ярты сүздән аңлый торган иҗади хезмәткәрләр, инженерлар, архитекторлар, конструкторлар... Безнең өлкә шактый катлаулы: ул тырышлык, тирән белем, тәҗрибә таләп итә. Җаваплылык сорый! Без гадидән – катлаулыга, кечкенәдән зурга таба атладык. 1998–2002 елларда ул вакыт өчен үтә дә кирәкле булган күп санлы автозаправка станцияләрен проектладык. Берничә генә катлы торак йортлар буенча заказлар алдык. Ә дәүләт заказы буенча башкарган беренче эшебез – Казан дәүләт ветеринария академиясенең дистә еллар төзелмичә тукталып торган тулай торак бинасын реконструкцияләү иде. Автозаправка станцияләре буенча туплаган тәҗрибәбез 2002 елдан башлап «Акос», «Фобос», «ТрансТехСервис» кебек оешмаларга зур автосалон проектларын ясау эшенә курыкмыйча алынырга булышлык итте. Берничә генә катлы торак йортлардан башлаган проектлар кыска вакыт эчендә егерме бишәр катлы торак йортларны төзү эшен документлаштыру дәрәҗәсенә күтәрелде, «Ава-Казань» кебек күп функцияле биналарны проектлауга юл ачылды. «Унистрой», «Бриз», «Завод «ЖБИ-3» кебек исемнәре мәгълүм заказчыларыбыз белән дә уртак тел табып яшибез. «Акведук» проектлау оешмасы барлыгын хәзер төзелеш эшләре белән шөгыльләнүче күпләр белә. Безнең белән санлашалар. Башкарган эшләребезнең соңгыларын гына санасак та, оешмабызның эшчәнлеген күз алдына китерү кыен булмас. Павлюхин урамында урнашкан «Возрождение», Карбышев урамындагы «Комсомолец» торак комплекслары, Гадел Кутуй урамындагы торак йортлар, автосалоннар, кунакханәләр... «Сытый папа» рестораннары, Щапов, Ульянов-Ленин, Маяковский урамнарында, тарихи урыннарда төзелгән торак йортлар... Күп алар!

**Инде сүзне тизрәк эш-гамәлләрегезнең бөтенләй башка юнәлештәгеләренә борасы килә. Сез – атаклы мәгърифәтче, галим Каюм Насыйриның якташы. Белүемчә, аның исемен мәңгеләштерү буенча байтак эшләр башкарасыз.**

– 2015 елда шырданлылар белән киңәшләшеп, «Каюм Насыйриның туган җирен яңартып торгызу» исемле фонд оештырдык. Алдыбызга авылыбызны уятып җибәрү, килгән-киткәннәргә да шул фикерне җиткерү; тирә-юньне карап, чистартып, төзекләндереп, заманча сулыш белән яши торган авыл дәрәҗәсенә күтәрү; тарихи истәлекләрне саклап калу бурычы куйдык. 2015 елдан 2025 елга кадәр эш планы төзедек, устав кабул иттек. Шырданны бүген торгызырга кирәк, иртәгә соң булуы бар, дигән максат куйдык. Эшне башлау өчен, әлбәттә, матди чыгымнар кирәк иде. «Акведук» аларның күбесен үз өстенә алды... Ничек кенә катлаулы булса да, әлегә шул планнан читкә тайпылганыбыз юк. Җиңүнең 70 еллыгына, Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган, шулай ук сугышта катнашкан барлык авылдашларыбызның исем-фамилияләрен барлап, гранит ташка уйдырып, монумент-һәйкәл куйдык. Чигенеш ясап әйтим, эшебез төгәлләнер алдыннан әтинең Краснокамск шәһәрендә яшәүче сеңлесе Флера апабыз шалтырата. «Фин сугышында вафат булган Габбаз абыйны исемлеккә керттегезме?» – ди. Ярый әле вакытында әйтте – өлгердек. Бабайның энесе Габбаз абыебыз монументка 300 нче кеше булып теркәлде.

Планнар зурдан иде безнең: 2016 елда авылыбыз чишмәләрен торгызу; 2016–2017 елларда – мәчет; 2018 елда «Чәй йорты» төзү, «Каюм коесы»н сафка бастыру; 2019 елда Сабантуй мәйданын тәртипкә китерү, XIV–XV гасырларга караган, халык хәтерендә «Изге зират» буларак сакланган каберлекләрнең тирә-юнен тотып алу, һәйкәл кую, төзекләндерү... Саналганнарның барысы да әйтелгән вакытта эшләнде! Быел безнең максат – музей-китапханә бинасын эшләтү. Ул ишекләрен быел ачар дип көтәбез.

**Каюм Насыйриның туган нигезендә аның үз куллары белән казыган коесын яңартуны да әйтеп уздыгыз. Тарихи кое!**

– «Каюм коесы», дөрестән дә, авылның тарихи урыннарының берсе һәм бик әһәмиятлесе. Коега 200 ел! Аны, чынлап та, Каюм Насыйри үз куллары белән казыган, ул аларның нәсел нигезе урынының ышанычлы сакчысы да. Килгән кунакларга бу турыда сөйләргә дә, күрсәтергә дә кирәк. Проектын ясап, коега бура иңдереп, яңарту эшләре тәмамланды дигәндә, башка тагын бер уй килде. Каюм Насыйри исән чагында кайтып йөргән йортның фоторәсемен, элмә такта ясап, репродукция рәвешендә күрсәтсәк, күз алдына китерү өчен күпкә

■ Каюм Насыйри гаҗәп дәрәҗәдә күпкырлы шәхес: мәгърифәтче, язучы, тәрҗемәче, галим, этнограф, картограф, каллиграф... Егерме дүрт ел буе өстәл календаре чыгару; мөселман дөньясында беренче буларак Коръән гыйбарәләре сүзлеге төзү; педагог-укытучы буларак дәреслекләр язу; татар халкының гореф-гадәтләре, йола-кануннары турында хисапсыз күп материал җыю... Шуның өстенә, су юлы ачылгач ук, беренче пароход белән кайтып, туган авылында балалар өчен Сабантуй үткәрү. Туган як табигатендәге үсемлекләрнең дәва үзлекләрен өйрәнеп, киләчәк буыннар өчен теркәп калдыру. Татар халкының милли ризыклары, аш-су әзерләү, ничек туклану турында бай мәгълүмат туплау... Галим Мәсгут Гайнетдин: «Аның популярлыгы белән ул чорда һичкем ярыша алмаган», дигән сүзләр язып калдырган.



отышлырак булачак бит. Шулай эшләдек тә. Аннан авылдашларыбызны, якташларыбызны, дәрәҗәле кунаклар, район вәкилләрен чакырып, «Каюм коесы»н ачу тантанасын үткәрдек.

**Асия Наилевна, ә бүген якташлары Каюм Насыйрины ни дәрәҗәдә белә?**

– Мин үзем аның турында сәгатьләр генә түгел, тәүлекләр буенча сөйләргә әзер! Әңгәмәдәшләрем, гадәттә, бүлдермичә тыңлыйлар! Нинди милләттән булуга карамастан. Каюм Насыйри хакында моңарчы бернәрсә дә белмәгәнбез икән диючеләр дә бар... Мин генә түгел, авылдашларымның барысы да Каюм Насыйриның бөек шәхес, авылыбызның символы булуы турында һәрвакыт горурланып сөйләргә әзер. Шәхес буларак, ул, әйе, уникаль күренеш. Аның даһилыгы табигый акылында, дөрес тәрбия алуында, шул ук вакытта бу – тирән белем, фәнгә мәхәббәт, тырышлык нәтиҗәсе дә. Без – аның якташлары, авылдашлары туктаусыз эзләнүдә. Булганнарына өстәп, аның турында яңа табылган бер генә мәгълүматны да югалтмаска, алтын бәрабәренә тиңләп сакларга тырышабыз.

Яңалык дигәннән, Каюм Насыйри гомере буе авылыннан аерылмый, теләкләренең соңгысы да Шырдан белән бәйле була. Авыл җыенында картлар икенче мәхәллә мәчете төзергә кирәк дигән карар кабул итәләр. Бу җыенда Каюм Насыйри да катнаша. Безнең Гыйбадулла бабай, җыен карары буенча, төзелешне баштан ахырына кадәр алып барырга тиеш була, ә матди ягын Габделкаюм Насыйров үз өстенә ала. Архив документларында шулай язылган.

Авылдагы менә шушындый изге эшләр турында кайсын ишетеп, кайсын күреп үстек. Болар бит барысы да, Каюм Насыйри әйтмешли, тәрбия дәресләре.

**Ә үз дәвамчыларыгызга сезнең бу эшләр кызыклымы, алар аның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнен аңлыймы?**

– Кызым Мәрьям университетта юриспруденция буенча икенче курста укый. Уку белән беррәттән яраткан хоббие белән дә шөгыльләнә – бию студиясен җитәкли. Шәһәр кызы ул... Әмма минем авыл белән шөгыльләнүемнең вакытлы мавыгу түгеллеген яхшы белә. Киләчәктә аның карашы да авылга борылыр дигән өмет белән яшим... Ә башка туганнарымның, мәсәлән, бертуган апамның үсеп килә торган оныклары авылны бик яраталар. «Каюм Насыйриның туган җирен яңартып торгызу» фондының быелгы планы буенча музей-китапханә төзелеп беткәч, ул аларның да, авылыбыздагы барлык балаларның да яраткан урыны булыр дип уйлыйбыз. Шуңа омтылабыз.

**Туган авылыгызда башкарган эшләрегез, бу унъеллык планга гына сыймыйча, читкә дә чыгып китә шикелле. Шырданда сез үткәргән «Мөнәҗәтләр бәйгесе» искә төште әле.**

– Мөнәҗәт әйтү – халык авыз иҗатының бик борынгыдан килә торган төре. Анда безнең тирән тарихыбыз да, гореф-гадәтләребез дә, йолаларыбыз да; ата-бабаларыбызның яшәү рәвеше, күңел халәте, чичәнлеге дә чагыла. Аллаһыга сыгыну, ялвару, мактау, фаҗига авазы да. Анда тәрбия, әхлак, туган тел моңы да... Ә иң мөһиме – мөнәҗәтләрне бүгенге көндә башкаручылар гына түгел, иҗат итүчеләр дә шактый икән. Бу эшкә яшьләребезнең күңел биреп кушылуы сөендерде. Конкурс тирә-юнь авылларны да, өлкәннәрне дә, яшьләрне дә җанландырып җибәрде. Безнең фонд авылыбызны җанландыру, торгынлыктан чыгару, кунакчыллыкны саклап калу өчен оештырылды да. Шуңа күрә, төзекләндерү эшләре белән рәттән, рухи байлык бирүче чараларны да онытмыйбыз. Ел саен Каюм Насыйриның туган көнендә уздырыла торган төрле очрашулар матур традициягә әйләнде. «Мөнәҗәтләр бәйгесе» дә Каюм бабабызга бер хөрмәт билгесе ул.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

# ҖИРГӘ КҮКТӘН ДӘ КАРАРГА КИРӘК

Язучы Марат КӘБИРОВның тормыш кагыйдәләре



Авылда йөрер өчен велосипед алдым. Күрәм: бу сәпитнең нәрсәседер дөрес түгел. Элеккесе җиңел, җайлы иде. Вәт. Нәрсәсе начар икән дип, элеккеге велосипедлар белән чагыштырып чыктым. Бөтенесе дә үз урынында. Мин генә бүтән. Вакыт агышы әнә шул инде ул. **БУ ДӨНЬЯДА БАР ДА ЭЛЕККЕЧӘ, ТИК БЕЗ ГЕНӘ БЕРАЗ БҮТӘНБЕЗ...** Мин менә шуларны уйлап зарланам да, инәй көлә: «Йөзгә җиткәч, илле яшең дә яшьлек булып күренер әле», – ди.

Көненә әллә ничәшәр тапкыр үземне даһи дип атыйм. Мин язам. Ниндидер уңышка ирешәм. Шул уңышларымны яратам. Чөнки аларга ирешкәнче әллә күпме ялгышлыклар ясыйм һәм үземне булдыксыз дип атыйм. **УҢЫШ БЕРКЕМГӘ ДӘ БЕРКАЙЧАН ДА ҖИҢЕЛ БИРЕЛМИ.**

**УҢЫШ – ЯРАТКАН КЫЗ, СӨЙГӘН ЯР КЕБЕК. АНЫ ЯУЛАРГА КИРӘК.** Мин яуларга тырышам. Яулыйм. Һәм шулар белән яшим. Кемнәр нинди генә гаеп тапса да, ә сез болай эшли алмыйсыз, дип җавап бирәм. Эчтән генә.

Мине танырга яки танымаска мөмкин. Тик мине башка беркем белән дә алыштырып булмый. Менә бу – критерий. Иҗат кешесе берәү булырга тиеш. Бердәнбер һәм кабатланмас. **МИН ЭШЛӘГӘННЕ ТАГЫН КЕМДЕР ЭШЛИ АЛА ИКӘН, МИН ЮК ДИГӘН СҮЗ.** Ә мин бар!

**МИЛЛИЛЕК ҖАНДА, ӘСӘРЛӘРДӘ БУЛА УЛ.** Менә мин әле авылда ятам. Монда миллилекне күпертүче юк. Татарча сөйләшеп, татарча яшәп ятабыз. «Милләтем, халкым» дип кычкырып йөргәнче, шул халык укырлык әсәрләр язарга кирәктер. Тик монысы күпкә авыррак.

**ЯЗУЧЫ ҮЗ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН ГЕНӘ ҖАВАПЛЫ БУЛА АЛАДЫР.** Авылыбызда бер әсәремне дә укымаган кешеләр бар. Ни дип әйтим инде... Алар – укымый торган кешеләр. Бернәрсә дә укымыйлар. Мине дә башкалар яраткан өчен генә яраталар. Шуларга карыйм да милләт исеменнән сүз сөйләргә хакым юклыгын аңлыйм. Президент бар, милли оешмалар бар. Менә алар җавап бирә милләт өчен. Язучы андый вәкаләткә ия түгел.

**МИНЕМ КЫЙБЛАМ – ИҖАТ.** Эшләдем бит инде мин. Татар әдәбиятының офыкларын киңәйтергә теләдем. Киңәйттем дә бугай. Күрүче, бәяләүче генә булмады. Бәлки, бәяли алыр өчен дә үз дәрәҗәмдәге укучылар булу кирәктер. Ләкин бер нәрсәне яхшы беләм: миннән соң татар әдәбияты аз гына бүтәнчәрәк булачак. Бәлки, ул тиз генә сизелмәс тә, тик ул үзгәрәчәк. Мин үзгәрткән кебек үзгәрәчәк. Һәрбер әйбәт язучы әдәбиятны үзгәртә. Бер генә дәлил китерә алам, миннән соң миннән дә начаррак яза алмаячаклар.

**ЯЗУЧЫ ҮЗ УКУЧЫСЫННАН ЗУРРАК, АЛДЫНГЫРАК, ӨСТЕНРӘК БУЛЫРГА ТИЕШ.** Беркем дә үзеннән дә мескенрәк кеше белән аралашырга теләми.

**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ УЛ ТАТАРЧА ЯЗЫЛА. ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТҮГЕЛ, Ә ТАТАРЧА.** Без аз гына артта калганрак кебек. Тик мин дөнья әдәбиятын күзәтәм дә алда булмавыбыз өчен сөенәм. Әдәбият бизнеска әйләнә. Үзенең зурлыгын җуя. Күпме бестселлерлар, хитлар, тагын әллә нәрсәләр бар. Мин аларны укыдым. Укымасам, күпкә бәхетлерәк булыр идем. Бездә әдәбият бизнес түгел. Бу әйбәт.

**ӘДӘБИЯТ БЕРКАЙЧАН ДА БИЗНЕСКА ӘЙЛӘНЕРГӘ ТИЕШ ТҮГЕЛ.** Ул кешенең уй-хыяллары, кичерешләре, хисләре белән уйный. Әгәр шуларны да бизнеска әйләндерәбез икән, кешелектән берни калмаячак. Без кешелеклелектән чыгабыз дигән сүз. Татар әдәбиятының иң төп үзенчәлеге, бәлки, кешелеклелеген саклап калудадыр. Шулай дип аңлыйсым килә.

**СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ДИГӘН ЧОРНЫ ЯРАТАМ.** Миңа ул гаделлек, кешелеклелек чоры кебек тоела. Бала чагымдай якын да, кадерле дә. Беләм инде, мин андый дәвердә мондый язучы була алмас идем. Йә төрмәгә утыртырлар иде, йә бүтән җиргә. Йә мин шул системаны зурлый торган гади бер каләм иясе булыр идем.

Акчага табына торган хәзерге дәверне кабул итеп бетерә алмыйм. Акчага табыну дөрес түгел. Кешелеклелек булырга тиеш. Кешеләр шуңа сыенсын. **КЕШЕЛӘР БЕЛӘН АКЧА ДА, ДАН ДА, МАЛ ДА ТҮГЕЛ, Ә КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК ИДАРӘ ИТӘРГӘ ТИЕШ**. Берәр вакыт шулай булыр әле ул.

Гомерем буена иректә язучы булдым. Үзем бер дәүләт шикелле. Мин шуның өчен бик күп өстенлекләрдән баш тарттым. **ДАН-ДӘРӘҖӘЛӘР, ТИТУЛЛАР АРТЫННАН ЧАПМАДЫМ. МИН ҮЗ СҮЗЕМНЕ ӘЙТТЕМ.** Үз дәрәҗәмне белдем. Үз сүзеңне әйтә алу өчен хокук кирәк. Ул хокукны үзең генә яулап алаласың, аны беркем бирми.

Хокукың булса, җаваплылык кирәк. Мин һәр сүзем өчен җавап бирәм. Ул сүзләр өчен мин бүген генә түгел, ә үлгәч тә җавап бирәчәкмен. Сүз әйтү ул – ирек. Ирек – җаваплылык. Ирексез кешеләр генә бер үк сүзләрне сөйли. Ә иректә кеше яңа сүз әйтә. Һәм ул үз сүзләре өчен җаваплы булырга тиеш.
**ҖАВАПЛЫЛЫК ЮК ИКӘН, КЕШЕНЕҢ ИРЕГЕ КУРКЫНЫЧКА ӘЙЛӘНӘ.**

Синең тулысынча азат булуың өчен илең, халкың азат булу кирәк. **ЯЗУЧЫ УЛ ҮЗ ХАЛКЫННАН ЕРАК КИТӘ АЛМЫЙ. КИТСӘ, БӨТЕНЛӘЙГӘ КИТӘ, ХАЛКЫНЫКЫ БУЛМЫЙ.** Китмәсә, шул халкы тирәсендә бөтерелә. Ә ирексез халык үз балаларының ирекле булуын күтәрә алмый. Син ирекле булырга мөмкинсең, тик моны гафу итсеннәр өчен бик күп тырышырга туры киләчәк.

**ИРЕК ӨЧЕН ТҮЛӘРГӘ КИРӘК. ИРЕКНЕ БҮЛӘК ИТМИЛӘР.** Теләнеп тә алып булмый. Аны яулап кына була. Ирексез халык балалары өчен шәхес ирке беркайчан да шәхси файдага эшләми. Язучыларның халык хадиме булу сәбәбе, бәлки, шундадыр да.
Очучы булырга теләгән идем. Баш очыннан самолетлар

Фото: Анна Арахамия

PRESSA



узса, әле дә дөньямны онытып карап калам. Артларыннан очып китәсем килә. Хәзер очалмам инде… Тик минем очканым бар. Парашют белән төшкәнем дә бар. **ӘЙБӘТ ЯЗУЧЫ БУЛУ ӨЧЕН ҖИРГӘ КҮКТӘН ДӘ КАРАРГА КИРӘК.** Яңадан тусам, мин барыбер очучы булыр идем.

**ҮЗЕМНЕ АВЫЛ МАЛАЕ ДИП УЙЛЫЙ ИДЕМ. ЮК ИКӘН, МИН ШӘҺӘР КЕШЕСЕ ИКӘН. АВЫЛНЫ ЯРАТА ТОРГАН ШӘҺӘР МАЛАЕ.** Менә быел апрельдән башлап үзебезнең Сеңрәндә мин (Башкортстанның Илеш районы). Җир һәр мизгелдә минем шәһәр кешесе икәнемне сиздерә – йә утырткан нәрсәм чыкмый, йә кырау сугып китә, йә чүп баса. Әле менә атна буе язып утырдым. Ындырга чыксам – коточкыч. Бәрәңгене корт ашап бетергән, чүп баскан… Монда язарга ярамый, чүп утарга кирәк. Тик авыл миңа ошый. Ул хәрәкәтләнергә мәҗбүр итә.

Хәзер бер нәрсәне ачык беләм: үзеңнеке булмаганнарга кызыгырга кирәкми. Ахыр чиктә, кешенең бер генә чын байлыгы бар, ул – аның гомере. Һәм башкаларның тормышын матурлау мөмкинлеге. **БЕЗ ҮЗ ГОМЕРЕБЕЗНЕ ЯШӘП, БАШКАЛАР ТОРМЫШЫН МАТУРЛАП КИТӘРГӘ ТИЕШБЕЗДЕР.**

**МИН КАЗАННЫ ЯРАТЫП КИЛДЕМ.** Яратып яшим. Нәрсә көткәнен беркадәр чамалап килдем. Менә бер буын язучылар үсеп чыга бит инде. Алар вузда бергә укыйлар, берберсенә таяныч булып, бер-берсен күтәреп яшиләр. Безнең яшьтәшләр алай була алмады. Без төрлебез төрле җирләрдән килгән кешеләр. Без бер-беребезгә таяныч түгел.

**КАЗАНГА КИЛГӘН ВАКЫТЫМДА МИН ЗӨЛФӘТ БЕЛӘН МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМНЕҢ ИСӘН БУЛУЫН ТЕЛӘР ИДЕМ.** Аралашасым килә иде алар белән. Татар шигъриятенең иң югары ноктасы шуларда сыман иде. Барып чыгалмады. Нияз Акмалны бик ярата идем. Фаил Шәфигуллинны… Алар да исән түгел иде. Ә Роберт Миңнуллин, якташым буларак, колачлап алды. Икебез дә Сөн малайлары бит.

Ркаил Зәйдулла белән Газинур Морат туганыма әйләнделәр. Абыйларым инде алар. Бүгенге татар әдәбиятының иң югары ноктасы шуларда бугай. Миңа шулай тоела. Мине иң якын дусты иткән Илфак Шиһапов. Ул таныштырып, иң кадерле кешемә һәм гомерлек баш мөхәрриремә әйләнгән Гөлнара Сабирова. Сеңелләрем кебек күргән Йолдыз, Луиза, Ландыш, Эльмиралар… Энеләрем кебек Рөстәм, Рузэл, Рифатлар… Равил Файзуллин, Марсель Галиев кебек өлкәннәрем… Иҗатымның һәр баскычын күзәтеп барган Дания Заһидуллина, Гөлия Гайнуллина… Җырларым аша мине таныткан Нәфкать, Хәния, Салават, Җәвит… Казанга килеп төшкәндә яңгыр сибәләп тора, күгендә болыт иде. Әнә шул болытларны таратучы дустым Ратмир Әхияров… И, барысын да исемләп санап та бетерерлек түгел икән. Казан миңа шулар кебек күренә. **МЕНӘ ШУШЫ ТАЛАНТЛАРНЫҢ БАРЫСЫН ДА БЕРГӘ ТУПЛАСАҢ, ДӨНЬЯНЫҢ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ҖИРЕНДӘ КАЗАН ТӨЗЕП БУЛЫР ИДЕ.**

Казан кешеләре миңа ошый. Иҗат даирәсен әйтәм инде. Мин үзем яраткан, үземне яраткан кешеләр белән генә аралашам. Шуңа Казан кешеләре бик әйбәт булып тоела. Тик барыбызга да хас булган бер нәрсә бар: без кешеләрне күрә белмибез. «Кем узар»дан үзебезне, үзебезнекен күрсәтергә атлыгабыз. Алай булмый ул. Сине кемдер күрсен өчен башкаларны да күрергә кирәк. Сине күрсеннәр өчен генә дә түгел. **БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ КҮРӘ БЕЛМИБЕЗ ИКӘН, БЕЗ ЯЛГЫЗ КАЛАЧАКБЫЗ.**

Ялгызлыкта дөреслек юк. Вакытлыча ялгызлык ул – минем стихия. Ялгызым гына урманда йөрергә, балыкка төшеп утырырга яратам. Болар – мин теләп алган ялгызлык. Хәтта ялгызлык та түгел ул, берүзең калу. Ә тормышта ялгыз калырга теләмәс идем. Мин гаилә кешесе. Хатын, балалар белән берәр көн сөйләшми торсам да эчем поша башлый. Мин үземне ялгыз итеп күз алдына да китерә алмыйм. Бик яхшы дусларым бар. Алардан башка кем инде мин? **КЕШЕ ЯЛГЫЗЛЫК ӨЧЕН ЯРАТЫЛМАГАН.**

**МИН ЯЗАМ, ИҖАТТА ҮЗ ДӨНЬЯМНЫ ТУДЫРАМ. АНДА МИН ЯЛГЫЗ. БЕРДӘНБЕР.** Аллаһ шикеллерәк инде. Бу рәхәт ялгызлык. Ничек кенә әле! Беләм инде Аллаһ түгеллегемне. Тик мин монда нәрсә телим шуны эшли алам. Бу – үзем теләп алган ялгызлыгым. Мин үзем теләп алмаган ялгызлыктан куркам.

Үземне яхшы беләм дип уйлыйм. Тик мин шулай уйлыйм гына. Чынлыкта, кеше үзенең әйбәт якларын белергә мөмкиндер. Ә начар якларын күршеләре беләдер. Яки дошманнары. Тик барысы да ялгышадыр. Чынлыкта кеше ул җиһан шикелле, аны айкап чыгу, тулысынча белү өчен бер гомер генә җитмидер. Мин үземне дә, башкаларны да яхшы белә алмыйм. **ҺӘР КЕШЕ – БЕРДӘНБЕР.**

Әти үлгәндә яшь ярымлык кына булганмын, аны хәтерләмим. Ул чакта әле әти авылында – Чуракайда яшәгәнбез. Ул бик чибәр кеше булган. Миндә чибәрлек булмады. **СӨЙКЕМЛЕ СӨЯГЕМ БУЛДЫ, ШУҢА ЧИБӘРЛЕГЕМ БУЛМАСА ДА ЯРАТТЫЛАР.** Әтием Рафаил ихлас кеше булган. «Ыштансыз» дип көлә инде әни. Миннән дә көлә. «Шул тиклем әтиең сыңары булырсың икән. Соңгы ыштаныңны салып бирергә әзерсең», – ди. Ярый. Булсын. Ә чынлап уйласаң, мине шул ихласлыгым өчен яраттылар. Әнием Әнүзәдән сабырлык алдым. Салкын канлы кеше ул. Мин дә салкын канлы һәм сабыр булырга омтылдым. Омтылдым гына, гел алай килеп чыкмады.

Юмор ул – безнең үз-үзебезне саклау коралы. Бу илдә юморсыз булмый. Барысын да чынга алып яшәсәң, йөрәгең тотып үләргә мөмкинсең. Үземнең бөтен барлыгыма юмор аша карыйм. Мактанчыграк кеше кебек күренәмдер. Тик ул мактанулар да – юмор аша. Ирония белән. **ӘГӘР СИН ҮЗЕҢНЕ ЗУР ДИП УЙЛАУДАН ҮЗЕҢ КӨЛӘ АЛМЫЙСЫҢ ИКӘН, ҮЗЕҢНЕ ЗУР ДИП УЙЛАМАСКА ТИЕШСЕҢ.**

Ландыш ӘБҮДӘРОВА әзерләде.

Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru »



# «СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫ – ТЕЛЕГРАМ КАНАЛДА!

## ҖЫЛЫ, ИХЛАС, САМИМИ! КИРӘКЛЕ!



**КЫЗЫКЛЫ ХӘБӘРЛӘР:** «Абитовлар гаиләсендә бәйрәм! Яраткан җырчыларыбыз Гөлсирин Абдуллина белән Азат Абитовларның өйләнешүләренә бер ел! Беренче ел – иң авыры, диләр. Бер-береңне, холкыңны сыныйсың. Юл куярга, гафу итәргә өйрәнәсең. Гафу сорарга. Бер-береңә өчен җаваплы булырга. Мөнәсәбәтләр әле җайлаша, хисләр кабат сынала гына. Менә ни өчен аны ситсы туй диләр. Гөлсирин белән Азат шушы балдай татлы, әмма шактый катлаулы чорны уздылар менә».

**ФИКЕРЛӘР:** «Хатын-кызларның һәммәсе дә чибәр инде ул – каләм тотканы да, көрәк тотканы да, ат иярендә гаскәр белән идарә иткәне дә... Шулай бит? Табигать тарафыннан ныклык, үҗәтлек, психиканың сыгылмалы булуы безгә туганда ук бирелә. Ә бүгенге заманда әлеге сыйфатлар – иң кирәклеләре...» (Шагыйрә Гөлүсә Батталова)

**АУДИОӘҢГӘМӘЛӘР:** «Мәхәббәтнең барлыгы-юклыгы бер елдан соң гына аңлашыла. Ә аңа кадәр – гашыйк булу, өрфия кебек хисләр... Бер ел эчендә менә шулар сынала. Йә ул мәхәббәткә әйләнә, йә бу кешедән алҗып туктыйсың. Ә мин өч ай очраштым да кияүгә дә чыктым. Билгеле, бернәрсәне аңламый калганмын...» «Серләшик» подкастында Зәмирә Рәҗәпова-Куприянова белән серләшәбез.

**ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР:** «Кара карлыган ачы икән, беренчедән, сортына игътибар итәргә кирәк – кайбер сортларның җимешләре ачырак тәмдә була. Икенчедән, карлыган кояшлы һәм иркен урынны ярата: күләгәдә үскән куакның җимешләрендә шикәр җитәрлек күләмдә туплана алмый. Өченчедән, дым җитәрлек булмаса да карлыган ачы җимешләр бирә. Карлыган баллырак булсын дисәгез, крахмаллы ашламалар кулланып карарга мөмкин. Моның өчен гап-гади бәрәңге кабыгы да ярый».

БЕРГӘ БУЛЫЙК!
БЕЗНЕҢ КАНАЛГА КУШЫЛЫГЫЗ!

БЕЗНЕ УКЫГЫЗ
Сайтта: **www.syuyumbike.ru**
Канал Telegram: **t.me/suumbike**
ВКонтактеда: **vk.com/suumbike**
Фейсбукта: **www.facebook.com/syuyumbike**
Инстаграмда: **www.instagram.com/suyumbike_journal**

РЕКЛАМА 16+




**«Бала тугач, иремне алыштырып куйгандай булды, икәү генә яшәгәндә ул андый түгел иде!» Күпме хатын-кыз бу турыда ачынып сөйли, дус кызына зарлана, интернетта җавап эзли һәм авыр йөк итеп күңелендә йөртә. Үзгәрә-ә-ә, кызлар, бала тугач, ирләр үзгәрә икән ул!..**

# ӘТИСЕЗ БУЛАМЫ СОҢ?!



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

«Юк! – диде таныш психологым. – Ялгышасың! Ирләр үзгәрми! Бала тапкан хатын-кыз үзе үзгәрә, шуңа күрә мөнәсәбәтләр катлаулана. Гормоннар, депрессия, талчыгу, фигураның без теләгәнчә булмавы, йокысызлык...»

Менә сиңа кирәк булса, дидем дә... Бу сүзләрдә хаклык та бар түгелме соң, кызлар?!

Танышларыбыз Рафаэль белән Наилә өйләрендә сабый тавышы яңгырасын өчен ничә ел хастаханә сукмагын таптадылар, нинди генә табибларның ишеген шакымадылар. Зарыгып бала көттеләр! Беркөнне Рафаэльдән смс-хәбәр килде: «Әти-әни булырга җыенабыз! Шыпырт кына шатланыгыз, күз тимәсен!» И сөендек бу хәбәргә, балагыз була, дип, үзебезгә әйттеләрмени?! Аларга инде ике балабызны ияртеп кунакка барудан да, очрашканда балалар хакында сөйләшүдән дә уңайсызланмый башладык. Үзләре дә шундый бәхетле, нурлы иде! Әйе, иде...

Уллары тугач, дүрт-биш айдан соң Рафаэльне бик күңелсез килеш очраттык. «Наиләнең бөтен вакыты балага китә, мин хәзер икенче бүлмәдә йоклыйм, – диде ул. – Сездә дә шулай булдымы?» «Булды инде, бездә дә төрле хәлләр булды, балалар җиңел генә үсми, иң мөһиме – исән булсыннар», – дип юаткалап та, «Сиңа Наилә төнлә тынычлап йокларга мөмкинлек биргән икән әле», – дип шаярткалап та озатып калдык «балтасы суга төшкән» яшь әтине.

Бу очрашудан соң ике айлап вакыт уздымы икән, ирем яңа хәбәр җиткерде, Рафаэль әнисендә куна башлаган, өенә сирәк кайта, ди... Ничек? Бу сүзләр әле кайчан гына бер нәни почык борын турында хыялланган, бала туса, бәхетебез түгәрәкләнер иде, безгә башка бер ни дә кирәкми дип йөргән гаилә турындамы соң?! Түзмәдем, Наиләнең үзенә шалтыраттым.

– Баланы бит мин таптым! Ул бер авырлык та күрмәде! Төннәрен уянып бала ашатам, юам, җыям, үтүклим! – дип, телефонга ярсыды яшь әни. – Ә ул үзенә игътибар җитмәүдә мине гаепли! Әни булу җиңел бирелмәде, үзең беләсең!..

## Бала алып кайтуыбызны теләгән ирем әти ролен кабул итәргә әзер түгел булып чыкты.

Ир белән хатынның үпкә хисенә күмелгән, бергә төзегән дөнья икегә бүленгән, бала белән әнинең – «без»гә, ир кешенең «син»гә әйләнгән мәле иде бу...

Бүген бик четерекле бер мәсьәлә – бала тугач, яшь әтинең гаиләдән читләшүе хакында сөйләшүгә чакырам, кызлар. Бу күренеш күпләрне читләтеп узмагандыр дип уйлыйм.

Тормыш законы шундый: туйдан соң яшь парлар бала турында хыялланып яши башлый. Әмма гаилә ишәйгәннән соң, көндәлек мәшәкатьләр, авырлыклар, тәрбия мәсьәләсенә төрле караш яшь әти белән яшь әни өчен зур сынауга әйләнә. Бу сынауга алдан берәү дә әзерләми аларны, барысы да үзе хәл ителер кебек тоела. (Безгә гаилә мәктәпләре кирәк! Кызларны – әни, егетләрне әти булырга өйрәтү генә түгел, бала тугач ир һәм хатын мөнәсәбәтләрен җайлау турында күбрәк сөйләргә иде яшьләргә!) Соңгы вакытта бала тапканнан соң хатын-кызларда була торган депрессия турында күп сөйләнә. Инде менә яңа статус алган – яшь әти булган кешегә дә игътибар бирергә вакыт җиткәндер, шәт!

– Үземнең әти кеше икәнен тирәнтен аңлап кабул итү өчен миңа ярты ел вакыт кирәк булды, – ди Айрат. – Бала тудыру йортыннан чыкканда күңелем тулы рәхмәт хисләре генә иде. Өйгә кайткач, хатыным гел бала янында булды. Миңа игътибар аз дип, бераз үпкәләп йөрдем дә үземне кулга алдым. Улымны мин тәрбияләмәсәм кем тәрбияләр?!

Айрат белән дә килешми мөмкин түгел. Әти инстинктының ир кешедә соңрак кабынуы табигый хәл. Без, әниләр, бала белән тугыз ай алдан аралаша башлыйбыз. Беренче тибенүләре, үзен сиздерүләре, йөрәк тибеше... Әти кеше бу бәхет төргәген бала тудыру йортыннан чыкканда гына кулына ала бит, беренче тапкыр аны шунда күрә. Спектакльләр караганда, китаплар укыганда игътибар иткәнегез бардыр, татар хатын-кызлары элек-электән ирләренә «әткәсе», «әттәсе» дип эндәшкән, «атагыз» дип сөйләшкән. Халкыбызның бу зирәклеген без дә кулланырга тиештер, мөгаен, үзен җаваплы хис итсен өчен, ир кешегә «әтисе» яки «әтиебез» дип эндәшә башлау көчле зат өчен бер ярдәм, гаилә өчен матур гадәт булыр иде!

Бала тугач ир-атларның үзләрен кирәксез дип санап, гаиләдән ерагаюларын яхшырак аңларга тырышып гаилә психологлары белән дә аралаштым, җаваплар, киңәшләр объектив булсын өчен, ир-ат психологларга да мөрәҗәгать иттем. Белгечләрнең бер уртак фикере минем өчен зур яңалык булды. Бала туганнан соң Җир күчәре әнә шул оҗмах исе килеп торган нәни төргәк тирәсендә әйләнә башлый. Дәү әти, дәү әниләр дә гел бәләкәч турында гына сораша, бар сөйләшү биләүсәләр, шешә, подгузниклар турында... Менә шул чорда ир кешенең балачак яралары, үпкәләре белән балалыгы (психологлар аны «внутренний ребенок» дип атый) уяна икән. Өйдәгеләрнең игътибары башка галәмгә юнәлгән мизгелдә ул үзенә дәваны читтән табарга тырыша, өйдәгеләр аның ачуын чыгара, күңелен төшерә. Хатынының нәкъ шул мизгелдә үзеннән ярдәм өмет итүен күз алдына да китерми икән ул. Гаиләдәге аңлашылмаучанлыклар ир кешенең «балалыгына» наз һәм йомшаклык җитмәгәндә туа. Һәм бу күренеш «хатын» булудан туктап, батырларча «әни» ролен кабул итәргә омтылган хатын-кызның моны абайларга вакыты да, көче дә калмаган чорда барлыкка килә.

«Кызыбыз тугач, ирем белән бик еш әйткәләшә башладык. Ул, ачудан, миңа булышудан баш тартты. Бала тәрбияләү буенча да төрле фикердә идек. Балага бер яшь тулгач аерылыштык. Аның хәзер башка хатын-кызы бар. Ә мин гаиләмне саклап кала алмавыма үкенәм...» – дип хисләре белән бүлешә ялгыз бала үстерүче Айсылу.

Мондый вакытта яшь гаиләгә кем ярдәм итә ала? Әлбәттә, беренче чиратта, дәү әни белән дәү әтинең роле зур. Якын туганнарга да мөрәҗәгать итәргә була. Бер-береңне тәнкыйтьли башлаганчы, кем беләндер бүлешергә, сөйләшергә, ярдәм сорарга, гаиләне саклап калырга тырышырга кирәк!

Уңайсыз буса да, тагын бер әйбер турында сөйләшик әле, кызлар. Баласы тугач, ирен башка караватта йокларга күчерүчеләр бармы арагызда ? Бала үз янында йоклаганда уңайлы, әлбәттә, имезәсең дә, иреннән агып төшкән җылы сөт тамчысын сөртеп алып, изрәп йокыга таласың. Ә аның хәле ничек икән? Күрше бүлмәдәге караватка ялгыз кереп ятучыны әйтәм? Хатын бала белән мәш килгәндә болай да икенче планга күчкән ир-атка төнлә дә бергә булудан мәхрүм калу... Тел төбен аңладыгыз инде, әйеме? Гаилә психологлары да яшь әниләргә кичкә ирләре белән аралашырга аз гына булса да көч һәм вакыт калдырырга киңәш итә. Баласына әни генә булу җитми, ир-атка назлы хатын да кирәк шул. Моны аңласак, читкә йөрүче ир-атлар турында да азрак сөйләшер идек, бәлки.

– Минем хатыным бик җаваплы кеше, – ди урамда бала арбасы тартып йөрүче Илдар. – Ул барысын да үзе эшләргә тырыша. Балабыз тугач та ул гиперҗаваплы әнигә әйләнде. Бала үскәндә шулай кирәктер дип, мин читтәрәк булырга, күп вакытымны эштә уздырырга тырыштым. Әмма гаиләдәге киеренкелек торган саен үсә генә барды. Үземнең ялгышымны, гаиләдән читтә йөрүемне әнием аңлатып күрсәткәч кенә таныдым. Өйгә хәзер чәчәкләр алып кайтырга тырышам, әниебезгә әле шоколад ашарга ярамый, шуңа ул яраткан җиләк-җимешләрне алам. Хатыным барысын да үзе булдырырга тырышса да, минем җылы сүзем, ярдәм итәргә әзер булуымны белеп тору аның өчен мөһим булганны аңлыйм. Эштән кайткач, бала белән һава суларга да үзем чыга башладым...

Сизәсезме, кызлар, ир кешегә үзен һәрвакыт кирәкле кеше икәнен тоеп, белеп тору кирәк. Хәтта бала туган мәлдә дә!

Фото: www.pixabay.com

## Хатын-кыз ирен ярата, әмма бала тугач аның уртак мөнәсәбәтләргә вакыты калмый.

Беренче кызыбыз тугач, ыгы-зыгы килеп яткан назлы тиктормаска әтисенең беренче тапкыр подгузник кидертергә тырышканын хәтерлим. Ике яктан ике каптыргычны ябыштырып куяр өчен барлык тормыш тәҗрибәсен кулланды бугай, тәки. Армиядә – автомат, бакчада көрәк-сәнәк кенә тотарга өйрәнгән зур кулларың белән нәзберек подгузник путасын җайлап, таслап кара әле син! Ә миндәге курку хисен белсәгез! Артык каты тотмадымы, авырттырмадымы, кызыма уңайсыз түгелме?! Дәшмичә, шикләнүемне белдермичә түзәргә кирәклеген аңларга фәрештәләр ярдәм иткәндер ул вакытта! (Гел өйрәтәсе килә инде без җүнсезнең!) Подгузникны җайлап, төзәтеп куйганда мактарга да җай таптым әле, әтисез буламы соң, янәсе. Безнең гаилә архивында тагын бер фото бар, «әти киендергән» дип атала ул: ике айлык кызыбызның кулында бияләйләр урынына носкилар, юка комбинезонның аяк өлеше генә киелгән дә, шуып төшеп китмәсен өчен, җиңнәре кызымның биленә бәйләп куелган. Көлке булса да, ситуациядән чыккан, аптырап калмаган, дип бәяләдек без аны. Менә шулай, мөмкин булганын шаяруга бора-бора, кай арада саламын гына түгел, печәнен дә кыстыра-кыстыра, түзәбез, кызлар, тү-зә-без! Бала, гаилә, түгәрәк бәхет хакына. Ир-ат ничек көчле булып күренмәсен, гаилә дигән дәүләттә аның урынын билгеләүче дә, кирәклеген белгертеп торучы да без – хатын-кызлар бит! Балага әни ничек кирәк булса, әти дә шул кадәр кирәк!

Ә бит кайчак зур тавыш чыкмасын өчен бер җайлап сөйләшү, әти кешегә дә авырга туры килгәнен аңлауны гына да белгертү җитә. Әнә ул, гаилә өчен дип, эштә күпме көч куя! Әти булуы белән горурлана, җаваплы булырга тырыша! Шул сыйфатларын күреп, үсендереп җибәрергә генә кирәктер, бәлки?! Уйлап карасаң, бар да бик гади кебек, ирләрдән безгә ярату, кайгырту, ярдәм итәргә әзер торулары кирәк, ә бездән – аңлау, җылылык, үзебезне бала карауга гына багышламыйча, ирләребезгә дә игътибарлы булырга тырышу сорала. Әмма менә шул гади фикерне тормышта куллланулары, ай-һай... Килешәсезме, яшь әниләр?

Алда искә алган Рафаэль белән Наилә хакында әйтмәкче идем бит әле. Шөкер, аңлашты алар. Зирәк кайнана ярдәмгә килде – вакытлыча яшь гаиләне үзләренә сыендырды. Наиләгә бала карарга, бераз хәл җыярга ярдәм итте, кайвакыт Рафаэль белән икесен генә сөйләшергә, һава суларга чыгарып җибәрә иде. Мөнәсәбәтләр җайлана төшкәч, өчәү генә яшәүнең кадере арткач, яңадан үз фатирларына күчеп яши башлады яшьләр. Гаилә сынавын уздылар булса кирәк, әле күптән түгел генә икенче балаларын көтәләр дигән яңалыкны ишеттек.

### ПСИХОЛОГ КИҢӘШЕ



**Роза ШӘФИЕВА,**
**психолог**

**Яшь әтиләргә киңәш:**

Гаиләдә бала тугач тормыш сезнең тирәдә генә әйләнмәячәген алдан аңлап куйсагыз иде, ир-егетләр. Сөйләшкән сүз, вакыйгалар бер ел тирәсе бары тик бала белән генә бәйле булачак. Әмма вакытлыча гына икенче планга күчсәгез дә, бала өчен сез һәрвакыт иң кирәкле кеше булып каласыз! Тормыштагы, көн тәртибендәге, хатыныгыз белән аралашулардагы үзгәрешләргә дә әзер булырга кирәк. Онытмагыз, хатын-кыз организмы бу чорда гормональ, эмоциональ үзгәрешләр кичерә. Аңа әле яңа халәттә үз-үзен кабул итү дә авыр бирелә. Бала туганчы яшь әтигә киңәшләр язылган китаплар яки интернеттагы мәгълүмат белән танышырга җай тапсагыз, бу чорны бергәләп узу җиңелрәк булыр. Бала көткәндә үк хатыныгыз белән булачак әти-әниләргә багышланган курслар узу да файдалы. Балагызның әнисен ратуыгызны күрсәтергә уңайсызланмагыз!

**Яшь әниләргә киңәшләр:**

Беренче чиратта үзегезне, сәламәтлегегезне саклагыз! Җаваплылыкны үзегезгә генә алырга тырышмагыз. Беренче көннән үк баланы юындыру, киендерүне әтисенә ышанып тапшырырга була. Күтәреп йөргәндә, юатырга тырышканда ата белән бала арасында эмоциональ бәйләнеш барлыкка килә, алар бербөтенгә әверелә. Ир кешедән ярдәм сорарга уңайсызланмагыз. Булышмый дип тә гаепләргә ашыкмагыз. Үзләре белгертергә тырышмаса да, кечкенә балага якын килергә, аны уңайсыз тотарга, аның белән аралашырга курка ир-атлар. Беренче айда бала сирәгрәк борчый, күбрәк йоклый. Ул вакытны күбрәк ирегез белән аралашырга тырышыгыз, җаегыз булганда ул яраткан ризыкларны пешереп куярга да, аны мактап алырга да иренмәгез. Аның өйгә кайтканына шатланганыгызны күрсәтегез. Сөйләшергә вакыт табыгыз!

**Дәү әни-дәү әтиләргә киңәшләр:**

Оныкт тугач, дәү әни-дәү әтиләрнең икенче сулышы ачыла гадәттә. Әмма балага карата булган әти-әни җаваплылыгын үз өстегезгә алмагыз. Яшь гаиләгә кысылмагыз. Һәр гаилә үзенең проблемаларын үзе хәл итәргә тиеш. Үзләре сорамаганда акыл өйрәтүдән, яхшылык белән зыян салудан сакланыгыз. Яшь гаиләнең үз чикләре, тәртипләре була, аларны хөрмәт итәргә, бар әйберне сөйләшеп, балаларыгыз белән килешеп эшләргә тырышыгыз. Бала никадәр генә кадерле булса да, гаилә тормышын алып баруны үзләренең җаваплылыгына калдырсагыз әйбәтрәк булыр.



Рифат СӘЛАХ,
шагыйрь

# МАКСАТЫБЫЗ – БӘХЕТЛЕ БУЛУ

Язмада бик кызыклы сорау күтәрелгән. Өйләнешкәннән соң, яңа гына әти-әни булган парларның һәрберсе бу кризис белән очрашадыр дип уйлыйм. Бала тугач ир-ат та, гаилә дә ниндидер бер стресс кичерә. Әмма моны зур фаҗига дип кабул итәргә кирәкми, ә рухи яктан әзер булырга гына кирәк, минемчә. Ирләрне дә аңларга буладыр. Сабые тугач, әни кешенең баласын күбрәк карыйсы киләдер, әмма бу очракта ир кеше читтә кала, аңа игътибар җитми башлый. Әле генә бер-береңне аңлап яши торган дус-тату гаилә иде... Һәм бала туа да, хатын кинәт сиңа суынды сыман тоела башлый... Артык катлаулы да, җиңел дә булмаган менә шундый ситуация килеп чыга. Тормыш булгач төрле хәлләр була, аңлашмыйча аерылышучылар да бардыр. Әмма гаиләне таркату өчен шактый сәер сәбәп булып тоела бу миңа. Мондый вакытта нишләргә кирәк, дигән сорауга төгәл генә җавап та биреп булмый, гаиләдәге хәлләргә карап үзләре хәл итәргә тиештер. Ә минем рецептым: нинди хәл генә килеп чыкса да, төп максатыбызны онытмаска! Безнең максатыбыз – бер-беребез белән бәхетле булу, бергәләп балалар үстерү. Гаиләдә проблемаларны икең бергә утырып сөйләшеп кенә хәл итеп буладыр ул. Икең бергә нык булырга кирәк! Үзебезнең тормышыбыздан да хәтерлим: бала тудыру йортыннан кайткач, бала елаган тавышка һич түзеп булмас кебек иде. Иртән дә елый ул, кичен дә, йокың да йокы түгел, үзең дә... Ә аннары кинәт елаудан туктый сыман. Чөнки син аның елаганына ияләшәсең, ишетми башлыйсың инде. Беренче бала тугач, чыннан да бик сәер халәт кичерәсең: бер яктан, ул сөенеп туймаслык олы бәхет, икенче яктан, ниндидер бер стадиягә күчү процессы башлана. Икенче, өченче балалар белән бу хәл җиңелрәк уза, син инде тәҗрибәле әти буласың, хатыныңны да күбрәк аңлыйсың. Баштагы чорда балага бик күп игътибар кирәклеген дә беләсең. Әнисе кечкенәсе янында булганда, әти кеше олы бала мәшәкатьләрен үз өстенә ала.

Олы бәхет булып, дөньяны шатлыкка күмеп бала туган мәлдә, миңа игътибар итмисең, дип үпкәләп йөрү – бала-чагалык. Ир кешенең балалыгына зыян килә, ди бит психологлар. Хисләрне уздырып җибәрергә кирәк. Мөнәсәбәтләр үзгәрде дип ачуланып йөрмәскә. Без бит ирегетләр, аек акыл белән рациональ фикер йөртергә тиеш. Бер шагыйребез әйткәнчә, салкын сугышта кайнар баш та җиңелә. Үзебез гаиләдә кечкенә бала булудан туктап, җитди ир кеше ролен кабул итәргә кирәк. Кызып китәргә ашыкмаска, үзеңне дә, хатыныңны да аңларга тырышырга, балаң өчен сөенергә, аны кайгыртырга, бала турында күбрәк уйларга... Бергәләп бала мәшәкатьләренә күмелгәндә, юындырганда, уйнатканда яңа мөнәсәбәтләргә, әти роленә дә җиңелрәк ияләшәсең.

Фикерләрне Раилә ХӘЯЛИЕВА
язып алды.

# ИРЕК ЯРАТАМ...

**Дөньяга фәлсәфи күзлектән карап, тирән уйлар белән яшәгән талантлы актриса. Гел эзләнүдә, бунтарь, куркусыз, шуңа да үзгәрешләргә әзер. Сәхнәдә дә төрле булуына шул сәбәпче түгел микән?! «Дөнья да, мин дә тагын да камилрәк булырга тиеш» дигән шигарь белән яши кебек тоелды ул миңа. Аның хатын-кыз нәфислегенә бераз гына хулиганлык та салынган бугай әле. Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры актрисасы, Татарстанның атказанган артисты Ләйсән ФӘЙЗУЛЛИНА белән сөйләшәбез.**



**Ләйсән, спектакльләрдә уйнавыңны караган саен сокланам: син һәрвакыт башка, яңа. Бу талантмы, әллә инде даими рәвештә камиллеккә омтылуыңмы?**

– Башка артистлар да шулайдыр дип уйлыйм. Таланттыр ул. *(Уйланып.)* Мин иң элек шул герой булып карыйм, аңа охшаган кешеләрне эзлим. Характерының асылын табам да, үстерә башлыйм. Һәрвакыт эзләнәм: ул образ ничек сулый, ничек йөри, ничей йоклый.. Үстерә торгач тупикка барып чыгам. Шул вакытта яңа образ туадыр да. Минем амплуа юк, шуңа күрә дә әлегә кинода төшә алмыйм. Үземне кинода бөтенләй яратмыйм. Камерадан да куркам. *(Көлә.)* Тормышта да төрле идем. Хәзер инде бер кешегә әйләнә башладым димме соң... *(Көлә.)* Мин эзләнүдә идем. Шуңа күрә дә сәхнәдә дә төрле булганмындыр. Тормышта бер генә кеше булсам да, театрда әле мин бик күп образлар тудырырга әзер.

**Шулай да тудырган образларың арасында тормыштагы Ләйсәнгә охшаганнары бармы?**

– «Томан»дагы Алия ролемне, син, дип әйтәләр. Ләкин ул кичәге мин. Хәзер инде ул Ләйсәнне үзгәрттем. Башка уйлар, фикерләр, тоемнар белән яшим. 23 яшьтә кияүгә чыксам, бәлки, шундый җүләр булыр идем. Сөенеп тә куям кайчак. *(Көлә.)*




**Актер кеше сәхнәдә генә түгел, тормышта да гомере буе уйный дигән фикер белән килешәсеңме?**

– Бөтен кеше дә билгеле бер тормыш ситуацияләрендә уйныйдыр. Ләкин ул бит үз-үзеңне алдау, нидән булса да курку. Ә артист... Беләсеңме, артистның тормышта яшәп бетерелмәгән вакыйгалары, тормыштан алып бетермәгән эмоцияләре була. Ул аны сәхнәгә менеп тоярга тырыша. Шуңа күрә артистлыкка барадыр да. Сәхнәдә күбрәк ачылганга! Тормышта бик ябык кеше булырга мөмкин, чөнки бөтен эмоцияләрен сәхнәдә чыгарып бетерә. Әйе, без сәхнәдә ләззәт, игътибар, танылу алабыз. Ә тормышта шартлар югала бит: ут юк, сәхнә юк, тамашачылар юк. Шуңа да үзен башкача тоя башлый. Тулы канлы тормышта яшәр өчен артист сәхнәдә терапия ала, минемчә. Тормышта курыккан эмоцияне сәхнәдә чыгара ул. Шуның белән үзенә җиңеллек ала.

**Артист булмасаң, кем булыр идең?**

– Психолог. Ә бәлки, сәяхәтче... Китлар коткарыр, океан чистартыр идем. *(Хыялый күзләре белән көлә.)*

**Ләйсән, социаль челтәрләреңә караганда, син сәяхәт итәргә яратасың...**

– Беркөнне санадым: 17 илдә булганмын. Иң ошаган шәһәр – Лондон. Экзотикалы Колумбиягә гашыйкмын. Ә менә Австриядә яшәр идем. Ул бик камил ил. Чит илләрдә йөрү мине илһамландыра. Аның бит һавасы да башка! Сәяхәтләрдән соң башкача яши башлыйсың.

**Чит илләр белән генә түгел, чит телләр белән дә кызыксынасың дип беләм. Социаль челтәрләреңдә постлар инглиз телендә, хәтта, ялгышмасам, корея телендә дә...**

– Өч ел инде инглиз телен өйрәнәм. Өч яшьлек бала кебек сөйләшә алам. *(Көлә.)* Юк инде, ярыйсы сукалыйм хәзер. Корея кинолары ошый. Рюкзак асып Кореяга сәяхәткә чыгып китүемә дә сәбәп шул булгандыр. Телләр бит ул яңа дөнья кебек. Билгеле, хыялларым да бар. Бәлки, киләчәктә... *(Бик серле итеп елмая.)*

**Син бит әле антиквариатлар яратучы да...**

– Әйе, бик яратам тарихи әйберләрне. Минем чулпыдан ясалган алкаларым бар. Алар бер гасырлык. Өйдә «венский» урындыкларым бар. Антиквариатларның үзләренә генә хас энергетикасы. Кайчакта секонд хендка барып әйберләр карап йөрергә яратам. Колумбиядә дә «бет базары»на бардым. Шаккатып йөргән идем. Хыялым – төрле маркалар ябыштырылган юл чемоданы алу. Аны алсам, тынычланырмын, мөгаен. Мондый чемоданны алыр өчен кабат сәяхәткә чыгарга кирәк инде. *(Көлә.)*

**Ләйсән, синең уңган татар кызы икәнеңне беләләр инде. Чиккән сөлгеләр, кульяулыкларың «Зәңгәр шәл» спектаклен бизи. Элек сөйгәннәренә вәгъдә билгесе итеп кызлар кульяулык чиккән. Син андый кульяулык чиктеңме?**

– Чигәм дә, бәйлим дә. Әле менә җәй кияргә «паутинка» бәйләдем. Вәгъдә кульяулыгы чигеп биргән идем инде. *(Рәхәтләнеп көлә.)* Армиягә озаттым. Әмма ул кеше бүген янәшәмдә түгел. Якты бер истәлек булып калды. Хәзер нәрсә теләгәнемне беләм. Аны киләчәгемдә күрәм. Мин аны тоям. Әлегә янымда күренми, бәлки, ул чит илдәдер. (Көлә.) Гаиләсез булуымны проблемага санамыйм. Ялгызлыктан курыкмыйм мин.

**20 елдан соң Ләйсән нинди булачак?**

– 53 яшьлек Ләйсән булыр! Тагын да бәхетлерәк, акыллырак, тынычрак. *(Көлә.)* Театрда түгел. Мин ул вакытта башка нәрсә белән шөгыльләнермен. Бәлки, берәр ирекле театрда иҗат итәрмен... Ирек яратам мин. Яхшы мәгънәсендә. Театрны бик яратам. Әмма беләм: ул – минем тормышымдагы бер чор гына. Дөньяда шулкадәр кызык әйберләр бар. Театр белән генә чикләнергә ярамый.

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ.

Фото: Ксения БОГДАНОВА

QR-кодны ничек кулланырга:
1. Смартфоныгызга kiozk приложениесен урнаштырыгыз.
2. QR-сканерны ачыгыз.
3. Смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.




# ТАТАР МӘГАРИФЕ МИНИСТРЫ



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Хата киткән бугай дип, кабат тагын бер кат укыдыгызмы? Әйе, беләм, юк андый министрлык: бездә – Татарстанда да һәм, әлбәттә, аларның үзләрендә дә. Әмма язмамның героен – Сания Вахит кызы ШЕВЧЕНКОны, уенын-чынын кушып, Чиләбе шәһәрендә һәм өлкәсендә нәкъ менә шулай дип атыйлар.

– Кечкенәдән укытучы булам дип хыялландым дип әйтә алмыйм. Бигрәк тә татар теле укытучысы... Дөрес, өченче сыйныфка кадәр татар мәктәбендә укыдым әле мин. Аннан әти үзебездән унсигез чакырымдагы рус авылына – Вострецовога илтте. Шунда сигезьеллык мәктәпне тәмамладым. «Татарча укып, беркая да укырга керә алмаячаксың!» – диде ул миңа... Әтинең мине зур кеше итәсе килә иде...

«Шулаймы? Керә алмыймы?! Ярый, карап карарбыз!» – дигәндер Язмыш, күрәсең.

Вострецово мәктәбен тәмамлаучыларның күбесе алга таба укуын Уфа нефть техникумында дәвам итә торган була: Сания дә шул сукмактан китә. Дүрт классташы белән документлар тапшырырга дип баралар, әмма кайсы факультетны сайларга белмиләр. «Әйдәгез, кайда теләүчеләр күбрәк, чират зуррак, шунда керәбез!» – ди ул. Кызларның икесе рус теленнән имтихан тапшыра алмый, ә Сания керә. Бәхетеннән канатланып авылга кайтып төшә. Ниндидер йомыш белән күрше Мөкәррәмә апа кермәсә, нефтьче булып киткән булыр идеме ул, юкмы, анысы билгесез. «Шул да булдымы һөнәр? – ди күрше апа кызны болытлардан җиргә төшереп. – Резин итек киеп бер буровойдан икенчесенә йөрергә җыенасыңмы? Ир-ат эше бит бу! Әнә Бәләбәй педучилищесына укучылар җитми икән, шунда бар!»

Тагын юлга чыгып китә Сания. Бәләбәй педагогика училищесына аны кабул итәләр, әлбәттә. Рус мәктәбеннән соң татар бүлегенә эләгүе исә – үзе аерым бер тарих. Озакламый лекцияләр башлана. Ошый кызга! Фикере көннән-көн ныгый гына бара аның: «Бу бит, чыннан да, минеке! Укытучы булачакмын!»

Әйе, Язмыш инде барысын да сызып куйган була.

Гомеренең Чиләбе белән бәйләнүен әйтәм әле. Педучилищены тәмамлагач, үзе укыган Вострецово сигезьеллык мәктәбенә эшкә кайта – ике ел анда укыта. Ә аннан Чиләбегә китеп урнашкан Миләүшә апасы янына кунакка дип кенә бара да, шунда кала. 1972 ел була бу. Шәһәрдә тормыш бөтенләй башка шул! Апасы ЧТЗ заводында эшли, ә бөтен буш вакыты Гата Шәрип улы Сәлимов җитәкләгән театрда уза. Андагы рух! Андагы мохит! Гата Сәлимов апасына ияреп килгән Саниягә дә игътибар итә. Премьера вакытында спектакльләргә тәрҗемәче итеп чакыра башлый: кабул итү комиссиясендә руслар гына утыра бит. Сания Чиләбенең атаклы артистлары Нәзифә Хәбибуллина, Җәүһәрия Нәфыйковалар белән якыннан таныша. Әмма театрның гел үзенә тартып торуының башка сере дә була әле: аның булачак ире – атаклы баянчы да шушы үзешчән театрга йөри...

Гата Сәлимов театры аны милли хәрәкәткә дә алып кереп китә.

Шәһәр китапханәсендә Татар-башкорт мәдәнияте үзәге (аны үзара «татар-башкорт үзәге» дип кенә йөртәләр) оеша. Үзәкнең җитәкчесе Рәшидә Сираҗиева үз тирәсенә бөтен татар зыялыларын туплый: укытучылар, артистлар, шагыйрьләр... Сания дә еш бара китапханәгә: беренчедән, китап укырга ярата, икенчедән – милләттәшләр белән һәр очрашу бәйрәмгә әйләнә. Көньяк Урал дәүләт университеты студентлары үтенече буенча, китапханәдә татар теленә өйрәтү курслары эшли башлый. Атнага бер тапкыр – якшәмбе көннәрендә җыелалар. Сөйләшүләр гел татар китаплары тирәсендә әйләнә. Студентлар сорау арты сорау яудыра – җавапларны күп вакыт бергәләп эзләргә дә туры килә.

1988 елны Сания Шевченко укыткан 59 нчы мәктәптә дә «якшәмбе мәктәбе» эшли башлый.

– Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Зөһрә Андреевна Минһаҗева тәкъдиме белән тотындык моңа. Аның ата-аналар арасында нинди зур эш алып баруын

Уңышның канатландырганын белә Сания Вахитовна: шуңа дәрестә һәркемнең хатасын җиңел кичерә.

аңлата да алмам... Һәр татар гаиләсенә аерым хат язды. Укырга теләк белдерүчеләр бик күп җыелды: өлкәннәр дә, балалар да... Ул чакта шундый зур яңалык булды бу мәктәпнең оешуы. Инде рус телле аудиторияне ничек татар теленә өйрәтергә? Программа да, дәреслек тә, методик материаллар – берсе дә юк бит. Барысын да үзебез яздык! Нульдән башладык... Күңелдә шундый зур сөенеч иде! Ниһаять, халыкны кузгаттык...

Теләктән генә тора – барысын да эшләргә була! Өлкәдә татар теле буенча олимпиадалар оештыра башлый ул. Әйтергә генә җиңел... Башта олимпиада биремнәрен кулдан язып чыга (компьютерлар кулланышка кермәгән чаклар әле), рейс автобусларына утырып, районнарга сайлап алу турлары уздырырга бара, үз акчасына җиңүчеләргә бүләкләр сатып ала... Иң беренче олимпиаданы Аргаяш районының Акбаш авылы мәктәбендә, башкорт теле олимпиадасы белән бергә үткәрәләр. Бөтен өлкәдән нибары 6 бала килә ул чак. Ә аннан министрлык сукмагын таптау башлана... 2004 елда гына татар теле буенча олимпиадалар Көньяк Урал фән һәм мәгариф министрлыгының эш планына керә һәм рәсми рәвештә үткәрелә башлый. Булышчылары күп хәзер Сания Вахит кызының. Министрлыкның үзенә дә, Чиләбе өлкәсе татар конгрессына да таяна ала ул. Әмма бер нәрсә үзгәрешсез калган – олимпиада биремнәрен ул һаман да үзе әзерли. Өлкә буенча узучы олимпиадада башта үз мәктәбендә, аннан район күләмендә җиңеп чыккан укучылар катнаша. Аны төрле елларда өлкәнең төрле төбәкләрендә – Үзбәгәрәктә, Конашакта, Мөслимдә уздырганнар. Соңгы ун елда исә олимпиаданың өлкә этабы Чиләбенең үзендә – Сания Шевченко эшли торган 81 нче мәктәптә генә үтә. «Күрше авыл, район мәктәбенә барганчы, зур шәһәргә килү балаларга кызыграк», – ди ул. Балаларны җәлеп итү юлларын гел эзләп кенә торалар. Бер елны, мәсәлән, татар теле олимпиадасында катнашучылар «Абзак» җәйге лагерена бушлай путевка белән бүләкләнә: сәламәтлекләрен дә ныгыталар, телне дә үзләштерәләр.

Катнашучыларның белем дәрәҗәсе үсү белән дә мактана алалар. Инде халыкара дигән статус алган бу олимпиадада аның шәкертләре дә призлы урыннар яулый. Денис Харасов, Ленария Мөслимова, Наилә Миңнуллина, Владислав Гыйбадуллин... Бу исемлек бик озын. Һәр шәкерте – укытучының горурлыгы, йөз аклыгы. Әле тагын шунысы да бар: татар теле буенча олимпиадада катнашучылар милли хәрәкәткә дә кушылып китә. Өлкә татар конгрессы үткәргән барлык проектларда катнаша башлыйлар. Алар арасыннан


Фото: Юлия Вохминцева

# «Татар теленә, мәдәниятенә аннан да тугры кешене табу авыр», – диләр Чиләбедә.



бөтен татар дөньясына билгеле лидерлар үсеп чыккан. Ленария Мөслимова – шуларның берсе. Ул бүген Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты каршындагы Бөтендөнья татар яшьләре форумы рәисе. Әйе, күңелдә милли рух бер кабынса сүнми инде ул...

– Миңа балалар белән дә, зурлар белән дә эшләү ошый. Һәр группаның үз үзенчәлеге. Күңелдәге сорау гына гел кабатлана: «Нидән башларга? Укыту процессын ничек оештырырга? Моңарчы русча гына сөйләшкән кешене ничек татарчага өйрәтергә?» Соңгы сорау барысыннан да мөһимрәк... Кем өчен генә уздырсаң да, беренче дәрес алдыннан гел шуны уйлыйсың. Туган телдә сөйләшергә өйрәтү – аерым сүзләр яки гыйбарәләр ятлату гына түгел, ә укучыңны татар мохитына «чумдыру», шунда яшәтү ул. Моңа исә татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары, тарихы, рухи кыйммәтләре, мәдәни мирасы аша гына ирешеп була. Бу юлда нинди форма, ысул, технологияләр бар – һәммәсен кулланам. Мониторинглар уздырам, анкеталар тутыртам – дәресемә һәркемне нинди теләк-ихтыяҗ китерүен өйрәнәм...

1996 елда Сания Шевченко булачак укытучылар әзерли башлый. Татар теле укытучылары! Ул елны Чиләбе дәүләт университетында Өстәмә педагогик профессияләр институты ачыла. Татар студентлары татар бүлеге дә ачарга сорыйлар. Уку – ике еллык, аны тәмамлагач, студентларга «татар теле түгәрәге җитәкчесе» дигән сертификат тапшырылырга тиеш була. Сания Вахит кызы укыту программасын үзе төзи, университетның гыйльми советында аны яклый. Лекцияләр башлана.

– Сизәм, белемем җитеп бетми... Студентларым бик кызыксынучан, берсеннән-берсе катлаулырак сораулар бирәләр. Чиләбегә күчеп килгәч, университет тәмамлаган идем инде. Кабат парта артына утырырга туры килде... Квалификацияне күтәрү өчен Казанга институтка укырга кердем. Тизләтелгән программа буенча белем алдым. Өч елдан «Татар теле һәм әдәбияты» белгечлеге буенча кызыл дипломым кулымда иде инде. Бу вакытта инде Чиләбедә милли тормыш кайный – студентларымны да шул хәрәкәткә тартып кертә башладым...

Өч чыгарылыштан соң, институтта татар бүлеге ябылып тора һәм кабат өч елдан соң гына яңадан эшләп китә. Бу юлы инде төркемгә татарлар гына түгел, чит телләр факультетыннан башка милләт вәкилләре дә килә. Өстәмә педагогик профессияләр институтының директор урынбасары булып ул елларда Чиләбенең танылган шоумены Руслан Мәҗитовның әтисе Рифкат Хәким улы эшли. Студентларны татар төркеменә тарту өчен ул бик күп көч куя. Тагын бер сөенечле яңалык була: сертификатны чын диплом алыштыра! Өстәмә белгечлек алып – татар теле укытучылары булып чыгалар. Кызганыч, нибары бер чыгарылыш булырга өлгерә: бүлек тагын ишекләрен яба.

Ә Сания Вахит кызының теләүчеләрне татар теленә өйрәтүдән туктаганы юк!

Чиләбе татар конгрессы каршында инде ничә еллар татар теле курслары алып бара. Аның дәресенә кем килсә дә, татарча сөйләшми калмый диләр: моңарчы туган телен белмәгән татарлар да, руслар, украиннар, башкортлар да. «Телләр өйрәнүгә сәләтең бармы-юкмы – анысы мөһим түгел, Сания Вахитовна дәресенә эләгү генә кирәк!» – диләр Чиләбедә. Татар теленә үзендә булган мәхәббәтне ничектер тирә-юнендәгеләргә күчерә белү сәләте бар анда. Күпләр аның бу курсларны бөтенләй бушка алып баруын исә, шәт, белми дә торгандыр...

– Татар теле музыка кебек яңгырый бит ул. Мин андагы моңны тыңлап беркайчан туймыйм... Туган телемдә аралашкан һәр минуттан ләззәт алам. Ихлас әйтәм бу сүзләрне! Чит җирдә, чит халык арасында яшәүчеләр мине аңлар... Якшәмбе мәктәбе – икенче өем кебек. Монда һәр мизгелем – әзләнү, мин монда гел ашыгам: укучыларым өчен кызыклы мөгаллим булырга, аларга үземнең энергиямне, белемемне бирергә, нindидер яңалыкка өйрәнергә, барысына да өлгерергә... Балалар янында әйтерсең лә мин үзем дә балачакка кайтам: алар белән бергә уйныйм, җырлыйм, биим, алар кебек үк хыялланам. Шул балаларга кирәклегемне тоюдан да зур бәхет юк! Укытучы эше шуның белән үзенчәлекле дә инде ул – һәр балага яратуыңны бүләк итәргә, аны шәхес итеп кабул итә белергә кирәк. Ә укучыңның ниндидер бәйгедә, олимпиадада, ярышта җиңгәнен ишеткән мизгелләрне

нәрсә белән чагыштырыйм икән? Ул шатлыкның бит чиге юк!

Туган телнең кадерен аңлаганга 1996 елда «Иман» тапшыруын алып барырга ризалаша да Сания ханым. Кемдер өчен татар телендә сөйләшүне ишетү өчен моның бердәнбер мөмкинлек булуын уйлый да... Чиләбе телевидениесе тарихында татар телендә беренче тапшыруны 1994 елда Салисә Гәрәева башлап җибәрә: экран аша милләттәшләребезгә өлкәдәге соңгы яңалыклар, китаплар турында сөйли. Ул Казанга күченеп китеп баргач, Чиләбе өлкәсе хакимиятенең дин эшләре буенча комитеты ярдәме белән тапшыруның юнәлешен үзгәртүгә ирешәләр.

– Телевидение минем өчен бөтенләй ят, яңа өлкә иде. Тапшыру айга ике тапкыр егермешәр минут чыга. Сценарийларны үзем язам, катнашучыларны үзем табам... Алты ел эчендә бик күп нәрсәгә өйрәндем. Иң беренче чиратта – теләсә нинди аудитория алдында да югалып, каушап калмаска. Дин әһелләре белән булган әңгәмәләр рухи дөньяма да яңалык алып килде: дингә мөнәсәбәтем, карашым үзгәрде. Башкалар кебек үк атеист итеп тәрбияләнгән идем бит... Язмыш миңа шулай халкыма хас булган һәр нәрсәне якыннан белү, өйрәнү, ярату мөмкинлеге бирде...

Сания Шевченко – Көньяк Уралда татар милли хәрәкәтенең башында торучыларның берсе. Ул инде озак еллар Чиләбе татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары вазыйфаларын башкара. «Аның кебекләр башка юк!» – диләр.

Яңалыкка омтылу – җанында аның.

Чиләбенең үзе эшләгән 81 нче мәктәпне татар үзәкләренең берсенә әйләндерүе дә күп нәрсә хакында сөйли. 2009 елда мәктәп белән Чиләбе татар конгрессы арасында хезмәттәшлек турында шартнамә төзелә. Конгресс оештырган бик күп чаралар анда уза: татар теле һәм әдәбияты буенча өлкә олимпиадасы, Муса Җәлил шигырьләрен сөйләү буенча укучылар бәйгесе, «Татар кызы», «Нәни җәүһәрләр» конкурсларының сайлап алу турлары... Чиләбе татар конгрессы рәисе Лена Колесникова тәкъдиме белән аларда татар теле һәм әдәбияты, сәнгате кабинетлары булдырылган, Муса Җәлилгә багышланган музей оештырылган... 2015 елда Чиләбе шәһәр Думасы карары нигезендә мәктәпкә Муса Җәлил исеме бирелгән.



■ Чиләбе өлкәсе татарлары конгрессы рәисе Лена Колесникова үзенең урынбасарлары – Сания Шевченкога һәм Ирек Сабировларга һәрвакыт таяна ала.

«Татар кызы» бәйгесенең сайлап алу турына килгән кызларның һәрберсе беренче минуттан ук Сания ханымның укучысына әйләнә: кызлар моннан үзгәреп, милләткә тагын да якынаеп, тамырларының тирән икәнен аңлап кайтып китәргә тиеш. Бөтен әңгәмәләр дә шул максатка юнәлдерелә. Ә Сания Вахитовна сөйли белә! Аңлатып, төшендереп, үтемле итеп. Горурлыкның ни икәнен, тугрылыкның, гаилә кыйммәтләренең... Гореф-гадәтләр, йолалар, тарих... Тел...

Иң авырткан җир – тел... Чиләбе өлкәсендә дә татар теле укытылган мәктәпләр бармак белән генә санарлык: Уй, Нязепетровск, Конашак, Чибәркүл (Бишкил авылы), Чесма (Рәдүт авылы) районнары... Туган телне ничек саклап калырга соң?

– Авыр сорау... Тел өйрәнү өчен, әлбәттә, мохит булырга тиеш. Ә безнең шартларда ул мөмкин түгел диярлек. Телгә өйрәтүне кечкенәдән – балалар бакчасыннан ук башларга кирәк, аннан мәктәптә, югары уку йортларында дәвам итәргә. Гаиләдә өйрәтергә! Татар тамырлары булган атаклы кешеләр турында күбрәк сөйләргә! Телгә өйрәтүче кадрларны күбрәк әзерләргә: укытучылар, тәрбиячеләр, түгәрәк җитәкчеләре... Ә моның өчен, әлбәттә, дәүләт сәясәте кирәк. Туган телне саклау өчен җаны көйгәннәр никадәр тырышса да, шунсыз күпкә ирешә алмаячак... Туган телен белмәгән кешедә аны өйрәнергә теләк тудыру, аңын «уяту», милли тамырларын искә төшерү дә бик мөһим. Рухи ихтыяҗ кирәк! Менә шул вакытта, хәтта тел аңа эше, карьерасы өчен кирәк булмаган шартларда да, ул аны өйрәнәчәк. Мин үзем туган телне белү башка телләрне өйрәнүгә күпер булачагын да гел әйтәм – яшьләр бүген телләр белергә бик омтыла. Каюм Насыйриның сүзләрен искә төшерәм: «Кеше нинди дә булса чит тел үзләштерергә тели икән, ул, беренче чиратта, үз туган телен белергә тиеш»...

Ике кыз тәрбияләп үстергән Сания Вахитовна. Өч оныгы бар. Кызлары үз юлыннан киткән – педагоглар. Олы кызы – Лилиясе – татарча иркен сөйләшә. Кечесе – авыррак, әмма әниләре мәктәптә үткәргән һәр татарча чараның эчендә кайный. Оныкларның олысы узган ел татар теле буенча олимпиадада җиңеп чыккан. Үткән уку елында үз мәктәпләрендә һәм район күләмендәге олимпиадада инде оныкларның кечкенәләре дә катнашкан. Бу яктан йөзе ак...

Аңа бирелгән бүләкләрне санамадым – алар бихисап. Сания Вахитовна өчен иң кадерлеләре – «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем һәм Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты. «Димәк, башкарган эшләрем Татарстанга, бөтен татар дөньясына, чыннан да, кирәк!» – дип сөенә ул.

Әлбәттә, кирәк!

Сания Вахит кызы Шевченконың Чиләбенең татар мәгарифе министры икәнлегенә ышандыра алдыммы?!

# ШУШМА БУЕ ТАЛЛАРЫННАН




Лилия
ГӘРӘЕВА

**Балтач, диюгә, күз алдына җиләкле тау битләре, игеннәр күкрәп үскән колхоз кырлары (күмәк хуҗалыкларны саклап кала алган район бу!), кояш төсенә буялган капкалары белән балкып утырган нык татар авыллары һәм... талчыбыктан үрелгән җиһазлар килеп баса. Әле моннан дистә ел элек кенә Балтачка юлыбыз төшкәч, Карадуганның тал чыбыгыннан үргән әйберләр цехына кереп, аһ итеп чыккан идек. Татарстанның башка районнарында да, мөгаен, талчыбыктан үрү осталары бардыр, ә менә Балтач – халкыбызның борынгы бу һөнәрен фабрика дәрәҗәсенә кадәр күтәргән төбәк.**









## Талбишекләре өчен Мөхәммәтнәби ага 1980 елда Мәскәүдә Бөтенсоюз күргәзмәсендә беренче дәрәҗә дипломга лаек була.

...Смәелнең су буе урамында кара-каршы торган ике йорт бар. Ике йортның да чормасында төрле сорттагы тал чыбыклары кибә, икесенең дә коесына бәйләм-бәйләм чыбык батырылган. Тәрәзәләрдән башлап капка төпләренә кадәр шау чәчәктә утырган бу йортлар авылның горурлыгы булган осталарныкы. Заманында Шәяхмәтов Мөхәммәтнәби дә, Якупов Харис та талчыбыктан төрле йорт кирәк-ярагы үреп дан тоткан. Мөхәммәтнәби аганың әтисе Шаһиәхтәм дә тирә-якта атаклы бер оста була. 1961 елда Чепьяда талчыбыктан үрү цехы ачылгач, Мөхәммәтнәби абыйны чакырып, яңа хезмәткәрләрне талчыбыктан үрү серләренә өйрәтүен сорыйлар. Мастер булып калуын да үтенәләр, ләкин ул авылыннан китәргә теләми. Әнә шулай, кара-каршы торган ике йорт, ата һөнәрен балага өйрәтеп, талчыбыктан үрү осталыгын бүгенгәчә яшәтеп килә. Мөхәммәтнәби абый да, Харис абый да бу дөньяда юк инде, ләкин үреп калдырган бишекләре өй түрендә әле дә тибрәнә, гөл чүлмәкләрендә гөлләр үсә, кәнәфи-урындыклары да хуҗаларына тугры хезмәттә.

Бүген Смәелдә бу эшне дәвам итүче бер генә оста бар – Харис абыйның улы Рәис Якупов. «Сүз кешесе түгел, эш кешесе ул безнең. Күп сөйләмәс», – дигәннәр иде Рәис белән танышканчы. Яраткан, күңеленнә биреп эшләгән һөнәрең турында, су буенда үсеп утырган гап-гади тал чыбыгыннан үз кулларың белән тудырган матурлык турында (чынлап та матур!) сөйләми буламыни?! Вакытын гына бик дөрес сайламаганбыз менә. Кыш көне киләсе булган: басу-кырларда эш беткәч, терлек-туар абзарга кереп, останың кулы бераз бушагач... Менә шул чагында остаханә агачның хуш исенә тулыр, гәрәбә төс күзне чагылдырыр иде.

### *Агач йоклый*

Карап торышка гади генә бер агач бу тал. Шуны киптереп, телеп, нидер үреп буласы иң әүвәл кемнең башына килгәндер, анысын инде белә алмабыз, чөнки бу һөнәрнең тарихы меңнәрчә еллар белән исәпләнә. Иң борынгы кәрзиннәр безнең эрага кадәр 6500 елга карый. Сыгылмалы җиңел агачтан үрелгән бу әйберләрнең ныклыгы белән дә, матурлыгы белән дә хәйран итә.

Әмма бишек яки кәнәфи булып түргә менгәнче, кәрзингә яки гөл чүлмәгенә әверелгәнче, тал чыбыгының әллә ничә төрле халәт кичәсе бар әле. Бер кайнарга керәсе бар аның, бер суыкка... Чималны кимәлгә китергәнче, оста үзе дә ике пешеп, өч яна әле. Җиңел генә эш түгел диюем.

Әгәр сез Смәелгә июль азагы, август башында килсәгез, Рәисне өйдә туры китерә алмассыз. Шушма буенда булыр ул. Юк, балык каптырыр өчен түгел, кышка җитәрлек талчыбык җыярга дип килә ул елга буена. Тал агачларының инде августтан кышкы йокыга талганнарын моңарчы белмәгән идем, Рәис әйтте. Яфраклары ямь-яшел үзенең, әмма кайрысы инде үзагачына ябышкан – агач йоклый. Шуңа да тал чыбыгын арыш ега башлаганнан алып (авыл кешесе вакытны үзенчә билгели!) август башына кадәр әзерлиләр. Сереме? Сере гади: бу вакытта мең чыбык өзәсең икән, меңенең дә кайрысы куба. 6 августта җыелганнарының чирегенекен инде кубарып булмаячак. 9 августтан соң берсе дә купмас. Шуңа да кырык эшен кырык якка ташлап, Шушмага ашыга егет. Өч-дүрт көндә 25-30 мең талчыбыгын җыеп бетерергә кирәк.

– Аны комбайн кебек рәттән урып бармыйсың, эшкә яраклыларын, яхшыларын гына сайлыйсың, – дип, бераз чабудан да тартып куя оста. – Җәй көне өлгерә алмый калсаң, тал яфрагын койгач, ноябрь урталарына кадәр кабат барып җыярга мөмкин.

Чыбык җыю ярты эш, әле аны эшкәртәсе бар. Менә монысы вакытта, көч тә, ярдәмчеләр дә сорый. Оста каршыма зур гына рогаткага охшаган агач куя: «Аеры агач бу. Тал чыбыгының яфрагын, кайрысын салдыра торган җайланма. Менә бу ярыгына чыбыкны куеп, кулыңа урап тотасың да бар көчеңә тартасың. Җәй көне җыелганнарын пешереп торасы юк, кабыгы болай да куба. Көз көне җыелганнарын кайнатырга кирәк». Эшнең бу этабы язын – көннәр җылыта башлагач башкарыла.

– Фабрикаларда кыш көне дә кайнаталар, безнең андый мөмкинлек юк, – дип аңлата Рәис. – Көз көне җыеп алып кайткач, чыбыкларны капронга төреп куям да, язга кадәр тора ул. Җил белән яңгыр гына тимәсен. Кабыгын салдыргач, күләгәдә киптерәм. Кояштан чыбыкның төсе кызара, караңгы урында киптергәннәре ак төстә. Кипкән чыбыкны ничә еллар сакласаң да була.

### *Җырлы бишек*

*«Бездә бишек әллә ничек*
*Талдан, җырдан үрелә.*
*Җырлы бишек, җылы бишек*
*Эленә өй түренә».*

Роберт Миңнуллин сүзләренә Оскар Усманов көй язган җыр әнә шулай башлана. Бүген аны Илнар Сәйфиев яратып башкара.

Сөн таллары гына түгел, Шушма таллары да җырлы-моңлы. Үзе җырлы, үзе җылы Балтач бишекләренә бүген дә сорау зур. Әллә кайлардан киләләр. «Сарафан радиосы» тәүлек әйләнәсе эшләп тора. Хәтта җырчыларның клипларында да күренеп китә тибрәлмәле Балтач бишекләре!

Талбишекнең ниндиләрен генә үрми Смәел остасы: түшәмгә эләторганнарын да, идәнгә куеп тибрәтә торганнарын да... Без килгәндә дә остаханәсендә биш бишек тора иде. Кайсыларын үзе үргән, кайсыларын реставрацияләргә китергәннәр. Арада әтисе яки күршеләре Мөхәммәтнәби абый үргәннәре дә очрый. «Һәр останың үз кулы. Берәү дә берәүне кабатламый. Хәтта бер үк оста үргән ике бишек тә икесе ике төрле була», – ди Рәис.

Фото: Анна Арахамия

# Өйгән утынына гына да куна куймый токмач җәярлек, дип соклана авылдашлары Рәис Якуповның осталыгына.

Әлбәттә инде, безне талбишекне үрү процессы һәм моңа киткән вакыт та кызыксындыра. Иң авыры, четерекле эше кайсысы икән? Бәлки әле ничек үргәнен дә күрербез.

– Һәй, алай тиз һәм җиңел генә булса! – дип елмая Смәел остасы. – Талчыбыкка кабат җан өргәнче, кабыгы салдырылып, яхшылап кипкән чыбыкны салкын суда тотасы бар әле. Кичтән кыршавын, төбен әзерләп калдырасы, тасмаларын теләсе... Бишек үрер өчен кирәкле бар нәрсә әзер булгач кына эшкә керешәсең. Мин, гадәттә, берьюлы өч яки ике бишек үрәм. Урындыкларны исә берьюлы унбишне ясыйм. Гөл чүлмәкләре генә тарихка күчә бара...

Бишек үрер өчен талчыбыкның төрле сорты кирәк. Кыршавы өчен – 2-3 еллыклары, тасма телер өчен 3-4 еллыгы, кырыйларын үреп менәргә берьеллык чыбыклар. Әле берьеллык дигәненең дә юанрагы кирәк, нечкәрәге... Болай гына карaганда гади күз аны абайламый да, оста әйткәч күренә: бишекнең башбашларына калынрак чыбыклар кулланылса, уртасына нечкәрәге куелган.

Ә менә тасма телер өчен дигәннәрен сәгатькә карап әзерлисе! Ярты сәгать барысын да хәл итә. Суда аз гына артык тоттыңмы, аны инде телермен димә. Тасма телә торган станогы – әтисе ядкаре. Хәер, ник ул гына. Шөшлеләре, безләре, бөгәчәләре – барасы да әтисе Харис абыйның кул җылысын саклаган кораллар. Бу һөнәре дә – әтисенең мирасы лабаса.

### *Ата мирасы*

Кечкенәдән күреп үссә дә, армиядән кайткач кына талчыбыгына карата кызыксыну уяна бүгенге останың. Югыйсә балачагы әтисенең эшләгәнен карап, остаханәдә уза.

– Безнең чор балаларына бакча булмады, авылдагы балалар бакчасын сиксәненче елларда гына ачтылар әле, – дип сөйли Рәис. – Әни эштә, абый-апалар мәктәптә (*бишәү үсә алар.* – Л.Г). Уянам да, әти янына мунчага киләм. Анда җылы, анда тәмле агач исе! Әти үзалдына күңелле сызгыра-сызгыра нидер үрә...

Рәис өйдәге кәнәфине күрсәтә:

– Кырык ел бу җиһазга. Әле дә берни булмаган.

Мондый кәнәфинең кечерәген без Мөхәммәтнәби аганың кызы Әлфинур апа яшәгән йортта да күргән идек.

– Элегрәк аркалы урындыклар да ясыйлар иде. Хәзер андыйны ясамыйбыз, арка бөгелешен бик нык исәпләп, белеп ясарга кирәк. Артсыз урындыкларны исә күп сорыйлар. Ремонтка да китерәләр.

– Әнә тегеләрнеме? – дип, остаханәдә торган урындыкларга ишарәлим. – Сезнекеләр ясаганмы?

– Безнекеләргә охшамаган, башка оста ясаган боларны. Без төбенә башка төрле бизәк төшерәбез – лалә чәчәге, – дип, дүрт читтәге дүрт бизәкне күрсәтә Рәис. – Бөгәчәсе дә башка төрле боларның... Әйтәм бит, һәр оста үзе ясаган әйбергә үзенчә кул куя. Сез бая, иң авыры кайсы эш, дип сораган идегез бит. Ышанасызмы, юкмы, иң авыры – буяу. Кызарып кипкән талчыбыктан үрелгән бишекләрне морилкалаганда ярый әле, эш тиз бара. Акка буяу мәшәкатьлерәк. Һәр үрмәсен, һәр ботак уемын җентекләп буярга кирәк бит.

– Бишек ул – ярты әни, дигән безнең халык, – дип сүзгә кушыла гомере буе шушы авылда балалар бакчасы мөдире булып эшләгән, үзе дә ничәмә тапкырлар бишек тибрәткән Зөлхәбирә апа Мәннанова. – Бу хакта педиатрлардан да сораганым бар. Тугыз ай буена әнисенең хәрәкәт уңаена тибрәнгән бала тугач та хәрәкәт сорый. Бу хәрәкәтне бары бишек кенә кабатлый ала. Анда җылы, уңай – нәкъ әнинең кочагындагы кебек. Аның бит талчыбыктан үрелүенең дә хикмәте бар. Иң чиста, иң табигый чимал бит ул. Борынгыларның һәр нәрсәсе дөрес аларның.

*...«Могҗизалар тудыралар*
*Таштан, агачтан, талдан.*
*«Смәел осталары», – дип,*
*Тарихка кереп калган...»*

Балтач районының шигъри җанлы игенчесе, Россиянең атказанган агрономы Фаварис Галиевтан да яхшырак итеп әйтеп булмыйдыр бу осталар хакында. Могҗизага тиң шушы һөнәр инде берүк югалып кына калмасын. Өй түрләрендә талбишекләр тибрәнсен, ул бишекләрдә илгә-көнгә игелекле балалар үссен.





Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

# РӘХМӘТЛЕ БУЛУ

**? Рәхмәтле булу дигәндә без нәрсәләрне күз алдында тотарга тиеш?**

– Бу гыйбарәнең мәгънәсе бездә гарәп телендәгесе белән туры килми. Татар телендә ул «спасибо» дигәнне аңлата: ниндидер изгелеккә карата сүз яки эш ярдәмендә изгелек белән җавап бирү. Пәйгамбәребезгә, мәсәлән, изгелек эшләсәләр, ул үзе дә гел изгелек белән җавап биргән: аңа берәр бүләк бирсәләр, шулай ук тиз арада бүләк ясарга тырышкан; күчтәнәч белән керсәләр, үзе дә күчтәнәч биреп чыгарган.

Ә гарәпләрдә рәхмәтле булу дип әйтү «милость» дигән мәгънәдә йөри. Кемдер безгә яхшылык эшләсә, аңа: «Аллаһының рәхмәте булсын», – дибез. Ягъни изгелегеңә карата сиңа берни дә бирә алмыйм, Аллаһы Тәгалә сине үзе зурласын, бүләкләсен, дибез.

Аллаһның рәхмәте булсын дию, икенче төрле әйткәндә: «Аллаһының сиңа изгелек кылу халәте булсын», – дию ул. Аллаһы Тәгалә сиңа изгелек, яхшылык кылып торсын, ә моңа гафу итү дә керә, җәннәтле итү дә, ярдәм итеп тору да, сиңа карата миһербан-шәфкатьле булу да.

**? Рәхмәт капкасы дип әйтү бар. Нинди капка турында сүз бара?**

– Аллаһның рәхмәт капкасы, диләр. Аллаһы Тәгаләнең кешеләрне гафу итәргә әзер торуы дигән сүз бу. Бу капка кояш көнбатыштан чыкканчы, ягъни дөнья беткәнче ачык булачак. Шул вакытка кадәр Аллаһы Тәгалә кешеләрнең тәүбәсен кабул итә һәм гафу итә.

**? Рәхмәт капкасы кеше өчен кайсы очракларда ябыла? Һәм бер ябылса, кабат ачыламы?**

– Шәхсән кеше өчен рәхмәт капкасы сулышы өзелгәндә – җаны бугазына килгәндә генә ябыла. Шушы вакытка кадәр аның тәүбә итәргә, Аллаһыдан гафу сорарга, Аллаһының рәхмәтенә ирешергә мөмкинчелеге бар. Ләкин Аллаһы Тәгаләнең шушы рәхмәте билгеле бер кешеләргә ябык. Мәсәлән, мөшрикләргә, ягъни Аллаһыга ышанмаучы кяфер бәндәләргә, Аллыһыдан башка затка табынучыларга. Аллаһы Тәгаләнең ләгънәте төшкән кешеләргә шулай ук аның рәхмәте ирешми. Моңа зур гөнаһ кылучылар керә: кеше үтерүчеләр, аракы эчүчеләр, зина кылучылар, караклар... Коръәндә: «Кеше үтерүчеләргә Аллаһының да, бәндәләрнең һәм фәрештәләрнең дә ләгънәте булыр», – диелгән. Тәүбә иткәнчегә кадәр аларга берәү дә изгелек, яхшылык теләмәс. Үкенсәләр, гафу үтенсәләр генә яңадан Аллаһының рәхмәтенә ирешерләр.

Ә Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм калсаң нәрсә була? Кыямәт көнендә Аллаһ каршына килеп баскач, Аллаһның бу кешегә рәхмәте булмый икән, димәк, ул аңа изгелек теләми дигән сүз. Бу бәндә җәннәткә үз гамәлләре белән генә керергә мөмкин: Аллаһы Тәгалә аны якламаячак. Кеше: «Минем биргән сәдакам бар», – ди. Аңа: «Ул сәдакаңның савабын син шул гөнаһ белән бетердең инде», – диләр. «Менә фәлән-фәләннәргә булышкан идем», – ди кеше. Аңа кабат: «Син аны бу гөнаһың белән юкка чыгардың инде», – диләр. Кешенең һәр изгелегенә бер гөнаһы туры килеп, изгелеге белән гөнаһысы тигез, ә кайвакыт гөнаһлар күбрәк тә булырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә бу кешегә савапларын арттырып җибәреп булышмаса, ул җәннәтле була алмаячак. Бу бәндәсенә карата рәхмәтле булган очракта, ул: «Гөнаһларың күп, ләкин рәхмәтемә ирешкәнсең (син – мөселман, тәүбә иткәнсең, гафу сорагансың, изгелекләр күп кылгансың – Аллаһка якынаерга тырышкансың), димәк, синең гөнаһларыңны гафу итәм», – ди. Пәйгамбәребез дә: «Кеше җәннәткә Аллаһының рәхмәте белән генә керә. Хәтта мин дә», – ди. Шуңа күрә без кылган изгелекләрнең максаты – Аллаһының рәхмәтенә, аның аерым бер карашына ирешергә тырышу. Шуңа ирешсәк, кылган изгелекләребезнең савабы арта, гөнаһларыбыз гафу ителә – Аллаһы Тәгалә дә безне яклап караячак.

Бу дөньяда исә Аллаһының рәхмәте бөтен кешегә дә ирешә, хәтта кяферләргә, мөшрикләргә дә: ул аларның күп гамәлләренә күз йомып карый. Шунда ук җәзасын бирми. Аллаһының рәхмәте бөтен кешегә, барча үсемлекләргә, барча җан иясенә төшә. Шуңа күрә дөньялыкта мөселман кешесе дә, мөселман булмаган кеше дә бертөсле яши. Мөселман булмаганы яхшырак, баерак та көн итәргә мөмкин әле. Безнең кайчак: «Мөселман булгач, намаз укыгач, ул бит бөтен яктан да яхшырак яшәргә тиеш», – дип тә уйлыйсыбыз килә. Логика буенча шулай бит: Аллаһы Тәгалә үзе ярдәм итәр кебек. Ләкин әлеге кагыйдә бу дөньяга карамаска да мөмкин. Җир өстендә Аллаһның рәхмәте кешеләргә тигез төшә: ниндидер байлыклар, өстенлекләр һәркемнең тырышлыгына, эшчәнлегенә карап та бирелергә мөмкин. Ә менә кыямәт көнендә барысы да башкача: кеше җәннәткә, әйткәнемчә, Аллаһының рәхмәте белән генә керә алачак. Анда мөселманнарның дәрәҗәсе зуррак булачак. Менә ни өчен бу затның ризалыгына омтылырга кирәк тә.

Мөселманнар җәннәткә тәмугта гөнаһларын яндырып бетергәч булса да керәчәк, ә мөселман булмаганнар беркайчан керә алмаячак. Аллаһның рәхмәтеннән мәхрүм булгач, аларга изге эшләре дә булышмаячак.

Кабатлыйм: Аллаһының рәхмәтенә ирешү өчен, беренче чиратта, мөселман булырга, аңа ышанырга, кушканнарын үтәргә, аннан үзең дә кешеләргә рәхмәтле булырга тиеш. Таныш һәм таныш булмаган кешеләргә сәбәп белән һәм сәбәпсез изгелек кылырга кирәк: елмаеп карарга, сәдака бирергә, киңәшең белән булышырга, малың белән бүлешергә... Болар да рәхмәт, һәм аларның мәгънәсе тирән.

PRESSA

Ул шигъриятькә язгы ләйсән яңгыр булып килеп керде. Җаны бәргәләнгән чакта хисләрен түкми-чәчми ак кәгазьгә төшереп, күңелләрне сафландырды, җаннарны иркәләде. Әти-әнисе дә шагыйрьләр булган кызга кечкенәдән үк шигырь җиле кагылсын да! Китаплар, Хыял, Иҗат мохитендә үссен дә! Шәһәр кызына татар теле дәресләрен китап һәм авыл бирә. Ләйсән Юнысова шигырьләре – үзе бер дөнья! Аларда Марина Цветаева, Анна Ахматовалар чалымы сизелә. Яшәү, тормыш, мәхәббәт фәлсәфәсе, кысаларга, шартларга сыярга теләмәве беркемнекенә охшамаган – бөтенләй башка яссылыкта! Яшь шагыйрәне күреп алган Мөдәррис Әгъләмов аңа зур өметләр баглый: «Халкыбызның шигъри дөньясында якты йолдыз булып калган Саҗидә Сөләйманова «шагыйрә» дигән төшенчәне яратмый иде. Ул үзен шагыйрь санады. Һәм үзенең шигъри дөньясында шул дәрәҗәгә ирешә дә. Ләйсәнгә дә шуны телим», – ди ул.

Ләйсән ЮНЫСОВА

# ҖАНЫМ, КУНЫП, ХӘЛ ҖЫЙСЫН...

* * *

Киредер мин –
Әллә нигә шунда
Кеше салган юлдан йөрмәдем.
Язмышымның талгын агышында
Урын табып кына йөзмәдем.
Ачык ишек көтеп торганда да
Кирелегем куды уратып,
Үз-үземә тапкан бураннарда
Йөрдем шулай бәхет урлатып.
Үз юлымны, үз җырымны эзләп
Чүлләр кичтем җилгә сарылып.
Юкка түгел икән – минем эзләр
Әнә калган,
ята ярылып.
Тормыш ярып барам,
Язмыш ертып –
Йолдызыма таба ашыгам.
Офыкларсыз дала булып әнә
Җәелгән бит гомер
Каршыга.

* * *

Учлап-учлап, ашыкмыйча,
уйчан гына
Яңгыр сибә тамчыларын учыма.
Утырам мин җиде юлның
бер чатында,
Җиде төннең, җитмеш уйның
кочагында.
Бер җилкәмнән җиде җилнең
кулы какты.
Басып торам – җиде илнең
җиде яты.
Бер узгынчы мин дөньяда –
кемдер атым?
Җитмеш күзгә,
җитмеш җанга барып бактым.

Җиде йозак күңелләрдә,
җитмеш тозак.
Дәрвиш сыман йөрим Җирдә,
бер ялгызак.
Җиде юлда адашканмын,
кая чырак?
Җидегән йолдыз күктә дә соң...
Йолдыз ерак.

### *Үзем генә*

Озатмагыз мине ерак юлга.
Үзем чыгып, үзем кайтырмын.
Юл янчыгым – уй капчыгым тулган,
Йөри-йөри бераз саетырмын.
Үз гомерем – юлы үземнеке.
Үзем атлап, үзем абынам.
Үз хатама үзем үкенеп мин,
Үз Аллама үзем табынам.

Кеше сүзе мине озатмасын –
Үзем генә йөрим адашып.
Бер кәккүк тә белми ни язасын –
Утырмасын еллар санашып.

Юлларыма сәлам җәйгән булып,
Киңәшчеләр янда йөрмәсен.
Егылганым әле хәтсез булыр –
Елаганны беркем күрмәсен.

* * *

Аңгырайдым – яңа гына...
Яңа гына
Язмыш сукты яңгыратып яңагыма.
Яңгырлардай шыбырдады
күз яшьләрем.
Өлешемнән көмеш көтеп
күп яшәдем.
«Күп сорама – аз алырсың», –
диде Аллам.
Ярар, ярар...
Синнән башка яши алам.

Күңелләрем йодрыкланды.
Күкне каргап,
Басып торам,
балбал сыман алга карап.

### *Пәрдәсез*

Минем янда ни калган соң:
Ни күреп, әрсез генә
Маңгай терәп капланкансыз

Күңелем тәрәзенә?!
Әллә ниләр эзләмәгез –
Күңелем тулы яралар...
Тәрәзәләре пәрдәле –
Һәр күңелдә бар алар.

* * *

Җилләрдән мин тормыйм качып –
Тәрәзәм минем ачык.
Йә, яшен, суксаң сук –
Язмыштан узмыш юк...
Узмыш юк...

Тормыштан да тормыйм качып –
Күңелем минем ачык.
Йә, кайгы, суксаң сук –
Яшьлектән узмыш юк...
Узмыш юк!

* * *

Өзелмә, үзәгем, өзелмә,
Керсәм дә картаймый күземә,
Үкенеп карамам күзгегә:
Алтын ул – саргаю төсе лә.

Көмештән киеник, көмештән,
Ул безгә кайчан да килешкән.
Зарланма син безнең өлештән –
Үзебез лә аны өләшкән.

Каргама, күңелем, Алланы:
Алгысып бар инде талганың,
Ялкынлап бар инде янганың...
Бездән тормый инде калганы.

Төренмә, йөрәгем, хыялга.
Хыял ул – хәерсез пыяла:
Ватыла да, кисеп, коела –
Уела да җаным, уела.

Җиткәндер ул безнең гомергә –
Күмелсен өметләр күмергә.
Ни насыйптыр әле күрергә...
Сүрелмә, учагым, сүрелмә.

* * *

Ә минем башым авырта.
Ә минем гамем юк бернидә.
Утырам берсүзсез. Ә сез
Шаулашасыз тирә-юнемдә.

Елмаеп утырам: мин дә бит
Кайнашканмын кичә үзәктә.
Мәш киләсез бүген дә.
Ә мин?
Мин бүген сезне күзәтәм.

Ә миңа кызык. Мин – читтә.
Сөйләшәсез кызып, аһ итеп...
Мин катнашмыйм бүгенге көндә.
Мин аның сүзсез шаһиты.

* * *

...Елар әле дидегезме,
Үксеп-үксеп, үкенеп.
Белдегезме, сиздегезме,
Көттегезме бу көнне?!

Инде көтәсездер, ахры,
Мескен башым игәнне.
«Җүләр булдым. Гөнаһларым
Ярлыкагыз», – дигәнне.

Үксеп-үксеп елауларым
Үкенүдән түгел лә –
Ачы яшем җүләрлекне
Юксынудан түгелә.

### *Арыдым*

Бәргәләнә бер күбәләк,
Әй, омтыла, ымсына –
Күңелләр яктысына да
Җаннарның җылысына.

Очасы килә аның да
Сагындырып, сөйдереп.
Җылы эзли күбәләгем,
Канатларын көйдереп.

Бәргәләнә, бер күңелдә
Урын табарга теләп.
Якты эзли, канатларын
Бозлардан телә-телә.

Әй, берегез, кызганмыйча
Күбәләклек җылысын,
Күңелегезне ачыгызчы –
Җаным, кунып, хәл җыйсын.

### *Мөдәррис Әгъләмовка*

Яз син, бала, яз, дидең.
Күңлең тулы наз, дидең.
Язың азган чагында
Үз акылың аз, дидең... –
Шундый усал остаз идең.

Язның көне аз икән,
Салкын күңел – баз икән.
Остаз барда янында
Оста гына яз икән.
...Шагыйрь көне аз икән.

Янып беттең гөлт итеп,
Йөрәгеңне көл итеп.
...Салам ятим шигырьне
Кабереңә гөл итеп –
Атмаган сөмбел итеп.

### *Югалттым...*

Талчыктым. Арыдым. Ялыктым.
...Эзләдем якты ялкынны –
Утларда көйде канатым,
Җилләрдә китте яманатым.

Еладым. Рәнҗедем. Оныттым.
Ялкынсыз яктыга юл тоттым.
Бозларга барып юлыктым –
Канатым канаттым.
Оныттым...

Өметем һаман да өзмәдем –
Мин утсыз җылы эзләдем.
Җанымны гына елаттым –
Яктысыз, юлны югалттым...

### *Авылыма*

Авыл-авыл, сине сагынырга
Иртәрәктер әле яшьлектән.
Ялантәпи тормыш шаукымына
Йөгереп чыктым кайчан ишектән?

Бәллүендә тирбәткәне дә син,
Атынчыкта күккә атканы...
Иманымны тетрәткәне дә син,
Тәмләп-чәйләп гайбәт сатканы...

Төрле чагың булды, төрле тәмең –
Гел яраттым дисәм, алдармын.
...Зиратында аткан сиреньнәрне
Күңелемдә менә саклармын.

Күпме җәйләр үтте елый-көлә,
Күпме язлар ташып түгелде.
Тәрәзләрдән пыш-пыш килә-килә
Озатучы да син түгелме?

Тыкрыкларың бигрәк озын иде,
Бигрәк баткак иде юлларың...
Мин дә синдә үскән кызың идем,
Ни юлларда йөри улларың?

Аркалардан сөя-сөя генә
Гәрәбәдәй баллар ашаттың...
Инде череп барган нигезеңә
Кем беренче булып таш атты?

...Әй яраткан идем дә соң, авыл,
Хәтфә сыман бәбкә үләнен.
Кабат яратырга соңрактыр шул –
Күрми калдым үлгәнне.





Язучы Роза Мулланурова хикәяләрен хатын-кызлар аеруча яратып кабул итә. Чөнки ул аларның хәл-халәтен, язмышын, сөенечләрен һәм күз яшьләрен үз йөрәгә аша үткәреп яза. «Сөембикә» укучыларын язмалары белән куандырып торучы журналист Роза Камалетдинова да – шул Роза апабыз инде! Ул һаман иҗатта, эзләнүдә. Быел Татарстан язучыларының Фатих Хөсни премиясенә лаек булды. Бу санда аның өр-яңа хикәясен тәкъдим итәбез.



Роза МУЛЛАНУРОВА

# ГОМЕРЛЕК СЕР

(Хикәя)

Хәбирәнең тоткага сузылган кулы һавада эленеп калды. Чыр-чу килеп бала-чага ни бүлешә анда? Капканың эчке ягыннан ишетелгән чәрелдек тавыш өнсез итте:

– Сөймим! Сөмсез! Сөйкемсез сөяк! Сөальче!

Йә Хода, сабырлык бир! Йөрәк өшетерлек ямьсез сүзләр кемгә аталган икән!

Аңа түгелдер ич? Булмас, булмас! Уе миен яндырып үтте. Башын күтәреп тирә-якны күзләрлек хәле калмады, кемдер арттан этте гүя. Аягын көчкә сөйрәп, галошын лыштырдатмаска тырышып, кире борылды. «Кеше-кара очрамаса, күрмәсәләр ярар ие!»

Әллә урам киңәйгән? Аягы җиргә тими, өч басасын бер сикереп ике араны очып узган чаклар кая китсен – сугыш урлаган! Дәрт-дәрманын картлык – карт аю ялмаган. Юанырга шул җитәр дип, хатирәләр өеп калдырган. Иң кадерле мизгелне – Рәүфенең җилкәсенә башын куеп тын калган таңны хәтердә яңартып, кайтарып булсае яшьлекне!

Күршедә балалар чыр-чуы... кайтасыларын әйткән иде Дөррия. Хәбирә дә түземсезләнеп көтә аларны. «Ерак әбекәй, нихәл?» – дип, Мөсәвир кереп җитәр төсле: таңнан торып камыр куйды. Келә шылтыратуын өнәми, артык кашыкка санныйлармы әллә аны? Кунак кунакны сөймәс, өй иясе берсен дә сөймәс, хуҗабикә үзе күпсенәме?

Капка келәсен элә керде. Кереп, бимазалап йөрүче булмас та... «Какма кеше капкасын, үз капкаңны кагарлар», диярлек адәм заты калмады. Кордашлары мәңгелек йортка тау башына күченде. Ахирәт дус – тик икәү калдылар авылда: Дөррия дә ялгыз башы гомер сөрүче Хәбирә генә. «Ике чабата – бер кием хәзер без», – дигән була. Хәбирәгәме соң Дөрриягә җиту! Күләгәсе, шәүләсе ул аның! Шәүлә күк яшәргә үзе риза булгач! Ике чабата – икесе көндәш шул алар. Беркемгә берни сиздерми яшәү рәхәт түгел дә, моны кем белә?

Дөнья гамьнәренә бирешми Дөррия. Һаман шат, бәхетле. Рәүф нәселе – Рәшит улы таяныч, терәк булды үзенә. Оныклар нәкъ бабалары төсле юаш. Хәер, Рәшитнең Мөсәвире «Әбекәй» дип, Хәбирә өчен үлеп тора. Күршедә генә яшәп тә, «Ерак әби» – елак әби булып калды Хәбирә, шунысы аяныч. Ерагайды аралар. Тәкъдирме?!

Дөрес, Дөррия мәҗлес, кунак җыйса, Хәбирәне дә калдырмый. «Бергә гомер иткән күршекәем!» дип, түргә утыртырга яскына кайчак. Кукраеп түрдә утырамы соң Хәбирә? «Син олырак, син ерактан килгән», дип, түрдән урын бирердәй кунак, шиксез, табылачак. «Күршекәй», урыныннан күчә-күчә, ишек катына ук кала. Кеше көен көйләп, савыт-саба өләшеп йөри торгач, аш-суга якын килмәвен абайлап, берәрсе аһылдаса да: «Чит кеше түгел,

монда мин үз кеше», – дип үткәреп җибәрә. Чит тә түгел, үз дә... Үзеңнеке – үзәктә, дип түзәргә калгач, сер биреп тормас инде!

Рәүфнекеләр табын тутырып утырганда, Хәбирәнең йөрәген ут-ялкыннар чорнаганын кем белсен? Шуңа куана: нигезе буш-ятим түгел. Сукмакка тузан кундырмый яшьләр. Рәүфнең Рәшите читкә китмәде, шушы нигездә гомер итә. Улы Мөсәвир – рәссам. Ашкынып кайта. «Ерак әбекәй, портретыңны ясыйм, стенага элеп куярбыз. Сагынмакка!» – дигән иде дә, Хәбирә үзе эреп төшмәде. «Булдыра алсаң, бабаңның рәсемен яса! Фотосурәте дә калмады ич. Без әле исән, килеш-килбәте күз алдында чагында...» – дип сөйли генә башлаган иде, Дөррия килеп кушылды: «Якын әбекәң белән янәшә ясарсың аны, яме!» – дип, дилбегәне, гадәтенчә, үз кулына алды. Дәртләнеп тотынса да, очлап чыга алмады Мөсәвир бу эшен. Еракка, Герман җиренә китәсе булды. Практикага, диде. Кем белә, бәлки, бабасының эзләрен эзләп, барлап йөргәндер. Булмас димә, дөнья бу!

Дөрриягә керми яшәргә риза булыр иде, газизләрдән-газизе – итәгендә үскән Рәшитен күрми бер көн түзалмас Хәбирә. Яшәү көче бирүче, фани дөнья белән бәйләп, тартып торучы җеп, аркан Рәшит аның өчен! «Әнкәй» димәде, «Ерак әбекәй» дип ачылды теле. «Ерак, димә, «якыным» диген!» – дип, Хәбирә үзе башын бутады. Барыбер якын күрә ул аны. Җан тартмаса, кан тарта. Ә җаннар... Мәңге өзгәләнерме?

Көн дә кереп хәл белешү, гадәт кенәме, йолага әйләнгән. «Кайсыбыз алдан китәр, соңгы юлга кем кемне озатыр», дигән уй, телдән ычкынмаса да, күңелне бимазалый. Эш-мәшәкать гомер узганын сиздермәсә дә, офык артында түгел ул көн.

Яшисен яшәде Хәбирә! Шөкер итәрлек, туксанны куа. Тик Рәшит өчен йөрәге өзгәләнә. Ике тапкыр йөрәк өянәге кичерде, чак исән калды. Гомер буе балалар укытты. Яратып эшләде эшен. Абруйлы, белемле, чын мөгаллим, диләр аны. Эреләндерәбез дигән булып, авыл мәктәбен ябулары белән килешмәде. Сүрелде янып йөргән галим-мөгаллим. Яну-көюен сиздермәскә тырыша. Кәефсез йөргәнен күрә Хәбирә дә. Узгынчы чир була күрсен, дип теләк теләүдән уза алмый.

Тәрәз төбен тутырып үсеп утырган тамчы гөлләр – моңлы гөлләр дә, нинди киңәш бирергә белмәгәндәй, мөлдерәп карап тора кебек. Алкаланып, асылынып төшкән чәчкәләре күбәләк канаты сыман ачылыр, җанланыр да очып китәр сыман.

Үзен белә-белгәннән бирле тамчы гөл үстерде ул. Нур сирпеп, балкып чәчкә аткан чакларын ярата шул. Бүлмәсе яктырып киткәндәй була. Аннан... тамчы-тамчы булып яшьләре тама, җанга сагыш сара. Елап-елап өзелеп төшүләре читендер гөл чәчкәсенә дә. Оя-оя булып, тәрәзә төпләрен тутырып үскән, бергә гомер иткән гөл... Күбәләк канатына ошатуы сәер дә... Каян искә төшә: Рәүф Хәбирәне бәләкәй чакта «Күбәләгем-түгәрәгем» дип үрти иде! Шуңа кадерледер дә алар. Хәер, бүтән гөл, яшь ботаклардан үрчеткән башка гөлләр инде болары. Әмма бер тамырдан бит! Әллә хыяллана инде?! Әнкәсенең моңлы көе тел очына кунганын сизмәде дә:

...Тукта, җилкәй, исмә, исми тор!
Узган гомер, искә төшми тор!

Туксанга аяк баскан Зөлхәбирә әбиең шул чакларны сагынып елап ятсын инде! Шаккаткыч бит бу! Кемнәрнең генә исем-аты, йөз-кыяфәте истән чыкмаган, ә Рәүфкә бәйле мизгелләр гел хәтер түрендә. Әкият! Канаты көйгән күбәләк – чын исеме шул икән! Узган гомер онытыла димени! Истәлекләр... Кайсылары бик кадерле, кайсы үкенечле. Шатлык-куанычы, кайгы-хәсрәте, михнәт-газаплары, хата-ялгышлары – бар да артта калган! Теләсәң дә сызып, бозып ташлый алмыйсың, фәрештәләр гамәл дәфтәренә теркәп куйганны. Уң яктан, уң кулыма бирсәләрче, дип теләргә генә кала. Күңелгә ятышлысы, ятышсызы – һәммәсе хәтер сандыгына таслап салынган. Нигә шулайдыр, Рәүф искә төшә дә, күз аллары яктыра аның. Әй, гомерләр...

... – Өйләнәм!

Олы якта гәп куерткан ике җиткән егет – күрше Рәүф белән Ингам абыйсы үсмер кызны әллә күрмәделәр, бала-чагага санап, тел яшерүне әллә кирәксенмәделәр? Хәбирә чаршау белән бүленгән бәләкәй бүлмәдә оекбаш бәйләп утыра иде. Кулында биеп торган бишинәнең берсе учына кадалды. Канатканчы иренен тешләде, еламады.

– Өйлән! Тик белеп өйлән. Өйләнү, өйле булу! Сөйләнү түгел! – Ингам абыйсы, сынап, дикъкать белән Рәүфкә текәлгән. Күршесе дулкынлана. Өйләнү уе башына кергән икән, ниятеннән кире кайтмас. Үҗәт ул. Сүзен җилгә очыра, юкны бушка аудара торган түгел. Кай арада егет корына керде соң әле ул да?

– Туганыңнан якын дустың, еландай телләрен чыгарып, сиңа сер ача. Ә син, акыл өйрәтәсең. «Кәләш чибәрме, ничә яшьтә, ата-анасы кем?» ише гап-гади сорау биргән булып, кызыксыну галәмәте күрсәтергә иренәсең, ахрысы...

Берсен-берсе ирештереп, төрттереп сөйләшү рәвеше ят гадәт түгел аларга, моңа үпкәләмиләр дә... Ә бүген Рәүфнең тел төбендә киная сизелә. Ингам да бирешми:

– Сер капчыгын төбеннән тотып селкегәнеңне сабыр гына көтеп торам әле.

– Беләсеңме, хушсыз итә икән ярату! Бер күрүдә гашыйк булуга ышанмый идем. Аны бер күрсәң, син үзең дә... Тик, чур! Нәфесеңне сузма! Миңа насыйп яр ул!

– Чибәрлек туйда кирәк...

– Акыллы, сылу! Күрсәң, чәчләре... озын! Күзе – зәп-зәңгәр. ФАШта укыйм ди... Хыял әлегә. Мин риза. Табиб булса... Ямь керер авылга! Их, әнкәй дә исән булыр иде.

ФАШның ни-нәрсә икәнен белми иде Хәбирә. Фельдшер-акушерлар мәктәбе икән. Рәүфнең ялкынлы нотыгына Ингам абыйсы ис китү галәмәте күрсәтмәде.

– Алтын балык эләктермәкче ахры син?

– Эләкмәс дисеңме? Аңа кызыгучы... буа буарлык. «Тимерне кызуында сугу мәслихәт», – дияр иде әнкәй. Бердәнбер дустыма сер чишәм, ул ышанмый.





– Миңа димәгәе, бүген үк өйлән! Ниятең изге. Сөйләнү генә булмасын.

– Ятсаң-торсаң, ялгыз башың. Тормышмыни бу? Әллә ярый, син бар иптәшкә.

– Сез, диген! Бер гаилә ич без! Күрше хакы – Тәңре хакы.

– Сиңа галәмәт зур бурыч – башкода вазыйфасы йөкләнә, дус...

– Һмм, башкодаларсыз, заманча гына өйләнеп булмыймыни соң?

– Булмый! – диде Рәүф кистереп. – Без икәүләп... кыз сорарга барабыз.

– Хәзер үкмени?

– Уенга борма! Чынлап әйтәм. Гореф-гадәтне яңартып, икәү барып төшәбез.

– Кая? Ерак юлны өнәмим.

– Якын да түгел, алай ук ерак та түгел. Сәхрә дигән авылны беләсең ич?

– Исеме шәп. Сәхрә! «Сәхрәләргә чыксам печән билдән...» Җырлап җибәримме?..

Ә Хәбирәнең күңеле – мөлдерәмә! Күңеле тулуын сиздермәскә азаплана иде.

– Гыйшык-мыйшык чире белән чирләргә иртәрәк әле сиңа, сеңел. Үз насыйбың табылыр. Беркайчан, беркемгә үзеңне кимсетергә ирек бирмә. Горур бул! – Абыйсы аңлады аның хәлен. Киңәш бирүе ярады. Яшен әчкә йотты кыз бала. Ике йортны бер итеп, бер ишегалдында уйнап үскән дуслар ич алар. Күршеләр генә!

Зөлхәбирәгә ул чакта унбиш, егетләргә унсигезәр яшь тулып килә иде. Ингам белән Рәүфне бертуганнар дип уйларлык. Бергә үстеләр, аерылмас дус булдылар. Зөлхәбирәне икесе дә сеңелләре итеп, үз, якын күрде. Абыйсының холкы кырысрак, Рәүф йомшак күңелле. Әнкәсе Бәдерниса абыстай улына тугыз-ун яшьләр чагында ук гүр иясе булды. Ахирәте Гарифә түти әллә җәлләп, әллә бергә үскән күрше хакын хаклап, ятим малайны канат астына сыендырырга тырышты.

Рәүфнең әтисе Хәбибулла агай кулыннан эш килә торган балта остасы, эшчән ир иде дә... Яратып гомер иткән хатынының вафатын авыр кичерде, нык биреште. Чит авылларга чыгып китә дә, кемгә бура бурап, кемгәдер мунча мүкләп, ә кышларын исә итек басып гомерен сата. Икешәр-өчәр ай зимагурлыкта йөргәч, шактый гына керем белән кайтып та төшә. Карт анасы хозурында калган улы исән-саумы, югалмаганмы, адашмаганмы – берсендә дә гаме юк. «Син бит минем бергенәм» дип, инде ятсына, ата кешенең сирәк назларыннан кыенсына башлаган улын кочаклап туйганчы елый да... тагын чыгып китү җаен карый. Әгәр игелекле күршеләре – Зөлхәбирәләрнең әниләре Гарифә түти акыл биреп тормаса, Ингам белән утырып дәресләрен хәзерләмәсә, кая барып чыгар, ничек җан асрар иде ятим улы, белсә, моны бер Ходай гына белгәндер.

Кайталы-китәле йөри торгач, Хәбиб-оста хәбәрсез югалды. Үтереп ташладылар дисәң дә... Яшәү ямен җуйды, юкка чыкты. Кайгы-хәсрәткә түзми, карт әбисе дөнья куйды. Дөм ятим Рәүф тырышып укыды, югалмады. Колхоз эшен изеп эшләде. Иген иккән эшчәннәрнең хезмәтен табигать тә юмарт бүләкләде. Хезмәт көненә колхоз ашлыкны мул өләште, келәт-амбарлар тулды. Әтисе җиткергән йорт өр-яңа, таза иде.

Чәч көлтәсе уттай янып торган киленне авыл өнәп бетермәде. «Җирән» дип тел озайтучысы да, «Даррия-дөрли» диюче дә табылды. Килен «ә» дигәнгә «җә» дип торучылардан түгел, авызларын тиз томалады: «Дөррия» – энҗе бөртеге ул. Әткәй яратып кушкан исемемне бозмагыз, ә Дарриянең мәгънәсе киңрәк: «бәндәләрне саклау өчен бәла-каза китерүче зат» дигәнне аңлата», – диде. Рәүф беркемне күрми, күзен алалмый кәләшкә карап тора. Гарифә түти ялгызын туры китереп: «Ак йөзле хатын-кызга күз тиючән. Исәрләнмә!» – дип тә әйткәләде. Кияү көлде, исе китмәде.

«Бәндәләрне сынау өчен бәла-каза китерүче зат!» Хәбирә шул сүзне күңеленә якын алды, хәтеренә бикләде. Бәла буласын сизеп, шомланып аңгы-миңге йөрде.

«Герман сугыш башлаган!» Аяктан егардай хәбәрдән тыннар кысылды.

Рәүф белән Ингам абыйсына «повестка» бер көнне килде. Икәү бер атка утырып, «Герман җире кара үлән, / Әллә кайтам, әллә үләм...» дип, моңсу җырлар җырлап авылдан чыгып киттеләр. Дөррия-кәләш: «Мин дә китәм, мин – медичка!» – дип, ирләрдән калмаска теләп талпынса да, алмадылар. Хәер, медичка дигәне – хыял җимеше, ФАШ дип мактануы – Рәүф кебек асыл егетнең күзенә төтен җибәрү генә булган, ахрысы...

Хәбирәнең гоманлавын әнкәсе өнәмәде: «Адәм юрар, Ходай юллар», – дип куйды.

Ялгыз йортта Дөрриянең озак юанмаячагы көн кебек ачык иде. Алай да уртак хәсрәт үпкә-сапкаларны оныттырды. Хәбирә белән аралары җылынган иде. Рәүфнең Гарифә апаларга атап язган хатын: «Минем ярты җаным авылда – Дөррия янында калды дип белегез. Мәрхәмәтегездән ташламагыз аны!» – дип тәмамлавы да эзсез узмады. Авыр сынау еллары миһербанлы булырга өйрәтте. Ачык, эшкә карусыз, ут кебек янып торган Сәхрә кызын Рәүфнең авылдашлары үз итеп өлгергән иде инде.

Ә бер көнне Дөррия кош тоткандай балкып Хәбирәләргә йөгереп керде.

– Гарифә апа! Теләгем кабул булды! Мин китәм! – дип, аны кочаклап алды.

– Кая? Сугышка, ут эченә керәм, дип куанасыңмыни? И бала! Әллә Рәүфеңне анда табалырмын дип хыялланасыңмы? – дип куркынып сорады Гарифә түти.

– Юк, сугышка түгел! Укырга китәм, – диде Дөррия, ишекле-түрле йөренеп. – Бу сугыш тиз генә бетмәс. Госпитальләргә шәфкать туташлары күп кирәк. Минзәләдән укырга чакырып язу килде. Теге чакта, Рәүф очраганда, укырга кердем дип йөрсәм дә, мине кире бордылар. Алмадылар. Ачу итеп мин кияүгә чыктым. Үзләре чакыра хәзер.

* * *

– Аерым булды юллар… Аерым булды еллар…

Рәүф, кушучы белән башын уа-уа, әрнеп-сыкрап әйттеме моны? Әллә Хәбирәнең уе гына идеме? Хәтеренә тирән уелып калуы хак. «Сүнмәс утлар булмый, мәхәббәт тә шулай». Рәүф авызыннан ишеттеме монысын да, үзе уйлап чыгардымы? Хәтерләми.

Көтмәгәндә-уйламаганда, ишекне киереп ачып, җилләнеп килеп кергән хәрби киемле ир-атны танымый торды Хәбирә. Бөтенләй икенче кеше иде ул, үзгәргән! «Күбәләгем-түгәрәгем, онытмыңмыни?!» – дип килеп кочаклагач, югалып калды.

Ингам абыйсыннан «батырларча сугышып һәлак булды» дигән кара кәгазь генә калды. Рәүфтән дә хатхәбәр өзелгәнгә байтак. Тик сүнмәгән өмет кенә пыскый иде әле. Өмет тә итмәгән күрешү-очрашу Тәкъдир идеме? Язмыш шаяруы, Хак Тәгаләнең сынавымы, әллә хөкемеме?! Сорауларның берсенә дә әле дә җавап табалмый Хәбирә.

Биш бармагыңдай якын иткән, туганлашып беткән, елап аерылган якыныңны югалту – олы хәсрәт. Әмма очрашу да тетрәндерә икән. Гаҗәп, хәйран хәл булды бу.

Хәбирә Свердловск ягыннан урман кисүдән кайткан иде. Окоп казу, торф чыгару, шахта эше кыз-хатын җилкәсенә төште. Авыр эшләрдә ватылды Хәбирә кебекләр. «Кудылар», дип сөйләүгә ияләштеләр. Үз теләге белән китәр идеме кыз-кыркын чит-ят җиргә? Кирәк! Кушалар! Куалар! Тыңламасаң, төрмә. Өч сүздә күпме мәгънә!

Сөйләү-сөйләшү рәвеше шундый иде ул елларның. Имгәнми, югалмый кайтып керә алсаң, зур бәхет инде. Хәбирәнең исән-имин кайтуы хөрмәтенә әнисе кызу итеп мунча якты. Утын чүтлы, әмма кием-салымны кыздырмый ярамый! Бетләп беттеләр.

Икәүләп юынып чыккач, Гарифә түти: «Яккан мунча әрәм кала. Хәл белешкән дә юк, савап булыр, апамнарны чакырып карыйм», – дип юлга җыенды.

Ул китеп озак та үтмәде, ишек шыгырдап ачылды. Хәбирә аптырап, борылып караса, шаккатты: улмы бу, әллә түгелме? Рәүф абыйсы кайткан! Исән!

Нәни чактагыча кочагына сыенды. Бөтен күзәнәкләрен, җанын, тәнен моңарчы татымаган рәхәтлек куырып алгандай булды: тансык, кадерле иде аңа бу хис!

Балачактан гашыйк бит ул Рәүф абыйсына! Егет: «Өйләнәм!» – дип сүз чыгаргач, ят хистән хушсыз калган кебек сизде үзен! Башканы яр итте ир, ә ярату яралары исән!

Хисләнеп торыр чак түгел. Рәүф фронтка узышлый, нибары ярты тәүлек вакыт урлап, авылга сугылу әмәлен тапкан. Каты яраланган. «Батыр ярасыз йөрми», – дип көлеп уздырды анысын. Госпитальдә дәваланган. Фронтка, алгы сызыкка барышы, димәк, ярамаслык түгел хәле. Бер күрешү – үзе бер гомер.

Хәбирә учакны тергезеп, самавырын яңартып җибәрде. Ризык… Иң тансык сый кабыклы бәрәңге инде. Анысы да бетеп киткән икән, хәерсез.


Рәсем: Наталья Васильева





Рәүфнең юл биштәре бөтенләй үк буш түгел. Бәйрәм икән, бәйрәм булсын!

Сүз ялганмады. Фронтовикның теләгән, Энҗе бөртеге хакында хәбәр ишетергә теләп кымырҗуын сизә Хәбирә! Сизә, тик ни белә, ни әйтә ала ул аның хакында?

«Фронтка китәм, шәфкать туташы булам» дип хыялланнуын сөйләр. Аннан соң никадәр гомер узган, күпме сулар аккан. Теләгенә ирешкәндер, ул сугыштадыр.

– Үзем дә инде!.. Кыр госпитальләрен урый-урый шактый йөрелгән. Югалттык без бер-беребезне. Хатларга җавап язмады. Әллә хатлар адашты, әллә үзебез! – Рәүф көрсенеп куйды. – Ашкынып кайттым, очрар дип өметләнеп, и юләр! – Бу кадәресен әйтмәсә дә ярар иде, атылган уктай сүз яралый икән. Хәбирәне сагынып кайтмаган ул.

– Сәламәт тәндә – сәламәт акыл, диләрме? Мунча парлы, суынмагандыр, юынып чык һәйбәтләп! – Әнисенең апаларын чакырырга китүе дә истән чыккан.

– Арканы ышкысаң... – Шаярып әйттеме, әллә юри сынар өченме? Кызарды...

Сабын күзгә кырып салырлык та калмаган, бар булганы – селтеле су да баш юарга ярый торган әче эремчек суы. Мунча җылы. Кайсы нәрсәнең кайдалыгын күрсәтеп биргәнче төн уртасы авышты. Тирләтте, шулай да сер бирмәде Хәбирә.

– Чишен! Арканны уам! – диде.

Рәүф ашыга-каушый эчке киемен салганда искәрде: Ходаем, теткәләнгән арка-күкрәктә җөй өстендә җөй, рәтле-башлы төзәлеп тә бетмәгән. Ничек түзә адәми зат!

– Чиста күлмәк китерәм, боларын калдырырсың, – диде Хәбирә. Керләнгән эчке киемнәрен селтеле суда чылатып, сыгып куйганда да, кайтып кергәч тә күзләреннән яше туктамый акты да акты. Кызгану, ярату, ничек булса да хәлен җиңеләйтергә омтылу – барысы бергә кушылган, буталган иде.

Таң сызыла башлаганда да ятмаган иде әле Хәбирә. Кичләтеп кенә күрше авылга киткән әнкәсе куна калды. Апасын утыртып килерлек ат-арба табалмаганнардыр.

Әзрәк черем итеп алгач, күңеле күтәрелеп киттеме, Рәүф торып ук утырды.

– Йокла әле, иртә бит! – Хәбирәне тыңламый, тарсынмый сөйләргә кереште.

– Уйлыйм-уйлыйм да уемның очына чыга алмыйм. Егет ир булсын өчен өч шарт үтәлергә тиеш, диелгән. Нәселен дәвам итәрлек баласы... Ник сөйләп торам соң әле? Һәммәсеннән мәхрүм итте безне бу сугыш. Бетәр чамасы да күренми. Гөнаһсыз гомерләр өзелә, өзеләчәк. Иң яманы – нәселеңне корытулары... Аяусыз, кабахәт сугыш бу! Ирексездән «Мине үтерерләр ахры», дигән уй миеңә керсә, исән калуың икеле.

– Ә син уйлама! Бүген исән бит без. Энҗе бөртегең дә табылыр. Кызганыч...

– Сугыш хатын-кызны аямый. Күрдек... Пе-пе-же дигәннәрен дә! Яздылар...

«Пепеже» ни ул?» – дип сорап тормады Хәбирә. Берни сорашмады. Берәүне дә яманламады. Кадер кичәсе кебек кыска төндә гөнаһ, сугыш дигән сүз онытылды.

Бер-берең сыенып утыруның нинди ләззәт, рәхәт бәхет икәнен соңрак аңлар йөрәк. Наздан бигрәк җылы, җан җылысы кирәк кешегә. Иң кадерлесе, тансыгы шул!

Ә иртән иртүк, ат җигеп, җизнәсе белән апасы Гарифә түтине озата килде.

– Утынга кытлык. Әнкәң: «Мунча яктык, эссесе сүрелсә дә пары, җылы суы җитәр, юынырсыз», – дип кызыктыргач, килеп җиттек, менәтерәк! Кичтән ат булмады. – Керә-керешкә ваемсыз гына сөйләнгән җизни кеше сагаеп калды. Кыз янында куна калган хәрбине күреп, ни уйларга да белмәгәндер. Мулла-мунтагайны Себергә сөргәндә көчкә котылып калган үтә диндар карт яшь җилбәзәк гамәлен юньлегә юрыймы соң!

– Хәлләр... Хәлләр булган! – Күзе белән тишәрдәй булып яшьләргә карап торды. Мунчадан чыккач, йомшарды тагын: – Кем, Хәбибулла улы Рәүфетдин, Сәхрә кызын хәләл җефетлеккә алган идең түгелме? Никах укытып матавыкланмадың шикелле.

– Авыл сәвитенә барып язылыштык. Канунча... Дөррия исемен урысча яза белмичә, Хабибуллина Даррия, дип теркәделәр, – диде ир, телен көчкә әйләндереп.

– Дуррия димәгәнгә рәхмәт, дура булыр ие. Әмма дә ләкин никах лязим, – дип үз сүзен җөпләде картлач. – Зина кылу зур гөнаһ. Тәһарәтлемен, Аллаһ кушмаган эш булмас, укыйм никах. Килешмәсәгез, өч тапкыр «Талак!» диярсең. Ризамы?

Гарифә түти дә, апасы да хуплап торгач, ирексездән ир белән хатын булды да куйды яшьләр. «Талак!» дияргә тел әйләнмәде. Чәйләр эчкәч, аулакта калдылар...

– Улым булсын! Нәселем киселмәсен! – Дога, иман кәлимәсе итеп шул сүзләрне пышылдады Рәүф. «Туган җирем, җан сөйгәннәр, газиз кавемем өчен!» – дип, утка керергә әзер асыл затның теләге фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килде.

Ә Хәбирә йөкле икәнен аңлап алгач, ни куанырга, ни кычкырып еларга белмәде. Ил-көн күзендә ул – ялгыз, ирсез хатын-кыз. «Теләмәсәң, берәүгә дә белгертмәбез!» дигән шаһитлары – мулла җизни белән карчыгы озак та тормый фани дөньядан үтте.

Ачлык, мохтаҗлык бугаздан буды. Авыр эшкә чыдамыйча кырда кышлаган башакны ашап агуланып та кырылды фәкыйрь халык. Каян юнәтеп, ничек тамак туйдырырга белми тилмергәндә сөенечме бәби табу? Ирсез, «җилдән тапкан, зиначы», дип ил теленә керсәң... Чәчең белән җир себерсәң дә, гайбәткә киртә куя алмассың. Хәл-халәтен Рәүфкә белгертергә адрес та юк. Ахыры хәерле булса ярый ла!

Корсагындагы яралгыны сыйпый-сыйпый аз еламады Хәбирә. Рәүфтән килгән хат: «Сагынам. Көт! Хәлиткеч сугышка керергә торабыз. Бәлки, соңгы хатымдыр бу. Энҗедән хат бар. Җавап язарга вакыт юк», – шул хушлашудыр дип кем уйлаган?!

* * *

Көпә-көндез саташырдай булып йөргән шул көннәрдә энҗе бөртегедәй ялтырап Дөррия үзе кайтып төште дә Хәбирәне чарасыз итте. Кемнең ире соң Рәүф?! Ничек тиз, көтмәгәндә кайтып керсә, яшен ташыдай балкып, кинәт китеп тә барды. Кайту-китүен күрүче булмады. Үзенекеләрдән башка берәү дә белми никах турында да.

Дөррия кайткан шәпкә күршеләргә сугылды. Ябыккан, йончыган, күңеле шат.

– Бардым. Күрдем. Кайттым. Сугыш минем өчен үтелгән этап. Яраланып, ярты саулыгымны куеп, исән кайттым. Мәхшәр озакка бармас, бетәр! Яшәрбез!

Үзе турында тәфсилләп сөйләмәсә дә, Хәбирәнең хәл-әхвәлен тиз тоемлады:

– Син, кызый, нидер яшерәсең. Күзгә туры карый алмыйсың, – дип башлаган иде, Хәбирә тәмам югалып калды. Җитмәсә, агарынып, укшырга ук тотынды.

– Кайчаннан? – Кырыс иде Дөррия, усал. – Яшермә, күреп торам. Күпмелек?

– Өч ай тирәсе! – Ватылып-чирләп урман кисүдән өч ай элек кайтуын сөйләгән иде. Рәүфнең кайтканын белмәдеме, төпченеп тормады.

Хәбирә җиңел сулап куйды.

– Нишләргә уйлыйсың? – Сорау алырга ук тотынды, тагын ни күрер башкае!

– Белмим. – Каушавын яшерә алмыйча калтырана ук башлаган иде Хәбирә.

– Кем белер соң? Корсагың борыныңа җиткәч, уйларсың да, соң булмагае.

– Чүлмәк салдырып караргамы? Куркам да! Ярдәм итәрсең, бәлки? Котылырга...

– Син әйтмәдең, мин ишетмәдем! Табасың! – Бөергә таянып, боерык бирергә сугыш өйрәткәнме, туганда ук оста булганмы? – Бүтән куертмыйбыз юк сүзне.

– Ирсез... Әтисез бала... Ничек үстерәм мин аны?

– Үтерү җиңел дип беләсеңме әллә? Үсәр, үстерербез! Эш мәсьәләсен хәл итик башта. Зур өметләр төяп кайттым. Ниятем – авылда медпункт ачу. Рөхсәт алдым дисәм дә була. Әлегә бик җәелеп булмас. Башлап җибәрү авыр. Иң якын ярдәмчем, булышчым, бергә зур эшләр майтарырдай аркадаш итеп сине күрәм. Ризамы?

Кыр госпитален бомбага тотуларын, хәрабәләр арасыннан яралыларны өстерәп чыгарганда түшәм ишелүен, аягы имгәнүен, миңгерәүләнеп һушсыз ятуын – берсен дә сөйләп тормады. Сүзгә саран иде ул. Аксый-туксый чабарга, эшләргә әзер, риза.

Рәүфләрнең йорт-нигезендә медпункт коруны үзе уйлап чыгардымы, өстәгеләр хәер-фатиха бирдеме – җиң сызганып эшкә җигелде Дөррия. «Дөрли, дөрләтә бу», дип сокланды халык. Рәүфнең «Энҗе бөртеге»н истә тотып, «Бөртек Энҗе», «Энҗе», диделәр. Энҗедәй балкып, күз өстендәге каш кебек кыйммәтле зат булып күренде ул.

Халык ач, ярлы, хәлсез, чир-чорга тиз бирешә. Дәва-савыгу серләрен белеп бетерми. Сугышның озын кулы авыл өстенә бәла арты каза ишеп тора: белмәгән, онытылган йогышлы авырулар баш калкытты. Мескен адәмнәрне сындырып сыный заман: эч китү, тавык күзе, ютәл чире таралды! Ягарга утын, ашарга ризык калмагач...

Кыш аеруча рәхимсез, зәмһәрир суык үзәкләргә үтә. Кем – койма-киртәсен, абзар-келәтен, кем кара мунчасын сүтеп якты. Бет, кандала үрчеде. Өй борынча йөреп дару өләшү, ничә йортка бер исән мунчаны ягып, ярдәмчесез карт-корыны юындыру, өс киемнәрен күмер үтүге белән үтүкләүләр... Дөррия күп эшләрне үзе башлап йөрде, алай да таякның авыр башы Хәбирә өстенә төште. Авыр, пычрак эшләргә аның кулы керде. Шәфкать туташының ярдәмчесе – «санитарка» вазыйфасы аңа йөкләнде.

– Бүген эшкә чыгалмас. Төне буе... бәбигә авырды. – Гарифә түти үзе дә көчкә йөри. Дөррия кайтканнан бирле ике ут арасында калгандай сизә үзен. Ялгыз калып, аның белән ачылып сөйләшергә курка. Рәүфнең законлы, язылышкан хатыны ул ич!

Ана җаны кызы өчен көяләнә. Сер булудан узды, хәле – хәл! Хак Тәгалә хозурына ирешкәндер никахы, ә бүгенгесе авыр. Йөзгә кара яктың дип битәрләргә тел бармый. Үзе гаепле. Кәҗә янында юри кәбестә калдыргандай, нәкъ шул кичне, кызны ялгыз калдырып, апасына китеп баруын күр! Терсәк якын да, тешләп булмый.

Ходадан бигрәк, кеше сүзеннән курка бәндә. Сизмәделәрме көмәнле икәнен – сүз чыкмады әлегә. Киң халатын җилфердәтеп йөргәч... Надан халык – кара сарык, дияр иде ире, фин сугышыннан кайтмады. Ялгыз үстерде улы белән кызын. Тәрбиясе җитеп бетмәгәндер. Бердәнбер улы да «сугышып һәлак булды» дип юансынмы?!

Дөррия ашыгып чыгып китте дә, үзеннән калдырмый йөрткән юл сумкасын тотып кереп тә җитте. Гарифә түтигә: «Су! Кайнары, суыгы җитәрлек булсын!» – диде.

Әзер, барысы да әзер, дөнья күрмәгән хатынмыни ул! Дөрриянең кызына ярдәм итәргә атлыгып торуы күңеленә хуш килде: «Иманлы икән, шөкер!» – дип куйды. Көндәш дип уйлавы да... үзен юату өчен генә түгелмени? Рәүфнең кайтканын-киткәнен үзенекеләр күрде, белде. Йөрәгенә яра ясап, Дөррияга ник сөйләп торсын? Чакырып кайтармадылар, үзе кайтты. Халык гамен кайгыртып, олы эшләр майтарып йөрүе авыл өчен бәхеттер, бәлки. Ул да адәм баласы. Миһербанлы, булдыклы. Андый хатынга көндәш булсаң да бик хуп. Хәер, Рәүф кайтыр да әйтер әле үз сүзен!

Аңлашу кирәк булгандыр да... «Кычытмаган җиреңне кашыма», – дия иде әбиләре. Өметләр болай да сүнәрсүнмәс. Хәбирә Рәүфтән бер хат алды. Тик бер, бердәнбер. Дөррияга да килмәде хат-хәбәр. Югалды өрлек кебек ир. Үз теләге белән түгелдер. Берсендә Дөррия, ачылып китеп, хәрби госпитальдә эшләгән чагын искә төшерде. «Баш врач мәрхәмәтле, фидакарь җанлы чын табиб иде, бер яхшыга бер яман дигәннәре хак: хатыны... аждаһа! Көнләшеп, шәфкать туташларының канын эчте явыз. Рәүфнең хатын ачып укыганын беләм. Нахак, гайбәт язып җибәрдеме, кинәт суынды арабыз...»





– Ир бала! Бәхетле сабый булыр! Тыпырдап торыр бу! – Маңгай тирен сыпырып, сөенеп әйтте моны Бөртек Энҗе. Асыл зат икәне күренеп тора, рәхмәт төшкере!

Хәбирә сөенергә дә, көенергә дә белми, мышык-мышык елап ята иде.

– Их, бәхетле дә син, Хәбирәҗан! – диде Дөррия ямансулап. – Миңа мондый бәхет тәтемәс шул инде. – Сабыйны күкрәгенә кысып, үзе дә үксеп елый иде инде.

– Менә тагын кирәк булса! – Гарифәттәй үзе дә сизмәстән сүз җебен эләктереп алды. – Бетмәс кайгылар булмас, бетәр сугышы да. Кайтыр Рәүфебез дә...

– Юк, Гарифәттәй! Кайтмас. Иртән... хәбәр китерделәр. Һәлак булган Рәүф.

Дөньяның асты өскә килде. Ә тормыш – дәрья, туктап тормый, үз көенә ага да ага икән. Тол хатыннарның кайгысында сабыйның гаме юк. Сөт, ими сорап елый ул.

– Бергәләп үстерербез! – Кайсы әйтте моны, Дөррияме, әллә Хәбирә үземе? Әмма шул сүз фәрештәләрнең «Амин!» дигән чагына туры килер дип кем уйлаган ул чакта!

Малайга Рәшит дип исем куштылар. Яшәү үзәненнән ул «Хәбибуллин Рәшит Рәүф улы» булып атлап китте. Хәбирә аңа күкрәк сөтен имездe, астын алыштырды, юды, җыйды, карады. Ә туу турындагы таныклыгына: «анасы – Хәбибуллина Дөррия» дип теркәлде. Бөртек Энҗе шулай хәл итте. Хәбирә – ни чарадан бичара – гаять шикле тоелган шул карар белән килешми булдыра ала идеме? Сабыйның чынлап та Рәүф улы икәнен Дөррия белдеме, юкмы, әллә тәрбиягә алган ятим итеп кабул иттеме аны, бусы да сер булып калды. Рәшиткә җил-яңгыр тидерми үстерделәр икәү. Хәбирәгә дә ышанычлы түбә зарур, аның ярдәменнән башка тернәкләнеп китүләре икеле иде шул.

Үҗәт, үзсүзле, әмма ярдәмчел иде фронт юлларын кичкән шәфкать туташы. Мәрхәмәтле табибә ярлы-ябагайны, чирле-чорлыны авызына каратты. Түрә-күрә дип сыгылып төшми, эшли дә, эшләтә дә белә. «Утсыз дөрләтә, сусыз юа, җилсез киптерә бу», диючеләр хаклы: ун кешелек эшне берүзе башкарып чыга!

Хатирәләр диңгезенә чумып, юрганын башыннан ук бөркәнеп, ишек-тәрәзәгә якын килми ята Хәбирә. Намаз дип тә үртәлми, яткан килеш укыр. Җанга тансык җылы – тынычлык иңәрме? Чәбәләнеп беткән уйлары тынгылык бирми, тарткалый, йолка, өзгәли гүя. Белә, төзәтә алмаслык хата ясаганын белә ул. Гөнаһлардан хали түгел адәм баласы, ялгыша. Әмма бу рәвешле түгел. Тәүбә, әстәгъфирулла, гөнаһысына күрә җәза тиештер шул.

Тыштан сиздермәскә тырышса да, үзен гаепле санап, эчтән сызып, янып яшәве хак. Шундый язмыш насыйп иткәнгә кемгә үпкәләсен соң? Үзенә. Дөрес гамәл кылмаганын белде, үкенде. Үз канынnан яралган турыннарының күзенә җен карчыгы булып күренерлек булгач, җуелмаслык олы хата ясавы хак инде. Төзәтергә соңдыр. Бу тормышта Сак белән Сок язмышына дучар адәмнең берсе... үзе булса, гаҗәпме!

Дөррия Рәүфләр нигезендә медпункт кору белән чикләнмәде, авылда хастаханә салдырды. Бу төбәктә яшәүче дистәләгән авыл халкы рәхмәтле аңа. Яратты табибә апаны гавам. Хәбирә күләгәдәрәк калды. Юк, кимсенми анысына. Гомер буе чирканмый кара эштә кайнагач, шул төс аңа. Әмма газизләре: «Ерак әбекәй» дигәндә, тәне чымырдап китә. Ерак түгел, бик якын бит ул аларга! Рәшит, Мөсәвир, оныклар чиксез кадерле аңа. Тәкъдирдә язылган дип юанса да, гомерлек сер төенләнгән, чишелмәс тә. Чияләнеп беткән төенне чишү кирәкме? Кулыңнан килмәстәйне уйлама, Хәбирә!

Михнәтле еллар артта калган, авыл яшәргән, ямьләнгән, яшелләнгән чак бит бу!

Укучылар саны азайды дип, авыл мәктәбен ябуны, эшсез калуын Рәшит җанына якын алды. Ул сау булса, Хәбирә дә барына риза булып яшәр иде. Бай, хәлле адәмнәр җыелышып шәп мәчет төзеп куйдылар. Үзе абруйлы, гыйлемле дип, мулла вазыйфасын Рәшиткә йөкләргә теләгәннәр иде. Авыруын әйтеп, үзе итагатьле генә баш тартты.

Хәбирә йокымсырый башлаган иде, капканы каты гына кактылар. Ул арада кемдер койма аша сикереп ишегалдына төште. Мөсәвир икән.

– Әбекәй! Баядан бирле көтәбез. Әткәй авырайды. Нишләп ятасың? Ни хәл бу?

– Сөмсез! Сөйкемсез сөяк. Сөймәс! – Бәйләнешсез сүзләр пышылдый, саташа иде, ахры, карчык. Мөсәвир аны чәчәкле җәймәсенә сак кына төреп, күтәреп утыртты.

– Әбекәем, киен! Бая «с» хәрефенә башланган сүзләр сайлап, бала-чага мәш килә иде. Оляны татарча сөйләшергә өйрәтәләр, имеш. Шуны ишетеп, кире борылдыңмы?

– Әллә тагын... Сине көттем. Әллә нишләдем, башым әйләнә. Кем ул Уля?

– Соңыннан, әбекәй, тәртип белән иплəп аңлатырмын. Әти көтә, бәхиллек... – Әйтеп бетермәде, бүленде. – Сиңа җиткерәсе хәбәрем: бабамны – Рәүф Хәбибулла углын озак эзләттем. Германиядә әсирлектә вафат булган. Уртак каберлектә меңнәр җирләнгән. Каберенә үзебезнең җир туфрагын салдым. Синнән откан доганы укып!

...Төркиядә укып кайткан яшь мулла мәкам белән «Йәсин» сүрәсен укый иде.

– Кардәшебезне җир куенына тапшырганда шартына туры китереп үтәлергә тиешле берничә кагыйдәне исегезгә төшерәсем килә, – дип сүзен дәвам итте ул. – Мәрхүмне кабергә Ана исеме белән төшерү лязим! Гыйлем җыйганда остазыбыз әйтә иде: Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм бер хәдисендә шулай әйтергә кирәклеген искәрткән. Ни өчен Ата түгел, Ана исеме белән? Хикмәт шунда: ананың кем булуында шик юк. Ә ахирәттә, кыямәт көнендә һәркем атасының исеме белән чакырылачак. Бөтен серләр фаш ителәчәк. Кемнәрдер хурлыкка калачак. Хатын – иреннән, ир баладан качачак. Аллам сакласын! – дип йомгаклады сүзен.

Яшь имамны дикъкать белән тыңлап торган Дөррияне кинәт тыны кысылды.

– Хәбирә мондамы? Чакырыгыз анасын! – дип кысып чыгарды да телсез калды.

75 ҖИҢҮ! 1945–2020

**Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...**

# БӘХИЛЛӘШҮ АВАЗЫ ӘЛЕ ДӘ ЙӨРӘКТӘ


Фото: Лилия Гараева

– 25 июнь көнне бездә Татарстан бәйрәмен үткәрәләр иде. Шул бәйрәмгә әзерләнеп йөргән вакыт. 22 июньдә иңбашына уракларны элеп, капчыкларны башларыбызга киеп, печәнгә киттек. Киткәндә берни дә юк иде, без кайтканда авыл капкасына ниндидер язу элгәннәр. «Бәйрәм турында язганнар, ахрысы», – дибез. Ә ул... сугыш хәбәре иде.

Әңгәмәдәшем Сәкинә апа Мөбинова 1930 елның 12 февралендә Балык Бистәсе районы Зәңгәрле авылында туа. Сугыш башланганда 10 яшьлек булган баланың хәтере ул көннәрне мәңге онытмас.

– Онытылырлык булдымыни соң? – Сәкинә апа мөлдерәмә күзләрен кызыл яраннарга төбәп, әкрен генә җыр башлый: «Ленинград урамына мылтыгымны сөядем. Туып-үскән җирләремә кайтыр микән сөягем?» Инде ничә ел узса да, әтисе Габделмөбин абыйның сугыштан язган җырлары һәрберсе исендә әле.

– Шул көннән үк авыл ирләренә повестка килә башлады. Бүген – өчәү, иртәгә дүртәү китә... Зәңгәрле авылы 35 кенә йортлы. 35 йорттан 35 ир-егетне сугышка озаттык. Унҗидесе әйләнеп кайтмады... Июль аенда әтигә дә хәбәр килде. Ерак болында печәндә иде. Әни дә эштә. Бабай урманда колхоз умарталыгын саклый. Әби белән икәү төнлә бабайга бу хәбәрне әйтергә киттек. Туган апа мичкә ягып, төче күмәчләр пешерә калды. Бабай төн дип тормады, сарык чалды. Әти таң алдыннан китте. Балык Бистәсеннән кузгалучы пароходның кычкырткан безнең авылга ап-ачык ишетелә. Ул тавыш күпләрнең соңгы бәхилләшү тавышы булып, әле дә колакта тора кебек...

...Әтиләрсез, абыйларсыз, ирләрсез тормыш башлана. Балачаксыз тормыш... Әниләре Мәрьямнисага биш кыз кала алар. Сәкинә – иң олылары.

– Бүген 10 яшьлек балаларга карыйм да, без дә сабый булганбыздыр бит, дип әрни күңелем. Сабыйлыктан бик иртә чыктык шул. – Сәкинә апа бер көрсенсә, бер елмаеп та куя. – Алай да балалык үзенекен итә. Бер кышны авыл кырыена самолет төште. Казанда җыелган «ТУ». Экипажы – яшь-яшь кенә ике егет. Төзәтеп-төзәтеп карадылар, күрәсең, булдыра алмадылар. Ахырдан ул самолетны колхозчы хатыннар сүтеп, чаналар белән район үзәгенә илтте. Безгә ике зур чаңгысы калды. Шулкадәр әйбәт шуалар! Кинәндек таудан шуып!

– Ач үлемнән безне сыер гына саклап калды, – ди әңгәмәдәшем. – Кычытканны, ат кузгалагын, сәрдә үләнен пешереп сөзәбез дә, бер ашлык итеп йомарлап, базга куябыз. Әни шуннан сөтле аш пешерә. Сепараттан аерткан сөт кенә булса да, коры суга салып пешерү түгел инде. Ә ипинең без инде тәмен үк онытттык. Әти киткәндә, әни ипи кыерчыгын тешләтеп, чоландагы тәрәзә төбенә куйган иде. Шундый ышану бар: ризыгы кайтканын көтеп тора, имеш. Ул ипи кисәге шул тәрәзә төбендә бер ел торды, ике ел... Тузаннар кунды аңа. Беркөнне кечкенә сеңлебез елый-елый ипи сорый. «Кайдан алыйм?» – ди әни. «Әнә чоланда бар бит», – ди сеңлем, үксеп. Әнинең йөрәге чыдамады, тузаннарын өреп, ипи кыерчыгын алып бирде. И әрләдек инде: «Әтинең ризыгын ашадың, синең аркада әти кайта алмый бит хәзер!»

Ә әтиләре кайта аларның. Ленинград блокадасын баштан-ахырга кадәр кичеп, яраланып булса да кайта. Ул көнне дә хәтерли Сәкинә апа:

– 1944 елның 9 ноябре иде. Мәктәптән кайтып киләбез. Каршыбызга җан-фәрман кечкенә сеңлем йөгерә. Үзе кычкыра: «Әти кайтты, әти кайтты!» Өйгә кердек, и оялабыз әти янына килергә. Язга чыккач, әтине кабат сугышка алырга повестка килде. Колхоз председателе районга барып, чәчү беткәнче генә булса да калдырыгыз, дигәч, әтине калдырдылар.

Ил белән тилмереп көткән Җиңү көне дә исендә аның.

– Беренче класстан бергә укыган Хөсәенова Суфия белән мәктәптән кайтып киләбез. Түбәләрдә кызыл флаг кебек әйберләр җилферди: кем кызыллы яулыгын бәйләгән морҗага, кем кызыл шакмаклы эскәтерен, кем күлмәген... Сугыш беткән икән. Ул көнне безнең «Кызыл Үрнәк №3» колхозы йорт саен он өләште – халык бәйрәм итте. Күз яшьләре белән коенган көн иде ул. Якыннары исәннәр – тиздән күрешү шатлыгыннан, исән түгелләрнеке – мәңгегә хушлашу ачысыннан елады.

Иң авыр сугыш елларында да яхшы укыган Сәкинә апа Мөбинова сугыштан соң 41 ел гомерен балалар укытуга багышлый. Килен булып төшкән нигезнең, Балык Бистәсе Олы Елга авылының Ак әбисе, мохтәбәр заты ул бүген.

Лилия ГӘРӘЕВА



PRESSA

# АККОШ ОЧА...



**Балет бәллүргә тиң: шундый ук зиннәтле, сокландыргыч һәм нәфис. Ул – хәрәкәт гүзәллегенең гәүдәләнеше. Хисләр, темпераментлар, характерлар давылы сыйган аңа. Бер тапкыр күрсәң (бигрәк тә балачакта), аны гомер буе җаныңда саклыйсың. Балет ул чын мәгънәсендә күңел бәйрәме. Безнең өчен Казан балеты әнә шул гүзәллек дөньясы булды. Аның тарихында легендар һәм сокландыргыч исемнәр байтак. Бөтен гомерен балет сәхнәсендә идеал эзләүгә багышлаган «Терпсихора кәнизәкләре»нең иң күренеклеләре арасында Татарстан Республикасының халык артисты Сания ХАНТИМЕРОВА да бар.**

Хантимеровлар шәҗәрәсе нык тормышлы крестьяннар нәселенә барып тоташа. Әтисе Татарстанның Норлат районында туган. Булачак балеринаның әнисе исә Нократ буенда үсә, аннары Свердловскида яши, соңрак гаиләләре белән Казанга күченәләр. Нәфисә һәм Хәсән Хантимеровлар гаиләсендә 1945 елда – Сания, 1948 елда энесе Әхсән дөньяга килә. Хәсән Хантимеров Бөек Ватан сугышында катнашып, яралана. 1952 елда шул яраларыннан дөнья куя.

Саниянең әнисе театрга йөрергә бик ярата, Казан балетының булачак примасы да аның белән бик күп спектакльләр карый. Нәфисә ханым Нияз Даутовның Свердловскидагы искиткеч чыгышларын хәтерендә саклап, балаларына аның хакында, ул катнашкан спектакльләр турында гел сокланып сөйли торган була. Әле опера һәм балет театрының үз бинасы да юк чакта Камал театры сәхнәсендә күрсәтелгән «Аккош күле» балеты кечкенә Санияне тәмам сихерли, кыз аны гомере буена күңелендә йөртә. Балеттагы әкияти героиня үзенең гүзәллеге, грациясе белән таң калдыра аны. Әлеге партияне Казан балетының 50 нче еллардагы примасы, Россия һәм Татарстанның халык артисты Нинель Юлтыева башкарган була. Хореография җене әнә шулай кагыла Саниягә. Соңрак алар дуслашып китәләр. Алай гынамы, Нинель Юлтыева яшь «грация»нең остазына әйләнә әле.

50 нче елларда Черек күлдәге балалар паркында оркестр уйный, балалар бии торган була. Кышын чыршы куела, шугалак ясала. Мәктәптәге бию түгәрәгенә йөргән Сания дә паркка еш килә...

1956 елда Казанда опера һәм балет театрының яңа бинасы төзелеп бетә. Сәләтле балаларны А. Ваганова исемендәге училищега сайлап алыр өчен Ленинградтан педагог-хореографлар килә. Сания дә шул балалар арасына эләгә, конкурсны уңышлы узып, «Төньяк Пальмира»га укырга китеп бара.

А. Ваганова исемендәге академик училище Россиядә хореография Мәккәсе санала, зур традицияләре, планетаны сокландырган шәкертләре белән дан казана. Матильда Кшесинская, Анна Павлова, Вацлав Нижинский, Галина Уланова, Наталья Дудинская, Рудольф Нуриев, Михаил Барышниковның дөньякүләм даны шуннан башлана.

Чыгышы белән грек булган искиткеч педагог М. Франгпуло училищедагы балет тарихы музеенда яшь талантларны тылсымлы бию сәнгате, император театрлары, актёрлык осталыгы, мавыктыргыч легендалар дөньясы белән таныштыра. Үзе дә музейга тиң бу мәгърур шәһәр булачак артистларда зыялылык, затлылык тәрбияли. Сания Хантимерова Ленинградта 9 ел укый, һәм ул бүген дә үзенең данлыклы остазларына күңелендә рәхмәт хисләре саклый.

1965 елның җәендә училищены бик яхшы билгеләренә генә тәмамлап, биюче кыз туган ягына әйләнеп кайта. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрына урнашып, Чабаксарга гастрольгә китә. Бер актриса авыргач, ике репетициядән соң ук аны

«Травиата»дагы испан биюенә һәм башка спектакльләргә катнаштыралар. Балет примасы һәрвакыт романтик спектакльләргә өстенлек бирә. Аврора, Мария, Жизель, Сөембикә партияләрен аеруча яратып башкара.

Балеринаның репертуары бик тиз байый бара. Ул кырыктан артык партиягә кабат җан өрә. Спектакльләргә тиз кереп китүе, рольне бик бирелеп уйнавы, искиткеч үзгәрү осталыгы күпләрне гаҗәпкә калдыра. Билгеле, бу бер дә очраклы түгел, чөнки актриса күп классик һәм мәшһүр партияләрне яттан белә, бер үк вакытта актёрлык таланты да булыша. «Балетта мине һәрвакыт актёрлык сәләтен күрсәтү мөмкинлеге кызыктыра иде, – ди Сания ханым. – Күп спектакльләрдә бер үк төрле хәрәкәтләрне башкарганда, аларны гәүдәләндерер өчен һәрвакыт хореографик интонацияләрдәге аерымлыкларны эзли идем. Мәсәлән, шул ук арабеск төрле стильдәге балетларда кабатланмас булырга тиеш бит».

Балеринаның романтик биюләре җиңеллеге, өрфиялелеге белән аерылып тора. Үзгә бер җылылык, эчкерсезлек образларны йомшак яңгыраш, самимилек белән тулыландыра. Физик һәм нерв киеренкелекләрен җиңеп, сүзендә нык торучанлык һәм ихтыяр күрсәтеп, Сания Хантимерова үзенең илһамлы хезмәте белән тамашачыларның мәхәббәтен, коллективның хөрмәтен яулый. Аның бию сәнгатендә һәрвакыт ачык хакыйкать, фәлсәфи фикер, психологик тирәнлек ярылып ята.

Бөек Галина Уланова аның өчен һәрвакыт идеал була. «Илаһи актриса», – ди Сания ханым аның турында. Джордж Баланчин шаяртуынча, балет ул – хатын-кыз дөньясы, ир-ат исә анда мактаулы кунак кына булса да, Казанда үзен Ревдар Садыйков, Салих Хәйруллин, Камил Гайнуллин, Наил Сәрвәрев, Виталий Бортяков, бертуган Ибәтуллиннар кебек партнёрлар белән очраштырганы өчен Хантимерова үз язмышына бик тә рәхмәтле.

1992 елда актриса Н. Римский-Корсаков исемендәге Петербург дәүләт консерваториясенең балетмейстерлар бүлеген тәмамлый, театрда берничә постановка – «Борис Годунов» операсында Поляк акты, Илдус Якуповның «Джельсомино ялганчылар илендә» операсында пластика һәм биюләр, Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсында биюләр куя. Көнбатыш Европа һәм Россия балет сәнгате принципларын шәрык хореографиясе үзенчәлекләре белән уңышлы берләштерә.

Татарстанның халык артисты Сания Хантимерова һәрвакыт иҗади эзләнүдә. Казан хореография училищесында укыта, үзенең бай тәҗрибәсен яшьләр белән теләп уртаклаша. Аның горурланырлык шәкертләре арасында Татарстанның халык артисты Луиза Мөхәммәтгалиева, Прага балеты солисты Игорь Жуков, Россиянең атказанган артисты Николай Шильников, Татарстанның атказанган артистлары Артём Белов, Михаил Тимаев, Станислав Сырадоев, Айсылу Мирхафизханнар бар.

Татар балеты легендасының юбилее алдыннан без аның шәкертләре белән дә сөйләштек. «Сания

## Сания Хантимерованы хаклы рәвештә татар балеты легендасы дип йөртәләр.

Хантимерова – талантлы балалар белән эшли ала торган искиткеч профессионал, – ди Артём Белов. – Аңа эләгү – бәхет. Ул минем әти-әниемне белә иде, бөтен гаиләбез белән аралашты, балетта ясаган беренче кыюсыз адымнарымны күзәтеп барды, ничек басып торырга, нинди хәрәкәтләр ясарга, нинди костюм тектерергә һәм аны ничек киярга, кулны яки аякны сындырмас өчен нишләргә кебек һөнәри нечкәлекләргә төшендерде... Рус балет академиясендәге педагоглары турында илһамланып сөйли иде. Мин стандартларга тәңгәл килергә тырыштым, аның бөтен киңәшләрен хәтеремә сеңдереп бардым. Сайлаган һөнәремнең никадәр кыен булуын әкренләп аңлап, арып-талдым. Кайчандыр бөек Фаина Раневская әйткәнчә, балет – чәчәкләргә күмелгән каторга шул ул, сине күреп алсыннар, мактасыннар, премьер ясасыннар өчен никадәр тир түгәргә кирәк! Арудан бөтен тән сызлый, тик күз яшьләрен түгә-түгә, канаган аякларга басып һаман бии-бии түзәргә кирәк – безне нәкъ менә шул фантастик түземлеккә, хезмәт сөючәнлеккә өйрәтәләр. Миңа ышанулары, һөнәри осталыгым камилләшүгә инанулары, бөтенесен ташлап репетицияләрдән качасы килгәндә дөрес сүзләр таба белүләре өчен данлыклы педагогларым Виталий Бортяковка һәм Сания Хантимеровага рәхмәтем зур. Хәзер инде үзем дә педагог! Сәхнә дәвалый, алкышлар рухландыра, яшәү көче бирә. Мин укытучыларымны бик яратам һәм ихластан аларга энергия, дәрт, күңел юмартлыгы, мәхәббәт һәм яңа нәни аккошлар телим!» «Сания Хәсән кызы – искиткеч йомшак күңелле һәм игелекле кеше, – ди Михаил Тимаев. – Әни еракта иде бит, ә ул янәшәдә генә. Аның киңәшләре, әниләрчә мөнәсәбәте могҗиза тудыра: син инде «Спартак»та очасың, «Аккош күле»ндә явызлыкка каршы көрәшәсең, «Ромео һәм Джульетта»да мәхәббәттән исерәсең. Ә сәхнә артында һәм залда ничәмә-ничә кеше синең өчен борчыла, синең белән бергә хисләнә... Әлеге гармония – гаҗәеп халәт, сиңа гүя илаһи ләззәт ява! Театрның дуслары күп, тамашачылар яратып ихластан алкышлый, без исә бәхеттән, аккан тир һәм күз яшьләреннән лычма булып, баш иярга чыгабыз, зал белән бергә куанабыз. Бездән дә бәхетлерәк кеше бар микән бу мизгелдә? Бар! Безнең ПЕДАГОГЛАРЫБЫЗ алар!»

Сания Хантимерова шәкертләре өчен янып яши, дистәләрчә еллар дәвамында горур аккошлар тәрбияли, алар исә көн саен залны таң калдыра.

Флүрә ДӘМИНОВА,
Татарстанның атказанган
мәдәният хезмәткәре.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

*1921 елның башында илебез яңа икътисадый сәясәткә күчә. Бу – РКП(б)ның X съезды тарафыннан раслана.*

Мондый сәясәт эшчеләр белән крестьяннар арасында ныклы бәйләнеш урнашуын тәэмин итә. Ләкин 1921 елда моңарчы күрелмәгән корылык килә, илдә ачлык башлана.

Йөз меңнәрчә крестьян хуҗалыкларын һәлакәттән саклап калу өчен көрәш игълан ителә. Авыл хуҗалыгын торгызуда алга китеш күренә башлый. Чәчүлек мәйданнары арта, авыл акрынлап күтәрелә. Сука, кәтмән, чалгы, урак – авыл кешесенең төп коралы була. Ул вакытта техника куллану турында сүз дә юк әле, эшләр нигездә кулдан һәм ат көче белән башкарыла. Илдә ачлык-ялангачлык, хәерчелек хөкем сөрә. Авылым халкы ат урынына җигелеп эшли, михнәт-газаплар күрә, әмма күңел матурлыгын, яшәү дәртен җуймый, менә дигән балалар үстерә. Шундыйларның берсе – дәү әнием Зәйтүнә Борһан кызы Шиһабетдинованың тормыш һәм хезмәт юлы турында бер калын китап язарлык.

Ул чакта «Туры юл» дип аталган колхозга эшкә чыкканда дәү әниемә нибары 12 яшь була. Бераздан аны биш бригаданың берсенә бригадир итеп билгелиләр. 25 ат һәм үзе кебек 12-13 яшьлек малайлар-кызлардан торган бригада. Әле балалыктан да чыгып бетмәгән кыз өчен коточкыч авыр хезмәт була ул.

Өченче бишьеллык республиканың авыл хуҗалыгын үстерү бурычын куя: колхозлар һәм совхозлар алдына чәчүлек мәйданнарын киңәйтү, уңыш алуны күтәрү, терлек санын һәм терлекчелек продукциясен арттыруга ирешү.

Авылга тракторлар кайта башлагач, дәү әниемнәрнең хезмәте азрак җиңеләя, билгеле, ләкин анысы да озакка бармый... Бөек Ватан сугышы башлана. Авылның эшкә яраклы кешеләре ике тапкырга кими. Бөтен хезмәт карт әби-бабайлар, үсмер балалар, хатын-кызлар кулына күчә. Дәү әниемнәр «Барысы да фронт



өчен!», «Барысы да Җиңү өчен!» девизы белән эшлиләр. Фронтка ит, сөт, икмәк, кием озаталар.

Сугыш тәмамланганнан соң да әле авылга тиз генә җиңеллек килми. Бу вакытта инде дәү әнием чебиләр карарга күчә. Анда алты ел эшләгәннән соң, аны яшь бозаулар фермасына күчерәләр. Соңрак сыер савучы итеп билгелиләр. Лаеклы ялга чыкканчы ул сыер сава. Хезмәт сөючән дәү әнием кая гына барса да бөтен көчен куеп эшли. Сугыштан бер кулын җәрәхәтләп кайткан Габдрахман бабам белән гаилә корып, балалар үстереп, зур тырышлык белән яшиләр.

1976 елны дәү әнием Зәйтүнә беренче дәрәҗәдәге «Ана даны» ордены белән бүләкләнә. Алар бабам белән 9 бала: баһадирдай ике ул, чәчәктәй матур җиде кыз тәрбияләп үстерәләр. Гаиләдә дә, хезмәттә дә үрнәк әти-әни булалар. 1969 елдан дәү әнием Яшел Үзән район советына депутат итеп сайлана. Зәйтүнә дәү әнием елына 4 мең литр сөт савып, зур күрсәткечләргә ирешә. Ул чагында дүрт мең литр сөт саву – зур батырлык санала! 1971 елны аңа Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре һәм персональ пенсионер исемнәре бирелә. Шул ук елны Мәскәүдә халык казанышлары күргәзмәсендә катнаша, көмеш медаль яулый. 1971 елны – Хезмәт Кызыл Байрагы, ә 1973 елда Ленин орденнарына лаек була. 1980 елны дәү

Фото: www.pixabay.com

әнигә «Хезмәт ветераны» медале, ә 1995 елны «1941-1945 еллардагы фидакарь хезмәте өчен» медале тапшырыла.

Быел ТАССР төзелүгә 100 ел булды. Шушы 100 ел эчендә Татарстан үсте, ныгыды. Республикам шундый зур нәтиҗәләргә ирешкән икән, монда дәү әнием Зәйтүнә һәм бабам Габдрахманның да өлеше бар, минемчә.

Дәү әнием күптән вафат, бу язма аның рухына дога булсын иде.

*Лилия ӘХМӘТОВА.*
*Казан-Яшел Үзән.*

*Журналыбызның инстаграм битендә апрель-май айларында «Көтә белгәннәр полкы» дип аталган флешмоб башлап җибәргән идек. Ел саен зурлап уздырыла торган «Үлемсез полк» янәшәсендә газизләрен Бөек Ватан сугышына озатып, аларның кайтуларын көтеп яшәгән әниләр, әбиләр, апалар исемнәре дә торырга тиеш дип уйладык.* Күпләр бу флешмобка катнашып, кадерлеләрен сугыш кырларыннан көтеп җиткезә алмаган хатын-кыз якыннары турында мәгълүмат туплады. Мин дә иремнең дәү әнисе Фатыйманы тудырып-үстергән Нурлыҗиһан дәү әниебез турында язып әлеге флешмобта катнашырга уйлаган идем. Әмма хатирәләрне барлап, бер учка җыям дигәндә генә яңа мәгълүматлар ачыла башлады, көтмәгәндә-уйламаганда гына бу тарихның дәвамы барлыкка килде...

Нурлыҗиһан дәү әниебез – Апас районы Морзалар авылы кызы. Биш бала әнисе. Сугышка ул башта ире Солтанны, соңрак олы улы Равилне озата. Үзен алырлар дип күз алдына да китермәгән Равил абый әтисен атка утыртып Тәтешкә озата барганда, бик кайгырып: «Исән-сау кайтсаң иде, әткәй!» дип өзгәләнә. Әмма озак та үтми, 1942 елның декабрендә Равил абыйның үзен дә сугышка алалар. Мари АССРның Суслонгер саласында хәрби хезмәт лагерена эләгә ул. Улының туган җирдән ерак китмәгәнен белгән ана бар байлыгын туплап, күтәрә алганча ризык салынган биштәрен асып, кышкы салкыннардан да курыкмыйча, Суслонгер якларына юлга кузгала. Ул чакта алар яшәгән Апас районы Каратун авылы кайда да, Мари урманнары кайда урнашкан! Йөз чакрымнан артык араны җәяүләп, юлда очраган авылларда төн кунакуна уза ул. Идел аша чыгар өчен ул вакытта тимер юл күпере генә була. Шул күпердән чыгар өчен, улына дип алган дистәләгән йомырканы сакчыларга биреп калдырырга туры килә дәү әниебезгә. Русча бер авыз сүз белмәгән килеш, бер тапкыр да аяк басмаган юллар узып, лагерын да, улын да барып таба ул. Һәм бу кышта тагын алты тапкыр шушы юл газабын кичә – улын күрергә, аннан да битәр ачлыкка тилмергән газизенә мөмкин булганча азык-төлек алып килергә тырыша. Югыйсә улы: «Син киткәч үк, булган ризыгымны талап бетерәләр», – дип әйтеп тора үзенә. Шулай да, Равил абыйның: «Әнкәй, син килгәндә генә тамагым туя, башка чакларда чүплектәге бәрәңге кабыкларына кадәр җыеп ашыйбыз», – дип итәгенә ятып елавын озак еллар искә алып сөйли әле дәү әни. Солдатка киткән баласының ачлык газабын басыйм дип узылган чакрымнар булгандыр инде ул... Алтынчы тапкыр килүендә дәү әни улын очрата алмый. Мондагы изүләргә түзә алмыйча Равил абыебыз үзе теләп сугышка гариза язып китә. Балтыйк буе фронтында сугыша, кыю йөрәкле сапер була. Үзе дә миналар куелган Псков кырларында һәлак була. Нурлыҗиһан дәү әниебез 1944 елның мартында кайгылы хәбәр ала...

Равил абый турындагы истәлекләрне дә, Нурлыҗиһан әбиебез турында да безгә Фатыйма дәү әниебез еш сөйли. Тарихта калсын дип, быел районның «Йолдыз» газетасында Баһаутдинов Равил абыебыз турында язма да бастырды ул. Әлеге язма газета сайтында урын алгач, Равил абый тарихы белән тагын да яхшырак таныш кеше барлыгы ачыкланды. Ул кеше белән танышып, аралашу җаваплылыгын дәү әни миңа йөкләде.

Хәйдәр абый Зәйнуллин белән социаль челтәрдә аралаша башладык. Сугышта катнашып, туган якларына кайтмый калган солдатларны эзләү, алар турында мәгълүматлар җыю белән ул күптән шөгыльләнә икән инде. Равил абый тарихын да җентекләп өйрәнгән. Безгә аның турында шактый күп яңалык җиткерде. Яңадан документларын күтәрде, Равил абыйның батырлыкларын, кайда ничек көрәшкәнен тасвирлап язды, «Батырлык өчен» бирелгән медаль приказының нөсхәсен җибәрде. Хәйдәр абыйның һәр хәбәрен зур дулкынлану белән көтеп тордык. Равил абыебыз җирләнгән хәрбиләр каберлеге урнашкан Псков өлкәсе Новоржевск шәһәренең хакимият башлыгына кадәр чыкты ул! Равил абыйның исеме язылган Мемориал тактаны, солдатлар каберлеген махсус безнең өчен фотога төшереп җибәрделәр.

Әлбәттә, бу тарих гаиләбезне нык дулкынландырды, безнең өчен зур табыш булды ул. Нурлыҗиһан дәү әни гомер буе: «Равил әтисен, исән кайт, дип озатып калды, ә үзенә киткәндә, исән-сау кайт, дип әйтеп калучы булмагандыр», – дип өзгәләнгән. Әнисенең өметләрен аклап, өй капкасын исән килеш ачып кермәсә дә, Равил абый батырлыгы күңелләрдә, сугышның безнең гаиләгә кагылган бер хатирәсе итеп саклыйбыз. Бу тарихны балаларыбызга җиткергәндә, без, беренче чиратта, Нурлыҗиһан дәү әниебезнең солдат улы өчен җан атып, кышкы юлдан алты тапкыр җәяүләп узган Каратун-Суслонгер арасы турындагы истәлекләрдән, ана йөрәгенең чиксез мәхәббәте турында сөйләүдән башларбыз...

Раилә САБИРОВА.
Казан.

***Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru***



**Күпме еллар инде йөретәмен**
**Сине йөрәгемдә,**
**Йөрәгемне каты чәнчү алды**
**Капыл үткән төндә.**
**Әллә авыр кайгың бармы синең?**
**Әллә бармы шигең?**
**Мин курыктым, югалтам дип сине,**
**Йөрәк куйса шиңеп.**

**Мостай Кәрим «Раузага» дип аталган бу шигырен 1956 елда язган. Күрәсең, аның күңелендә Раузасын югалту куркынычы үзен гел искәртеп торган.**

**Хатынына багышланган шигырьләре күп түгел сыман аның. Ләкин бу ике кешене, ул гаиләне якыннан белүче гаилә әгъзасы буларак, андый шигырьләре аз булса да, аның барлык иҗаты Раузасы белән бәйләнгән дип ышандырып әйтә алам. Язмамны шулай дип әйтергә нигез булырлык бер очрактан – алар тормышындагы бик авыр бер вакыйгадан башлыйсым килә...**



Нәзифә
КӘРИМОВА

# МӘХӘББӘТ ФОРМУЛАСЫ

1964 елның матур җәе... Минем булачак кайнанам белән кайнатам Кавказ тауларында, андагы танылган язучы, шагыйрь Алим Кешоковның 50 яшьлек юбилеенда кунак булалар. Бәйрәмнән соң Эльбруска баралар һәм аннан кайткан вакытта юл казасына очрыйлар. Ниндидер бер могҗиза белән генә тарлавыкка төшми калалар. Шофер рульне кискен борып, нарат агачына бәрелә. Машинаның алгы тәрәзәсеннән очып чыккан Рауза йөзе белән ташларга барып төшә. Кайнатай җиңелчә генә яралана, ә Раузасының башында ачык яра, тез сөякләре чәрдәкләнгән, аңсыз... Тырнауз хастаханәсендә аңа операцияне Хәсәнби Каранашев исемле яшь хирург ясый. Операция уңышлы үтә. Мостайның Раузасы аякка баса. Таулар иле белән хушлашканда Мостай Кәрим хирургка: «Сез минем хатынымны гына түгел, иҗатымны да коткардыгыз!» – ди. Әгәр дә ул юл казасы фаҗига белән беткән булса?! Бу турыда уйлавы да куркыныч... Әле бит бу 1964 ел гына. Алда иҗат белән тулы 40 елдан артык гомер бар. Күпме әсәр язылган ул вакыйгадан соң! Димәк, аның һәр әсәре, шигырьләренең һәр юлы, тормышының бар уңышы мәхәббәтенең исән, янында булуына мәдхия, хәтта ул мәхәббәтнең җимешләре дисәк тә ялгыш булмас.

Мостай Кәрим бер истәлегендә: «Миннән еш кына «Нәрсә ул бәхет?» «Нәрсә ул мәхәббәт?» дип сорыйлар. Мин бу сорауны артык гади, бик акыллы булмаган сорау дип атар идем. Чөнки бәхет белән мәхәббәт ул бармак эзләре кебек. Һәр кешедә үзенеке, ул беркайчан да кабатланмый. Кемгәдер бәхет өчен тулы кояш кирәк, ә кемдер бәләкәй генә нур чаткысы белән дә бәхетле», – дип яза.

Мине дә бу гаиләгә мәхәббәт китерде. Мин – аларның бердәнбер уллары Илгизнең хатыны, ике оныкларының әнисе. Шуңа күрә аларның мәхәббәте турында язарга, искә төшерергә шушы язмалык кына булса да хакым бардыр дип уйлыйм. Гомеремнең илле елы бу

## Кем белә, бәлки аларны кайнатамның үз язмышына ишарәләгән билгеләрне таный белүе кавыштыргандыр?

гаиләдә, шуларның утыз биш елы әткәй, әнкәй дип йөрткән кешеләремнең яктылыгында, аларның барлыгын тоеп яшәү рәхәтлегендә узды. Якыннарыбыз инде арабыздан киткәч, күпләребезнең, их, менә моны сорыйсы калган икән, дип үкенгән чаклары байтак. Юклыкларына ышанмаган күңел, киңәшергә теләгәндә дә, нindидер шатлыклы хәбәр белән бүлешәсе килгәндә дә, үзләре инде бакыйлыкка күчкәч тә аларга омтыла. Бер минуттан барысы да искә төшә... Их, дип үкенеп куясың. Мин үзем әткәйдән күп нәрсәне тыңларга, сөйләтергә өлгердем. Язмамның геройлары илле елдан артык бербөтен булып, бер-берсен аңлап, хөрмәт белән, чын ярату, мәхәббәт белән яшәгән кешеләр. Аларның очрашу, беренче күрешүләре турында язылган истәлекләр бар. Ул турыда әткәй бик тәфсилләп сөйләгән иде. (Ә менә әнкәйнең аларның танышу тарихы турында сөйләвен хәтерләмим.) Кайбер әңгәмәләрдә аңа: «Сез инде ничә ел бергә яшисез, туйларыгыз ничек үткән иде?» – дигән сорауны биргәннәрен укыганым бар.

Ул сорауга әткәй болай дип җавап биргән иде: «Безнең бергә яшәүнең төгәл генә әйтерлек датасы да юк. Туйлар да булмады безнең... Ә менә танышу – анысы гәҗәеп бер тарих!»

Әткәй бу тарихны сөйләргә ярата иде. Чөнки язмыш дигән нәрсәнең барлыгын исбатлаган тарих аларның танышуы. Минем кайнатам язмышка ышана торган кеше иде. Әле балачагында ук, абыйсы Мортазаны өйләндергән вакытта ун яшьлек Мостафага Олы әнисе: «Сиңа да маңгаеңа язылганы насыйп булыр, тик кәләшеңне ерактан алырсың ахрысы – каш араларың киң. Берсе – мәгъריпкә, икенчесе мәшрикъка караган», – дип әйткән була. Менә шушы «маңгаеңа язылган» дигән нәрсә аның күңеленә керә дә утыра.

– 1938 елның май ахыры иде, – дип сөйләвен башлаган иде кайнатай. – Әле басылып та чыкмаган поэмам өчен акча түләделәр. Баедым! Базардан өр-яңа чалбар, аз гына киелгән туфлиләр сатып алдым. Өсбаш бөтен булгач, дәрт тә тик ятмый икән... Әнә шул иләс-миләс чакта сабакташ дустым Вафин Закир әйтеп салмасынмы: «Ничава гына егет күренәсең бит әле син хәзер. Шәрип авылында менә синең өчен генә туган бер кыз бар. Укытучы. Киттекме шуны күзләргә?» – диде. Исемен дә әйтте.

Башта бераз югалып калдым. Кыз-кыркын янында йөргәнем юк иде. Шулай да: «Киттек!» – дидем. Төш ауганда без инде Шәриптә идек. Дустымның иптәше дә без кайтуны чамалап торган, ахры. Табынны әзерләгән. Ләкин минем тамактан аш үтми – тизрәк теге кыз белән танышасым килә. Алар өч кыз каршыдагы өйдә торалар икән. Өчесе дә яшьләр, икесе – укытучы, берсе фельдшер. Минем ике күзем тәрәзәдә генә...

Ләкин, кызганыч, алар бу юлы очраша алмыйлар. Чөнки «аның өчен генә туган кыз», каникуллар башлану сәбәпле, Уфага, апасына кунакка киткән икән.

Дустының хатыны башка кызны димли башлый. «Анысы тегесеннән дә матуррак, син бит әле берсе белән дә таныш түгел, нинди аерма бар соң?» – дип үгетләргә тотына. Ләкин «үзе өчен туган кыз» артыннан кайткан Мостай: «Булмагае тагын. Миңа калса, пар канатлы фәрештә булсын! Минем өчен генә тумагач... Үземнекен күрмәс әүвәл ятка күз салу хыянәт түгелмени?» – дип уйлый. Чөнки ул Закирның «Шәрип авылында синең өчен генә туган бер кыз бар», дигән сүзләрен бик нык инанып кабул иткән була. Ул кызның үзен көтмичә китеп барганына әзрәк үпкә сыман бер хис тә барлыкка килә әле күңелендә.

Киткәндә кайнатай кызның Уфадагы адресын сорап ала. Ләкин: «Ярый, барырмын, табармын, ләкин үземнең шушы әрсезлегемне нәрсә дип аңлатырмын?» – дип уйлый да, адресны укып та тормыйча, кәгазьне ерткалап җилгә очыра... Һәм бу хакта: «Менә шулай, бу язда мәхәббәт миннән эзен яздырды», – дип яза.

...1939 ел. Кайнатайның беренче китабы дөнья күрә, ул эшкә урнаша, акча килә башлый. Студентның иң зур хыялы – тулай торактан фатирга күчү хыялы да, ниһаять, тормышка аша. Алар «Отряд кузгалды» дип аталган беренче китабын чыгарган Вәли Нәфыйков белән икәүләп фатирга күченәләр. Ул фатир – Социалистическая белән Достоевский урамнары киселешендәге почмакта урнашкан 47 нче санлы ике катлы агач йортның икенче катында яшәүче Һәдия апаның бер бүлмәсе була. Фатирга урамнан текә генә агач баскыч менә, ишек төбендә бавыннан тарткач чылтырый торган кыңгыравы да була. Кем килгәнен беләсе килгән кеше, өстәге тәрәзәдән карый да, аска төшеп тормый гына, келәгә бәйләнгән бауны тартып, ишекне ача. Ә инде кыңгырау бавын ят кеше тартса, тәрәзәдән башны тыгып, өстән генә: «Сезгә кем кирәк иде?» – дип сорыйлар.

Беренче тапкыр килгәндә, Һәдия апа яши торган бүлмәләрен күрсәтә. Бүлмәдә зур өстәл, икесенә ике караваt куелган була. Менә шунда кунакка килеп йөри башлый инде барлык язучылар. Кайнатай ул хакта: «Дусларым белән кайткач, Һәдия апай юкны бар итеп, барны күп итеп табын әзерли торган иде», – дип искә ала. Минем бу урында Һәдия апа хакында да бер-ике сүз әйтәсем килә. Аның белән мин дә таныш идем. Бик гадел, бераз кырыс, аш-суга оста апа иде ул. Гаиләдә аны «Туган абыстай» дип йөрттеләр.

Менә язмамның иң мөһим урынына да килеп җиттем шикелле. Ул хакта кайнатай бик тәфсилле итеп искә ала: «Утыз беренче декабрь иде. Мин эштән чыктым, тик ул көнне институтка бармадым. Ябалак-ябалак кар ява. Шуңа сокланып, хозурланып өйгә кайтып киттем. Капкадан кергәч тә көзен яфракларын коймый калдырган чия агачы тирәсендә талпынышып уйнаган кар бөртекләреннән аерыла алмый карап тордым.

## Тормышта бернәрсә дә очраклы түгел, диләр. Очрашулар да очраклы түгел. Бу – язмыш.



■ 1943 ел. Сугышка китәр алдыннан. Иң авыр көннәр. 1942 елда уллары Илгиз туган булса да, алар әле һаман да язылышмаган. Менә шушы кайтуда Мостай: «Сугышта үлә-нитә калсам, баланың әтисе дигән графа буш булыр», – ди, һәм алар язылышалар. Сугыш дәһшәте, аерылу кайгысы, ниндидер шом аларның йөзләренә чыккан...

Башны күтәрми генә кыңгырауның бавын тарттым. Өстә ишек ачылып ябылды, ләкин келә күтәрелмәде.

– Сезгә кем кирәк иде? – диде миңа ят булган бер яңгыравык тавыш.

Менә шушы тавыш мине кинәт кенә урады да алды... Мин дерт итеп, башымны югары күтәрдем. Тәрәзәдә кара-кучкыл йөз балкыды. Балкыды да сүрелде. Ярым каушап, ярым шаярып:

– Сез кирәк, төшегез монда! – дип әйтеп салдым.

Келә һаман ачылмый.

– Сызгыра белсәгез, сызгырыгыз! Сызгырсагыз төшәм! – диде дә кызыкай, матур борынын җыерып, елмаеп куйды.

Мин гомергә сызгырырга өйрәнә алмаган кеше.

– Сызгыруын сызгырмам, тик гәүдәгезне күрсәм, менә шулай суырып алырмын! – дип, иреннәремне бөрештереп һаваны суларга керештем.

Келә келт итте, мин баскычтан югарыга үрмәләдем. Ләкин, нигәдер, озак мендем. Йөрәгем ашкына иде бит, нигә шулай әкрен кыймылдадым икән... әле һаман да аңламыйм...»

Фатир берничә бүлмәле була. Ул баскычтан менгәнче, ишек ачкан кыз бүлмәсенә кереп китәргә өлгерә. Ә зур бүлмәдә кайнатайның әтисе Сафа бабай белән бертуган энесе Ильяс авылга кайтып китәргә әзерләнәләр икән. Алар авылдан азык-төлек китергән булалар.

Капчык авызын бәйләргә дип Сафа бабай теге ишек ачкан кызны чакырып чыгара. Кызның сүс бау белән оста итеп капчык авызын бәйләгәнен карап тора да:

– Афәрин, сылу кызыкай! Кулың эшкә килешеп тора! Миңа синең капчык авызын бәйләвең хаҗәт түгел, эшкә ничек тотынганыңны күрәсем килгән иде! – ди.

Авылныкылар юлга кузгала. Һәдия апа исә әле эштән кайтмаган. Өйдә алар икәү генә кала. Кайнатай бу тылсымлы минутлар турында болай дип яза:

«Танышыйк әле. Минем исемем Рауза!» – диде кыз, кулын сузып.

Мин аның кечкенә кулын учыма алдым.

– Рауза? Шәриптәнме?

– Ничек инде ул: «Шәриптәнме?» – Ул кулын тартып алды.

– Шәриптән! Сез ишек ачканда ук күңелем сезне таныды.

– Әйе, былтыр мин анда укыттым... Һәдия апа сөйләдеме?

– Ул сөйләмәде... үзем... Узган ел дустым Закир Вафин мине Шәрипкә сезнең белән танышырга алып кайткан иде. Ә сез Уфага китеп баргансыз... Мин ифрат боектым. Күрмәсәм дә, үзеңә гашыйк булып киттем. Дөрес эшләгәнмен икән».

Хәзер инде шунысын да әйтергә була: Рауза, чыннан да, Шәрип авылында Мостай очрата алмаган, ул чакта Уфадагы апасына кунакка киткән кыз булып чыга. Һәдия апа белән Раузаның әтисе Суфиян бертуган булалар. Менә шулай очраша алар.

Шушы очрашудан соң алар, сугыш елларын санамаганда, гомер буе бергә. «Бу очрашуга без гаҗәпләнмәдек тә кебек, – дип яза кайнатай. – Шәриптә аймыл булуыбызга торып-торып исебез китте. Инде байтак еллар узгач та, әгәр дә Уфада гына очрашкан булсак, Шәрип тарихы булмаса, бәлки, безнең очрашу исәнмесаумыдан артып китмәгән булыр иде, дип уйлыйм. Чөнки ул вакытта Раузаның күзе төшеп йөргән егете булган. Ә менә минем Шәриптә «үземә дигән насыйбы булмагач, башкасы кирәк түгел» дип, бүтәннәр белән танышудан баш тартуым Раузага тирән тәэсир иткәндер. Нәкъ илле ике ел без бергә, бу могҗиза түгелмени?!» Бу юлларны ул 1990 елда яза.

Әнкәй бакыйлыкка күчкәч, әткәй тагын өч елга якын яшәде. Гаиләдә әнкәй һәрвакыт беренче урында торды безнең. «Менә әнкәгез нәрсә әйтер?», «Әнкәгез генә килсен әле!» – дип, безне «куркыта» да торган иде әле. Каләменнән төшкән әсәрләре иң башта Рауза кулында булды. Раузасы аның беренче укучысы, беренче редакторы, беренче тәнкыйтьчесе дә! Ләкин кирәк вакытларда әткәй үз сүзен өздереп әйтә дә торган иде. Алар – бер-берсен хөрмәт итеп, мәхәббәт, ышаныч белән яшәгән гаилә. Әнкәй беркайчан да гайбәт тыңламаган. Ирең тегеләй, ирең болай дип, сүз ташучыларны ярты сүздә кисеп, үзеңне генә бел дип, кире бора торган булган.

Аларның тормышы башланган ике катлы агач йорт турында язуым да юкка гына түгел. Анда язмышка ишарә ясаган байтак кына мизгелләр бар. Уфадагы ул урам бүген Мостай Кәрим исемен йөртә, хәзерге көндә аның урынында күп катлы йорт торуга карамастан, йорт саны да элеккегечә калган – 47 нче. Аннан ерак түгел әткәйгә – Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәримгә куелган мәһабәт һәйкәл бизи ул урамны. Шулай итеп, мәхәббәт тулы тормышы кайдан башланса, бүген дә шул урамда халкының да мәхәббәтен казанып басып тора ул.

**2020 елның** икенче яртыеллыгына **«Сөембикә»** журналына язылучылар арасында бүләкләр уйнатырга вәгъдә иткән идек. Ул көн килеп җитте, җиңүчеләребез билгеле булды!

Бүләк уйнату чарасында «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятеннән вәкил – Альбина Сабирова, иң яшь укучыларыбызның берсе – Рәфидә туташ Галимҗанова, редакция хезмәткәрләре дә катнашты. Әлбәттә, бу чарага редакциягә килеп журналга язылучыларыбызны да, күп еллар инде безгә тугры калган укучыларыбызны да чакырасыбыз килгән иде. Әмма замана шартларында болай эшләү мөмкин түгел икәнлеге ачыкланды. Шуңа күрә без барысын да видеога төшереп, инстаграмдагы сәхифәбезгә урнаштырдык.






**БҮЛӘК ОТУЧЫЛАР:**

**1. Равил Нурисламов.** Саба районы (үлчәү).
**2. Шәфкать Фәтхетдинов.** Әлки районы (үлчәү).
**3. Али Сәмигуллин.** Казан шәһәренең 2 гимназия укучысы (электр белән эшли торган коймак табасы).
**4. Нәсимә Шаһиева.** Минзәлә районы (электр белән эшли торган коймак табасы).
**5. Миләүшә Зарипова.** Арча районы (блендер).
**6. Лилия Купаева.** Әлмәт районы (блендер).






Җиңүчеләребезне чын күңелдән котлыйбыз, безнең бүләкләр тормышыгызга шатлыклар гына алып килсен!
Бүләк отмыйча калган дусларыбызга да күңелсезләнмәскә киңәш итәбез! Киләсе конкурсларыбызда нәкъ менә сезгә бәхет елмаер әле! Һәрвакыт бергә булыйк, өегезгә зур бүләк булып һәр ай саен «Сөембикә» килеп торсын!

# АРТИСТЛАНА БЕЛМӘГӘНМЕН

Һәркем үз язмышы белән туа. Берәүләрнең тормыш юлы озын һәм туры, икенчеләрнеке – сикәлтәле... Нинди генә булса да, аны үзебезгә үтәсе – шулай язылган. Шул юлны узганда егылып салынган яралар тормыш тәҗрибәсен баета, яшәргә өйрәтә икән...

Фото: Анна Арахамия

Сабый чактан ук артык дөрес, бик тәртипле идем. Олы бала булганга, энеләремне карау, әти-әниемә булышу кечкенәдән төп вазыйфама әйләнде. Мәктәптә яхшы укыдым. Укытучылар мине башкаларга үрнәк итеп куйды. Тик утыздан артык бала арасында бер мин генә читтән торып укырга кердем. Ә бит мәктәпнең президенты идем! Алдан сөйләшергә, кемгәдер нәрсәдер «төртергә» кирәк булган... Югыйсә әти-әниемә: «Танышыбыз ярдәм итәчәк, акчагызны әзерләгез», – дигәннәр иде. Ә мин, беркатлы үсмер, ризалашмадым. Үз көчем белән керәм, янәсе. Беренче зур югалтуым – шул. Ул вакытта үземне дөньядагы иң бәхетсез кеше итеп тойдым. Дөньяның асты-өскә әйләнде... Шулай да үз хыялыма тугры калдым, теләгән һөнәремне үзләштердем, бик яхшы җирдә эшли башладым.

Шәхси тормышта да кояш гел елмаеп торды. Биш ел буе яратып йөргән егетемне армиядән көтеп алып, кияүгә чыктым! Мин аны бик ярата идем! Беренче танышкан көнне үк дискотекада сугышканына исакылым китеп аптыраган булсам да, йөрәгемә әмер бирә алмадым. Үзгәрер, гел болай булмас әле дип уйладым. Хәзер, еллар үткәч аңладым: кешенең холкы үзгәрми икән. Яраткан кешеңнең яхшы якларын гына күрәсе килә бит ул. Тормыш көтәр өчен үҗәтлеге, тырышлыгы бар, димәк, ир ышыгында гына яшәячәкмен дип өметләндем. Бер елдан соң улыбыз туды. Бөтен җылым, бар назым, игътибарым балада булды. Беренче сабыем бит! Шулай булырга тиеш дип уйладым. Берәрсе: «Ирне дә онытырга ярамый, ул да, бала кебек, игътибарга мохтаҗ», – дип ник киңәш бирмәде икән?! Аралар суынды. Балага алты ай булганда, икебез ике тормыш белән яши башладык. Бала янына килеп йөрде ул, ә үзебез чит кешеләргә әйләндек тә куйдык. Бер елдан аерылыштык...

Әти-әни янында булгач, ялгызлыкны тоймадым да. Улым бик тыныч, акыллы бала булып үсте. Аның өчен яшәдем, аның өчен суладым. Балага бер яшь ярым тулгач, декрет ялымны озынайтыр өчен Казанга киттем. Кайтуыма, улымның аркасында сәер шеш барлыкка килгән иде. Әнием белән бик аптырадык. Бәрелмәгән, сугылмаган... Йөрмәгән табиб, бармаган им-томчы әби калмады. Хирурглар бертавыштан, операция ясарга кирәк, ди. Әбиләр: «Сихер бу», – дип чаң суга. Операцияне октябрь аена билгеләделәр. Менә ул көн. Баланы чишендереп, одеялга төрергә куштылар. Шәфкать туташы наркоз ясады. Кечкенә улым йокы аралаш нидер сөйли... Бу минутларда йөрәгемнең өзгәләнгәнен үзем генә беләм. Улымны операция бүлмәсенә алып

киттеләр. Анда барырга ярамаса да, елый-елый артларыннан иярәм. Качып-посып операция ясый торган катка менәм. Ә анда конвейер... Әле бер, әле икенче сабыйны чыгаралар да каршыдагы реанимациягә алып кереп китәләр. Бу балалар да бит кемнәрнеңдер нарасыйлары... Көтәм... Вакыт тукталган кебек... Шунда гына мин авыр чакларда вакытның бик әкрен узганын аңладым. Мондый мизгелдә кешеләр Аллаһы Тәгаләгә сыена, мин дә барлык догаларымны укып Аңа ялварам: «Йа, Раббым, зинһар өчен, улымны сакла! Зинһар өчен, операция уңышлы гына үтсен». Операция өч сәгать барды. Эченә яткырып, авызына әллә никадәр трубкалар куелган улымны алып чыктылар да реанимациягә алып киттеләр. Мине палатага куып төшерделәр. Бераздан коридорда: «Әнием! Әнием!» – дип елаган бала тавышы ишетелде. Улым! «Шеш бик зур иде, тирән киткән, тамырларын казып алдым, яңадан чыкмас дип өметләнәм», – диде табиб. Гистология нәтиҗәләрен көтү аеруча кыен һәм озак булды (вакыт бик әкрен уза шул!). Яман шеш кенә булмаса ярар иде дип теләдем. Аллага шөкер, бар да әйбәт иде.

Улым әкренләп тернәкләнде, ул көннәр дә акрынакрын гына онытылды. Аңа ике яшь тулганда үсмер чактан ук бер-беребезне белгән бер егет белән аралаша башладык. Ярты елдан соң кавышырга булдык. Аның әти-әнисе башта каршы килсә дә (мин бит аерылган, балалы хатын!), соңыннан ризалаштылар. Кулымны сорарга килгәч тә әнием: «Баланы чит итмәсәң генә риза», – дип, фатихаларын биргән иде. Какты дип әйтә алмыйм. Шулай да ике ут арасында яшисең икән ул. Ялгызы бүлмәдә утырган улыма: «Әйдә, чык залга, бергә уйныйк», – дим, ә ул чыкмый. Иремә: «Баланы чакыр инде», – дип әйтәм, ә ул: «Үзе чыгар әле, ник мин аны көчләп чыгарыйм», – ди иде. Бу сүзләрне үз әтисе әйтсә, йөрәк болай янмас иде, үги әтисеннән шундый сүз ишетү яралы күңелгә бик авыр тоела иде ул чакта. Сабыем да кызганыч, ирем алдында да үземне гаепле тоям. Бала белән килдем бит! Үз башыннан кичергәннәр генә аңлар мине. Йөрәк өзгәләнгән чаклар күп булды. Аннан кызыбыз туды. Ирем бала җанлы булды. Алар өчен акчаны да, вакытын да кызганмады. Кызыбызны аеруча нык яратты. Улымны да җәберләмәде. Мин шуңа риза идем...

Әмма бу юлы да бәхетле гаилә булып яшәргә язмаган булып чыкты... Ул беренче иремнән көнли башлады. Бер генә көн дә аны искә алмыйча үтмәде. Гомумән, өчәү яшибез кебек тоелды. Югыйсә аралашканым да, күрешкәнем дә булмады. Ул бала янына да әти-әнидә булганда гына, алар белән сөйләшеп кенә килә иде. Башта иремнең көнчелеген кызыкка борырга тырыштым, аннан ишетмәмешкә салыштым... Элеккеге иремнең эше яныннан үтеп киткәндә: «Әйдә, янына кертеп калдырам!», «Нормаль кешенең туе бер генә булырга тиеш!» кебек кимсетүләрне колак аша гына уздырып җибәрү бик авыр шул. Бу сүзләрдән, нахакка рәнҗетелүләрдән тәмам туя башладым. Ирем белән өч ел яшәгәннән соң, уртак тормыштагы якты киләчәккә

**Бар назымны, игътибарымны балага гына бирү зур хата булган икән. Ирем белән арабыз суынды.**

өметне өзеп, ике баламны җитәкләп әти-әнием өенә кайтып кердем. Кеше нәрсә әйтер, туганнар, дуслар ничек кабул итәр дип уйлап яндым. «Син, нәрсә, икенче тапкыр да аерылдыңмы әллә?» – дип бик еш сорап йөрәкне телгәләделәр. Түздем, тыштан булса да игътибар итмәскә өйрәндем. Бик ябыктым, чиргә сабыштым. Иремнең судка барып гариза язганына да бик гарьләнсәм дә, сиздермәдем. Суд юлын күп таптарга туры килде әле. Аның ипотекага алган фатирына «ана капиталы»мны салган идем. Ул акчаларны кайтара алмасам да, сабыр иттем. Хәтта кире кайтырга да риза идем. Аның килүен көттем. Тик ул бик тәкәббер кеше. Килмәде...

Инде бу вакыйгалардан соң алты ел үтте. Ялгыз яшәргә дә өйрәндем. Аллага шөкер, балаларым үсеп буйга җитә. Бөтен барлыгым белән балалар дип яшим. Бәхетле булсыннар, кимсенеп яшәмәсеннәр дип тырышам. Улым бик яратып хоккей белән шөгыльләнә. Инде шактый уңышларга иреште. Яхшы уйнавын күреп, яшүсмерләр хоккей клубының төп составына алдылар. Тренерлар зур өметләр баглый. Баламның киләчәге хакына тыныч кына аккан тормышымны үзгәртеп, сабыйларым белән башка шәһәргә күчендем. Әти-әни, туганнарым ярдәме белән ипотекага фатир алдым. Юлыбызда һәрвакыт яхшы күңелле кешеләр очрап тора.

Минем тормыш тарихым күпләрнеке белән аваздаштыр да. «Рәхәткә чыдамаган, түзмәслек ирләр булмаган берсе дә», – диючеләр дә булыр. Ләкин мин шулай хәл иттем. Димәк, миңа шулай язган. Мин үземне бәхетсез хис итмим. Ике ирем дә начар иде, алар аркасында бәхет таба алмадым дип тә әйтмим. Мин дә гаепле: артык таләпчән, артык дөрес шул. Тормышка җиңелрәк карарга кирәк иде. Яши-яши авызым пешкәч кенә аңладым: хатын-кыз тормышта артист булырга тиеш. Ул сәхнәдә уйнаган кебек уйнасын да, үзенә булган алкышларны лаеклы кабул итә дә белсен.

Үземне очып баручы кош белән чагыштырам. Әмма бер канатлы кош. Сыңар канат белән очу авыр, әлбәттә. Янәшәңдә ышанычлы сөйгән кешең булса, яшәве рәхәтрәктер ул... Кем белә? Бәлки, алдагы тормышымда мин дә пар канатлы булырмын. Элегрәк, беркайчан да кияүгә чыкмыйм, дисәм дә, яшь барган саен фикер үзгәрергә дә мөмкин. Балалар үсеп, үз тормышлары белән яши башлагач, мин бит япа-ялгыз калачакмын. Хәзер түгел, пар канатлы булу шул вакытта кирәктер. Бүгенге көндә юлымда очраган бар нәрсәне ничек бар шулай кабул итеп, балаларым, әти-әнием, туганнарым бар дип, булганына шөкер итеп яшим. Алга таба очам...

Исемем редакция өчен генә.

PRESSA

# БЕЗ БЕЛГӘН ҺӘМ БЕЛМӘГӘН БАШКОРТСТАН



Зәлия АХУНОВА

Урманнар, шарлавыклар, мәгарәләр, күлләр, кыя-таулар! Табигать могҗизалары! Һәм әллә кайда да түгел – кул сузымында гына. Үзебездә, Башкортстанда! Бар дөньяның астын-өскә китергән үзгәрешләр гади кыйммәтләрне искә төшерергә мәҗбүр итте кебек... Матурлык эзләп ел да әллә кайларга чыгып киткәнбез, ә янәшәдәгесен нигәдер күрмәгәнбез. Быел күп якташларның кинәт күзләре ачылгандай булды. Матур фотосурәтләр турында хыялланган блогерлар да, табигать кочагына әләгүне бәхет санаган шәһәр халкы да, яралы җанына дәва эзләүчеләр дә – барысы да үзенә урын таба ала икән бит монда. Башкортстан, аның искиткеч табигате белән ирем күптән таныш. Үсмер чагында ук кышкы-җәйге яллар-да өйдә утырмаган ул: республиканы аркылыга-буйга йөргән. Һәр почмагын белә! Алай гына да түгел, Урал тауларыннан соң Памир, Тянь-Шаньга чаклы барып җиткән! Яшермим, аннан көнләшүем күптән бар иде инде. Шуңа күрә быел Яңа елдан соң үземә бер еллык план төзегәндә, анда «Туган якны өйрәнергә!» дигән пункт-ният өстәлде. Ә пандемия ул хыялның чынга ашуын тизләтте генә.

***Баймак***

Әйе, теләк-ният зур көч – җиһанга тиз барып җитә! Ахирәтем – рәссам, композитор, автор-башкаручы Флера Шәрипова табигатькә гашыйк кеше. Ул мине дә туып-үскән якларын күреп килергә чакырды. Безгә Казаннан иҗатташ дустыбыз, җырчы Алсу Әбелханова да кушылды.

Киттек Баймакка! Юллар тауга бер менә, бер төшә, әле уңга борыла, әле сулга... Бетмәс-төкәнмәс урман белән капланган таулар! Барабыз шулай җырлашып, күңелгә бик ошаган матур урыннарда тукталып алабыз... Үзем дә алдан белешмәгәнмен, әйтмәделәр дә – юлның озынлыгы 500 чакрым икән бит! Рульдә булгач, арырга тиеш идем кебек – сизмәдем. Аның каравы, барып җиткәндә чыршы белән карагачны, нарат белән карагайны аера башлаган идем инде.

«Башкортстанда яшәүчеләр бу җирләрне килеп күрергә тиеш! Юк, алай гына да түгел – һәркем күрергә тиеш!» Баймакка аяк басуга шундый фикергә килдем. Мондагы матурлык! Табигать төрледән: кыяташлы, чыршы-карагайлы, имән-каенлы, ташлыкуаклы... Һәм алар арасында ат көтүләре йөреп тора (көтүчесез!): берничәсенә кыңгырау да тагылган, ә яннарында – колынчыклар! Алары – үзе бер дөнья! Алтын таба торган ачык карьерлар күп. Хәтта көз көне үрдәк-каз бүтәкәсеннән дә алтын чыга дип сөйлиләр монда. Күз алдыгызга китерәсезме Баймактагы байлыкны?! Юлларына кадәр затлы яшма ташыннан түшәлгән бит аларның!

Иң элек Ирәндек тау сырты буенда урнашкан Талкас күлендә тукталдык. Озынлыгы дүрт чакрымга сузылган, вулкан процесслары барышында барлыкка килгән бик борынгы күл ул. Бер башыннан икенче яр күренми, дулкынланып, әллә кайдан үзенә тартып тора. Килеп тә җиттек, кызлар бер-бер артлы күлгә кереп тә киттеләр, ә мин яр буенда басып калдым. Суыкны яратмыйм, тик суык мине бик ярата: саба җиле искәннән дә тамагым шешеп чыга. Күлнең суы миңа коедагы кебек чиста һәм бик салкын тоелды... Флера: «Талкас күленең суы искиткеч файдалы, моңарчы беркемнең дә чирләгәне юк әле!» – ди. Батырланып кергән идем – йөрәгем туктый язды... Суык! Әмма әкияттәгедәй матурлык, курку һәм шатлык бергә кушыла. Беркайчан тоймаган рәхәтлек! (Алгарак китеп булса да әйтәм, чирләү түгел, төчкермәдем дә!)

Икенче көнне Сибай шәһәреннән 15 чакрым гына ераклыкта булган Гаделша шарлавыгына юл тоттык. Үз гомеремдә моңарчы бер генә шарлавык күргәнем бар иде минем – Американың Ниагара шарлавыгын. Гаделша – Башкортстанның иң зур шарлавыгы санала. Өч каскадлы ул, гомумән алганда, биеклеге 15 метр. Иң матур чагы яз көне була диләр. Машина белән бардың да карадың, сокландың, фотога төштең түгел әле монда. Башта Флераның апасы белән җизнәсе, урман эчендәге үзләре генә белгән юлны күрсәтеп, машиналары белән ничәдер чакрым алдан бардылар. Борылыш арты борылышлардан гына торган юл булды ул. Аннан җәяү атлый башладык һәм гел өскә мендек! Куе урманлы тау, чишмәләре дә очрый, тирә-юньдә мүкле таш та таш... Кинәт алда яңа күренеш ачылды: без бик биек кыяда басып торабыз лабаса! Матурлыкка сокланудан йөрәк кысыла... Кемдер: «Кыя башына басып кычкырсаң, эчтә җыелган бер үпкә-рәнҗеш тә калмый икән. Әйдәгез, без дә кычкырып карыйбыз!» – дип тәкъдим итте. Барысы да күпме булдыра ала, шуның кадәр каты итеп кычкырды. Чират миңа җитте... Кычкыруның ние бар инде диярсез, тик тәҗрибә булмагач, бер аваз да чыгарып булмый икән ул. «Кызлар, минем барысы да әйбәт, берәүгә дә үпкәм юк, болай да бәхетлемен... Миннән булмый!» – дим. Алсу белән карашларыбыз очрашты... Без инде 20 еллап бер-беребезне беләбез, әйтмәсә дә аңладым – миңа да кычкырырга кирәк. Еракка һәм түбәнгә карап, ниһаять, кычкыра алдым! Чыннан да бик җинел булып китә икән... Сине эчтән тырнап торган бөтен борчу-куркулар чыга төсле. Үземнең генә түгел, ахирәтемнең дә күзендә яшь иде бу минутларда...

Ә без әле тагын да өскә күтәреләбез. Барган саен су тавышы ныграк ишетелә һәм берзаман алдыбызда күз явын алырлык могҗиза ачыла! Гаделша шарлавыгы! Өстән кояш нурларында коенып ашыгып агып төшә дә, бәләкәй генә күлчектә әйләнеп куя, аннан иренеп кенә зур ташлар арасыннан тагын аска – урман эченә юл ала... Кечкенә генә күлендә су коенып, шарлавыкның моңына күмелеп, кабатланмас мизгелләрне күңелләргә сеңдереп утырдык... Могҗиза, чын могҗиза түгелмени бу!

# Баймак халкының сөйләшүенә кадәр затлы: бик йомшак, моңлы, җылы...

Шул ук көнне тагын бер кабатланмас урынны күрергә насыйп булды безгә – Мөҗәвир (Сарыташ) тавын! Тау итәгенә бөек фикер иясе, галим Мөҗәвир хәзрәт җирләнгән. Аның турында бик күп риваятьләр сөйлиләр. «Шәп кеше иде Мөҗәвир хәзрәт. Көлдерепкөлдереп сөйләшеп утырыр иде, синең ни уйлаганыңны белеп утырыр иде. Кешеләрне яратты, үзенә төбәп килгән һәркемне җылы каршылады, хәленнән килгәнчә ярдәм күрсәтте. Күңеле киң, өе иркен, нияте изге, зар-интизар булып килгәннәргә, бала-чагага мәрхәмәтле булды», – диләр. Ул биргән киңәшләр дә гел телдә: «Кеше сүзен ишетмә – эт өрер, бүре йөрер. Үз-үзеңне генә бел – юк-бар өчен көяләнмә. Яхшылык иткәнгә начарлык кылма. Яманнардан ерак йөр». Мәңгелек киңәшләр!

Тауга менгәндә нииндидер җиңеллек тоясын, арымыйсың. Икенче дөньяга килеп чыктыкмыни: ташлар табигый түгел кебек. Алар барысы да бертөрле урнашкан һәм өстән бик көчле ут белән яндырылып шомар-

Автор фотолары

Көтү-көтү атлар йөреп тора,
учак урыннары тезелеп киткән…
Бәллүр һава!









тылган кебек дип әйтимме. Кояш батканчыга кадәр таудан төшәргә кирәклеген әйткәч, тоткарланмадык.

Баймак ягы – кымызлы, баллы кунакчыл як. Ахирәтемнең бертуганы Флорида апа үстергән помидорларның тәме дә һаман да тел очында. Шулай түгәрәк өстәл янында аралашып утырганда ниндидер кызыклы фикерләр туа, моңарчы гадәти тоелган әйберләр яңа төсмер ала, күңелне Галәмгә, Аллаһы Тәгаләгә, Табигать-анага рәхмәтле булу хисе били…

## *Арташ*

Елның һәр фасылы матур, әмма җәйне күңел барыбер нигәдер ныграк көтә – чөнки бу чорда гаилә һәм дуслар бергәрәк җыела. Җиләк-җимешле, чәчәкле бакчада, самавыр чыжлап торган өстәл янында, учак кырында сөйләшеп утырумы ул, авылга кайтып дәү әнигә бергәләшеп ярдәм итүме, диңгез буйларына барып башка илләр күрүме – һәммәсе берләштерә. Җәй якынайта!

Менә тагын дуслар Белорет районында урнашкан турбазага бергәләп ял итәргә чакыргач, шатланып риза булдым. Өстәвенә, Баймакка баргандагы юллардан үтәсе! Яратам юлларны: алар ниндидер серле – барлык уй-фикерләреңне тәртипкә сала кебек…

Сәфәргә улым белән икәү кузгалдык. Бу юлы юлда колонна белән барырга өйрәндем, аның үзенең кагыйдәләре бар икән. Мәсәлән: колоннаның иң башында булган машина башкаларны көтеп тормаска да мөмкин, әмма борылышларда барыбер туктый һәм көтә. Калганнар парлашалар: парның алдарагы «обгон»га чыгарга уйласа, «койрыгын» – колоннада үзеннән артта барган машинаны да онытмаска, арага аны да «сыйдырырга» тиеш. Миңа иң ошаганы ялга тукталган вакытлар булды. Һәр гаилә аерым конторкаларда (махсус өстәлләрдә) ризык әзерли дә (җиләк-җимеш, бутербродлар, татлы ризыклар), аннан аны бербереснә таратып чыга. Үзеңне бер гаилә итеп тоясың!

Янәшәндәге кешене юлда гел яңа яклардан ачасың. Улым да инде үсеп, ир-атларча уйлый башлаган икән бит минем! Күңелгә соклану, горурлык тулды! Бик данлыклы «тещин язык» дигән кискен борылышта нигәдер машинамның двигателе «кычкыра» башлаган кебек тоелды: тартмый гына. Уйлыйм: мае алыштырылган, техник яктан яңа гына каралган, дүрт приводы да эшли – нәрсә булды бу? Куркуыма тагын да шик өстәп, тимер атымның спидометр дисплее кыпкызыл булды – инглиз теленда бик күп язу чыкты. Ун яшьлек улым тиз генә укыды да: «Трансмиссиягә көч килгән, әкренрәк барырга куша», – диде. Соңыннан аңлаттылар: Магнитогорск юлы магнитлы икән, җирнең машинаны үзенә шулай тартуы булган ул. Һәм бу монда гел булып тора торган хәл икән.

Турбаза безне агачтан эшләнгән уңайлы өйләре, балалар уйнар өчен алсу төскә буялган замоклары белән каршы алды.

Үзебезгә пешерергә урын булса да, вакытны сарыф итмәдек: төшке ашны ашханәдә генә ашадык та, Арвякрязь тавына барырга кузгалдык. Тауның исеме







ике елга исеме кушылып ясалган: Арвяк (анысын «әрвах» сүзенә охшатып истә калдырдым) һәм Рязь. Уралтау сыртының иң биеге икән ул, биеклеге – 1068 метр. Балалар белән бергә һәммәбез 17 кеше идек, шулар арасында үземне иң куркагы дип аңладым, чөнки гел артта калам... Башта аяк куярга урын эзлисең, аннан кайда ныклап тотынырга. Куркыныч! Ә тирә-якта шундый сихри матурлык! Бик кыйммәткә сатып алып, бакчамда өф-өф итеп кенә үстергән чәчәкләрне менә кайдан алып кайтып үрчеткәннәр икән! Ничек инде аларны фотосурәткә төшермисең ди?! Ә фотоаппарат рюкзакта! Туктап аны алганчы, чатнап ябышып «басып» торырга уңайлы урын тапканчы, төшергәнче, беләсезме күпме вакыт уза?! Билгеле, артта каласың! Ул көнне алган тәэссоратларны сөйләргә сүзләр җитми: бу мизгелләрнең күбесе фотосурәтләрдә сакланып калды.

Ә кич көне буе күргәннәрнең барысын да кабат-кабат искә төшереп уздык: пылау пешердек, самавырдан туйганчы чәйләр эчтек, мунча кердек... Сөйләшүләр гел туган якның матур урыннары, спорт, гаилә һәм балалар турында булды...

Икенче көнне Крака сыртына юл алдык. Машиналар белән маршрут башына килеп туктыйсын – матур! Менә башлыйсың: йөрәк һуштан язып тибә, үпкә тулы күкрәккә эшли, тирә-якка карыйсың – искиткеч матур! Иң биек урынга – 1038 метрга менеп басасың: тагын да матуррак! Бик еракта бер авыл күренә... Болытларның күләгәләре йөзә... Сабан тургае, юк, баш очында түгел, ә кайдадыр астарак сайрый... Дулкынланып кылган «йөгерә» һәм, ураааааа!!! Телефонда «МТС» дигән язу килеп чыга! Интернеееет тота!

Бу көнне Арташ кыясы янында – Агыйделдә су коендык. Кайтышлый Архангель районында, Инзәр елгасы ярында урнашкан Асы Көзге шарлавыгына тукталдык. Биеклеге алты метр булган шарлавык текә кыялы ярдан Инзәр елгасына коя. Җәй көне ул кибеп бетә яза икән, шуңа да ерактан бу кыя көзге кебек күренә. Машина куярга һәм ризык әзерләргә махсус урыннары бар, суы бик тирән түгел, җылы. Безгә тагын ни кирәк?!

Көннәр җылы торса, барыбыз да сәламәт булсак, барыр җирләр бик күп бездә! Ирәмәл, Айгыр тавы; Караташ, Мәмбәт кыялары; Кандра, Калкан, Зәңгәр күлләр, Ачылыкүл, Яктыкүл; Салават, Аскын Боз мәгарәләре, Шүлгәнташ; Атыш, Күк Караук шарлавыклары; Морадым тарлавыгы, Нөгеш, Аркаим... Барысын да күрәсе килә!

Күңел оча... Һәм ниндидер сихри җылылык, энергия белән тула кебек. Шул җылылык, самимилек, җиңеллекне бар җиһанга таратасы, бөтен кеше белән бүлешәсе килә. Күзләр елмая – алардан бәхет нурлары бөркелә. Иннәреңдә әйтерсең лә канатлар... Тормышның сынауларын җиңеп чыгып, бар хыял-максатларыбызны чынга ашырырлык көч иңә кебек. Һәм бу көчне, бу илһамны безгә туган җиребез – Табигать-Ана бирә!

Уфа шәһәре



**Әлеге кыенлык белән хатын-кызның күпчелеге очраша. Карап торышка, чир дә түгел үзе, әмма ай саен берничә көнгә эшкә сәләтсез итә торган халәт бу. Ханымнарны гына түгел, яшүсмерләрне дә аямаган дисменорея күренеше хакында Республика балалар клиник хастаханәсенең югары категорияле акушер-гинекологы Лилия ХӘЙРУЛЛИНА белән сөйләшәбез.**

# ДИСМЕНОРЕЯ – ХАТЫН-КЫЗЛАР БӘЛАСЕ

Дисменорея ул хатын-кызларның, шул исәптән яшүсмер кызларның күрем циклы бозылу, күремнең бик авырттырып килүе. Әлеге проблема медицинага гына түгел, социаль-икътисадый өлкәгә дә кагыла, чөнки дисменорея күзәтелгән хатын-кызларның 30 проценттан артыгы ай саен берничә көнгә эшчәнлеген югалтып тора. Кызларның уку калдыру сәбәпләре арасында да ул беренче урында.

**Сәбәпләре:**

бүгенгә кадәр дисменореянең килеп чыгу сәбәпләре ахыргача ачыкланмаган. Бер сәбәп итеп, эндеметраль күзәнәкләр таркалганда барлыкка килүче простагландиннар карала. Простагландиннар аналыкның кыскаруына китерә. Ә икенчел дисменореянең сәбәбе төрле ялкынсынулар, эчке җенес әгъзалары авырулары булырга мөмкин.

**Дисменореяның билгеләре:**

- эчнең аскы ягында тулгак сыман авырту тою;
- эчнең аскы ягын тарту;
- кайчак авырту билгә дә бирергә мөмкин;
- эчнең авыртуы күрем килергә 1-2 көн кала башлана;
- баш әйләнү яки баш авырту күзәтелә;
- температура күтәрелүе ихтимал;
- тунү, кул-аяклар оюу, йөрәк чәнчү кебек билгеләр булырга мөмкин.

✓ **Профилактика максатыннан:**

- актив тормыш рәвеше;
- витаминнарга бай ризык белән туклану;
- яман гадәтләрдән арыну;
- җенси юл белән күчүче авыруларны кисәтү;
- эчке оча сөяге органнарында күзәтелгән ялкынсынуларны үз вакытында дәвалау.







**Ничек ачыкларга:**

- дисменореяне башка җитди чирләр белән бутамас өчен, авыртуның интенсивлыгы, характеры, даимилеге билгеләнә;
- бактериологик тикшеренүләр өчен гинекологик күзәтү ясала. Әлеге тикшеренү башка төрле чирләрнең, ялкынсынуларның барлыгын-юклыгын ачыклау өчен дә кирәк;
- кече оча сөяге органнарына УЗИ ясала;
- аналыктагы башка төрле патологияләрне кисәтү максатыннан гистероскопия билгеләнергә мөмкин;
- эчке җенес органнарында авыру юклыгына инану өчен лапароскопия билгеләнә;
- гинекологтан тыш, кыз баланы педиатр, невролог, эндокринолог күзәтә;
- кандагы микроэлементларны (аеруча магний дефицитын) ачыклау өчен биохимик анализ уздырыла.

**Табиб киңәш итә:**

- дисменореянең җиңел һәм уртача формасы булганда көненә бер-ике төймә ялкынсынуга каршы нестероидлы препаратлар билгеләнергә мөмкин. Аны күрем килергә 1-2 көн кала куллана башлыйлар;
- алар гына авыртуны басып, пациентның хәле җиңеләймәгән очракта, гормонотерапия билгеләнә;
- икенчел дисменорея күзәтелгән очракта, дәва чаралары төп чирне дәвалауга юнәлдерелә;
- дәвалауның нәтиҗәсе булмаганда, авыртуның нилектән барлыкка килүен ачыклау өчен җентекле тикшеренү таләп ителә. Әлеге чараларның барысын да фәкать табиб кына билгели.



Фото: www.pixabay.com

ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



**Кешенең организмы шулай көйләнгән инде: без тирлибез. Бу физиологик хәл. Әмма табигый булган процесс та кайчак проблемага әверелергә, кешенең тормышында уңайсызлыклар китереп чыгарырга мөмкин. Бу хакта без Татарстанның атказанган табибы, Республика клиник хастаханәсенең эндокринология бүлеге мөдире, югары категорияле табиб-эндокринолог Луиза БАРЕЕВА белән сөйләшәбез.**

# «ШЫБЫР СУГА ТӨШТЕМ»

Тирләү беренче чиратта организмны артык кайнарланудан саклау функциясен үти. Икенче үзлеге – тәнне бактерияләрдән саклау. Тирләүнең бүгенге көндә инде актуальлеген югалткан тагын бер үзлеге бар, ул – капма-каршы җенесне җәлеп итү өчен сигнал буларак та карала.

Кеше тәнендә 2,5 миллионнан артык тир бизләре бар. Һәм әлеге бизләр көненә 400 мл алып 1 литрга ка-дәр тир бүлеп чыгара. Эсседә, зур физик активлык вакытында тир бүленеп чыгу 2 литрга кадәр җитәргә мөмкин. Бу норма булып санала.

Кайчак кеше физик активлыкка һәм температурага бәйсез рәвештә дә тирләргә мөмкин. Артык нык тирләүне медицина телендә гипергидроз дип атыйлар. Гипергидроз локаль һәм диффуз була. Локаль төре – тәннең аерым бер өлешләре: култык асты, уч төбе, муен-бит тирәсе генә тирли. Бөтен тән тирләсә – диффуз төре.

Артык нык тирләүнең сәбәпләре күп булырга мөмкин. Еш кына ул организмдагы башка үзгәрешләр белән үрелеп бара. Әйтик, хәлсезлек, ябыгу... Әмма күпләр бары артык нык тирләүгә генә игътибар итә, калган үзгәрешләргә әһәмият бирми. Алары табиб белән әңгәмә барышында гына да ачыкланырга мөмкин.

Гипергидроз хатын-кызларны климакс вакытында аеруча нык борчый. Бу, билгеле, гормональ фон белән бәйле. Организмда эстроген гормоны кими, ә ФСГ гормоны арта. Безнең эндокрин система шулай көйләнгән: нәрсәдер кими икән, димәк, нәрсәдер арта. Эстроген кимегәч, тирләү дә кимергә тиеш кебек. Әмма әлеге дефицитны организм төрлечә тулыландырырга тырыша. Нәтиҗәдә терморегуляция үзәге моны тәннең артык кайнарлануы дип кабул итә һәм тир бизләренә сигнал җибәрә. Климаксны хатын-кызның актив тормышына нокта кую дип карау чоры инде күптән узды. Хәзер бу үзгәрешләрне тоткарларга яисә аны җиңелрәк кичерергә мөмкинлек бирүче чаралар бар. Табиб киңәше белән аларны кабул итү тирләүдән арынырга булыша.

**Табиб киңәше:**

- Сәламәтлегә буенча берни борчымаса да, һәркемгә биш елга бер тапкыр калкансыман биз гормоннарын тикшертеп тору кирәк. Бәби алып кайтырга ниятләгән хатын-кызлар исә аны ел да узарга тиеш.
- Сәламәт яшәү рәвешен кайгырту мөһим. Ул – эш, ял, йокы режимын дөрес көйләү, күңелле хис-тойгылар таба белү, тукlануны дөрес оештыру, хәрәкәтләнү.
- Физкультура организмны нормада тотарга булыша. Артык зур нагрузка бирмичә, бер минутка 100 адым ясап, тиз-тиз йөрүдән башларга була.
- Контраст душ та файдалы. Әмма ул эсседән шунда ук салкынга күчүне аңлатмый. Суның температурасында аерма баштарак бер генә градус та була ала.
- В төркеменә керүче $B_3$ һәм $B_5$ витаминнары кабул итәргә мөмкин.
- Атнага 2-3 тапкыр имән кайрысы төнәтмәсе салынган ванна керүнең файдасы бар.
- Диңгездә коенуның яисә диңгез тозы салынган ванналар кабул итүнең дә нәтиҗәсе яхшы.
- Кайбер матурлык салоннарында гипергидроздан ботулотоксин кадыйлар. Әмма тирләү ул икенчел генә күренеш, төп сәбәп организмдагы ниндидер җитди авыру булырга мөмкин. Шуңа да әлеге инъекцияне ясатыр алдыннан табиб-эндокринологка күренергә киңәш итәр идем.



**Бу мөһим:**

Гипергидрозның беренчел һәм икенчел формалары очрый. Беренчел форма күбесенчә нәселдән килә. Икенчел форма исә организмдагы ниндидер чатаклык билгесе буларак күзәтелә. Менә шуның өчен дә сәламәтлектә ниндидер үзгәреш булу белән, иң элек табибка күренү, тирләүнең төп сәбәбен ачыклау мөһим.

**Гипергидрозның сәбәпләре:**

- тән температурасы күтәрелү;
- стресс;
- нерв системасының дөрес эшләмәве. Аны психоген гипергидроз дип тә атыйлар;
- кайнар, ачы ризыкларга өстенлек бирү;
- йогышлы авырулар, онкологик чирләр;
- гормональ фон бозылу, калкансыман биз авырулары (гипергидрозның эндокрин төре);
- яшүсмерләрдәге гипергидрозның иң еш сәбәбе – организмдагы гормональ үзгәрешләр.



Республика клиник хастаханәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы белгече Валерия Белова ярдәмендә әзерләнде.

# «Казан-кебаб»



**Иң тәмле җәйге аш ул бакчада, учакта әзерләнә. Бөтен гаилә белән җыелып, кояшка, табигатькә, бакчадагы җиләк-җимеш уңышына соклана-соклана гөрләшеп самовар чәе эчүләр, тәм-томнан авыз итүләр – иң матур мизгелдер! «Сөембикә» күптән түгел генә Ландыш һәм Илдар Фәезовлар гаиләсендә (Ландыш та, Илдар да редакциябез өчен якын кешеләр – безнең элеккеге хезмәттәшләр) кунакта булып, учакта пешкән аш белән сыйланып кайттык. Гаилә башлыгы Илдар ФӘЕЗОВ безгә бәрән итеннән «Казан-кебаб» әзерләп күрсәтте.**
**Бу ризыкны ир-егетләр әзерләсә тәмлерәк була, ди. Әйдәгез әле, егетләр, учак ягып җибәрик тә, эшкә керешик!**

***Кирәк:***

- ит – 1,5 кг;
- бәрәңге – 1,5 кг;
- сыек май – 1 л;
- паприка, зира, кориандр, тоз, борыч;
- яшел тәмләткечләр.





Фото: Анна Арахамия

*Эш барышы:*

- Бәрәңгеләрне юып әрчибез.
- Итне юып, зур кисәкләргә бүлгәлибез.
- Учакка казан утыртабыз.
- Казан төбе кызгач, аңа май салабыз.
- Ит белән бәрәңгене майга салганчы, суын сыркытып, тастымал белән корытып алабыз.
- Кайнар майга берәмләп бәрәңгеләрне салабыз.
- Биш минуттан, кырыйлары кызарып чыккач, аларны майдан алабыз.
- Ит кисәкләрен майга салып, кызарганчы тотабыз. Кырыйлары майда кызып, кетердәвек элпә белән каплангач, итнең согы үз эчендә кала, шуңа ул сусыл булып пешә.
- Итне майдан алабыз.
- Казандагы майны 1,5 сантиметр гына калдырабыз, ә калган өлешен башка савытка бушатабыз.
- Казан төбенә янәдән бәрәңгеләрне тезәбез. Бәрәңге өстенә кызган ит кисәкләрен тезеп чыгабыз. Алар өстенә төрле тәмләткечләр, тоз-борыч сибәбез.
- Зур чынаяк белән су өстибез дә казанның өстен әйбәтләп каплыйбыз. Шул рәвешле казан талгын гына янучы учак өстендә 1,5 сәгать тора. Бу вакыт аралыгында ит белән бәрәңге авызда эрерлек йомшак һәм тәмле булып томаланып пешә.
- Әзер ризыкны зур савытка салып табынга чыгарабыз.

«Казан-кебаб» янына яшелчә, алкалап туралган суган, яшел тәмләткечләр куярга була.

Тәмле булсын!

## ЛАНДЫШ ФӘЕЗОВАДАН СЫРГАНАК МОРСЫ

Морсны туңдырылган сырганактан (облепиха) да, яңа җыелган җимешләрдән дә ясарга була.

**Моның өчен:** 100 г сырганак, 1 л кайнаган җылы су, 2 аш кашыгы бал (шикәр комы да ярый) кирәк булачак. Сырганакны савытка салып изәбез яки блендер белән пюре рәвешенә китерәбез.

Шуңа бал һәм су өстәп болгатабыз.

Тәм өчен корица, әнис, бөтнек, апельсин кисәге салып җибәрергә дә була.

Тәмле һәм витаминнарга, минералларга бай кояш төсендәге эчемлек әзер!



Фото: www.pixabay.com



**Җәй – организмны микроэлементлар һәм витаминнар белән баета торган чор. Яшелчә, җиләк-җимеш... Урманнарда әнә караҗиләк өлгергән! Уңган бакчачылар караҗиләкне хәзер үзләре дә үстерә. Әмма бакчадагы куакларда өлгергән җимешләр эрерәк булса да, аларның файдалы матдәләре азрак икән. Дөрес тукланырга яратучылар өчен караҗиләкнең файдасы һәм аннан ниләр әзерләп булуы турында Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА сөйләр.**



# Караҗиләк чоры

Караҗиләкнең файдасы турында язып кына бетерерлек түгел! Аның баш мие эшчәнлеге белән бәйле җитди авыруларга, төрле ялкынсынуларга каршы тору сәләте бар. Бу җиләк антиоксидантларга бик бай.

Кышка туңдырганда караҗиләк үзенең файдалы үзенчәлекләрен югалтмый. Шуңа күрә аны туңдыргычта ел буена җитәрлек итеп сакларга да була.

Караҗиләктә кан тамырлары системасына, йөрәккә файдалы, онкология авыруларыннан саклаучы антиоциан дигән матдә бар.

■ Организмны шлаклардан һәм токсиннардан чистарта, сәламәтлеккә уңай тәэсир итә. Караҗиләктәге антиоксидантлар тиз картаюдан саклый, хәтерне яхшырта, иммунитетны ныгыта, хатын-кызның айлык циклын һәм репродуктив системаны җайларга булыша.

■ Бу җиләктә ашкайнату системасы һәм эчәклекләр өчен файдалы булган азык җепселләре дә бик күп. Составында углевод, аксым һәм клетчаткалар дөрес нисбәттә булганга, ябыгу өчен диета тотучыларга да бик яхшы.

■ Халыкта караҗиләк күзләр өчен файдалы дигән ышану яши. Әйе, ул чыннан да компьютер каршында озак эшләгәннән соң күзләрнең аруын, ялкынсынуын бетерә. Әмма аның өчен бу җиләкне көнгә өч тапкыр 100 әр грамм ашарга кирәк.

■ Ничек кенә файдалы булмасын, караҗиләкне кулланганда уникеилле эчәктә проблемалар, аллергия һәм калкансыман биз авырулары, кан оешучанлыгы түбән булган кешеләргә сак булырга кирәк.

## ТИЗ ӘЗЕРЛӘНӘ ТОРГАН ИРТӘНГЕ АШ

***Кирәк:***

- 250 г караҗиләк, 150 г банан, 80 г солы лачавы (хлопья), 150 мл кефир, дарчин (корица), ванилин.

***Эш барышы:***

- Солы лавачына кефир салабыз.
- Шуңа банан, караҗиләк өстәп, блендерда әйләндерәбез.
- Дарчин һәм ванилин өстибез.
- Стаканга салабыз, өстен караҗиләк һәм банан кисәкләре белән бизибез.

**Караҗиләктән витаминлы смузилар:**

■ 100 г караҗиләк, бер банан, бер авокадо, аз гына су.

■ 200 г караҗиләк, 200 мл йогурт яки кефир, 2 аш кашыгы бал, 3 аш кашыгы солы лачавы, 2 аш кашыгы лимон согы.

■ 100 г караҗиләк, бер әфлисун, ярты стакан шпинат, 150 мл су.



Фото: www.pixabay.com

***Кучкар.*** Күзгә таба яңа эшкә тотыну мөмкинлеге барлыкка киләчәк. Мактаулар ишетерсез. Ә бу айда алдагы көннәрдәге тырышлыгыгызның әҗерен күрерсез.

***Үгезбозау.*** Тормышыгыз төрле вакыйгалардан кайнап торыр. Күтәрелешләр дә, азрак күңелсезлекләр дә булыр. Үзегезнең мавыгуларга бирелеп, күңел төшенкелегеннән сакланып кала алырсыз.

***Игезәкләр.*** Үзегезне ишетергә тырышыгыз. Тәвәккәл булсагыз – эштә уңышка ирешерсез. Финанс хәлегез көтмәгәндә яхшырып куяр. Китап укып, яраткан кинолар карап ял итәр өчен дә уңай вакыт.

***Кысла.*** Ялгышларны тану, гаиләдә тынычлык-татулык урнаштыру чоры. Гаепле булсагыз – гафу үтенегез, үпкәләтүчеләрне кичерегез. Тормышның ямен һәм тәмен табып, булганның кадерен белеп яшәргә өйрәнегез.

***Арыслан.*** Бу ай күңел күтәренкелеге белән узар. Финанс мәсьәләсендә хәлләрегез яхшырачак. Чыгымнар көндәлеге алып барырга өйрәнергә вакыт. Яңа эшләр башлар өчен уңай чор.

***Кыз.*** Шәхси тормышыгызга үзгәрешләр кирәк. Күбрәк аралашырга тырышыгыз. Көтмәгәндә тормышыгызга элек сезнең өчен буй җитмәс хыял булып тоелган әйберләр килеп керер.

***Үлчәү.*** Бу айда гамәлләрегезне үлчәп, дөрес нәтиҗәләр ясап яшәү әйбәт булыр. Эмоцияләрегез белән идарә итәргә тырышыгыз, түземсезләнмәгез. Кадерегез артыр, бу дөньяга үзегезнең кирәк икәнегезне аңларсыз.

***Чаян.*** Онытылган хис-тойгылар яңадан кабынырга мөмкин. Кабаттан гашыйк булырга курыкмагыз! Күз башында ялгыз Чаяннар үз парларын очратыр дип елмая йолдызлар.

***Укчы.*** Хыял диңгезендә йөзүне туктатып, эш күрсәтә башларга вакыт. Гаилә, мәхәббәт өлкәсендә уңай үзгәрешләр көтелә. Җанга рәхәтлек бирүче хисләр белән яшәрсез.

***Кәҗәмөгез.*** Сезне бу айда һөнәри өлкәдә танылу көтә. Эшегез күп һәм кызыклы булачак. Сәламәтлегегез турында онытмагыз! Якыннарыгыз һәрвакыт янәшәдә булыр.

***Сукояр.*** Яшерен талантларыгыз ачылыр! Моның өчен нәрсә эшләргә кирәклеген дә беләсез, тәвәккәлләп тотынырга гына кирәк. Бу айның энергетикасы романтикага, югары үрләргә илһамландырыр.

***Балык.*** Баштанаяк эшкә чумарсыз. Сезнең вазыйфага кермәгән эшләрне үзегезгә алмагыз. Акчага кытлык кичермәсәгез дә, кул кушырып утырмагыз. Финанс хәлегезне уңай якка үзгәртер өчен уңышлы чор.

# ВАКЫТЫГЫЗНЫ ДӨРЕС КУЛЛАНА БЕЛӘСЕЗМЕ?

«Вакыт – акча, кадерен белмәсәң кача», дигән халык сүзе бар. Һәркемгә дә тәүлеккә 24 сәгать вакыт бирелә. Кем аны ничек куллана – һәркемнең үзеннән тора. Ә сез вакытны дөрес кулланасызмы икән, әйдәгез, тикшереп карыйк әле!

**1.** Көннең беренче өлешен планлаштыруга, әзерлек этабына багышлыйм.

**2.** Үземә кушкан эшләрнең барысын да оста итеп башкаларга күчерә барам.

**3.** Эшләремне һәм максатларымны, үтәлү вакытын күрсәтеп, һәрвакыт кәгазьгә язып барам.

**4.** Нәрсәгә алынсам да, кире әйләнеп кайтмаслык итеп җиренә җиткереп башкарып чыгам.

**5.** Һәр көнне эшлисе эшләремне язып барам. Иң мөһим эшләремне беренче чиратта эшләп куярга тырышам.

**6.** Вакытны ала торган файдасыз сөйләшүләргә, телефоннан аралашуларга, юк-бар очрашуларга эш көнемне сарыф итмәскә тырышам.

**7.** Көчем җиткән эшләрне генә үземнең көн тәртибенә кертәм.

**8.** Килеп туган актуаль сорауларны хәл итәр өчен эш вакытында үземә буш вакытлар калдырам.

**9.** Көнлек планнан тайпылмаска тырышам.

**10.** Вакытымны алырга теләгән кешеләргә «юк» дип әйтә беләм.

**Җаваплар: беркайчан да – 0 балл, кайвакыт – 1 балл, бик еш – 2 балл, һәрвакыт – 3 балл.**

Ә хәзер, әйдәгез, балларны исәпләп карыйк:

**0–15** Сез үзегезнең вакытыгызны планлаштыра белмисез, шуңа күрә вакыйгалар уңаена «йөзәсез». Әгәр дә үзегез өчен беренче урында торган эшләр исемлеген төзеп, шулар буенча яшәсәгез, тормышыгызга уңай үзгәрешләр килер, күп нәрсәгә өлгерә башларсыз.

**16–20** Үзегезнең вакытыгыз белән идарә итәргә тырышасыз. Әмма, һичшиксез, уңышка ирешер өчен бу эш белән даими шөгыльләнергә, алдан план төзеп яшәргә өйрәнергә кирәк.

**21–25** Вакыт белән идарә итүнең серләрен беләсез, даими рәвештә кулланыгыз гына.

**26–30** Вакытны ничек дөрес бүләргә, аны үз файдаңа ничек кулланырга кирәклеген нәкъ сездән өйрәнергә була. Афәрин!

тест

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

PRESSA









# ЯРАТУДАН ТУГАН МАТУРЛЫК

– Җәйләрен Сарманда яшәүче Кәшифә әбием янына кайта идек. Әби инде маллар асрамый иде ул чакта. Ә бакчасы зур! Авылда беркем дә әле җиләк-җимеш үстерми. Ә аңарда әллә ниләр бар! Алмагач, кура җиләге, чия... Җиләккә якын килмибез – әби аны гел үзе генә җыя. Ә чияне безгә дә ышанып тапшыра...

«Бакчада» дигән картинасы турында сөйли Алсу: «Бу эшем – реализмнан символизмга күчүгә тагын бер адым. Бүген инде теләсә кемнең кулында гаджет – шәфәкъ, болытлар, салават күпере... кебек күренешләрне шунда ук төшерә, үзендә саклый ала, бу матурлыкны тагын рәсемдә дә күрү ихтыяҗы юк аңарда. Әмма бу күчеш бер рәссамга да җиңел генә бирелми...»

Алсу Тимергалина – сәнгать яратучылар өчен күптән билгеле исем. Аның эшләрен башка берәүнеке белән берничек тә бутап булмый: Алсуның үзе кебек үк ачык, якты төсләр (зәңгәрнең ничә төсмере бар икән аның картиналарында?!), ниндидер җиңеллек, сафлык, рәхәтлек... Һәм, әлбәттә, миллилек! Аны бу юнәлешкә алып китүдә татар матбугатының да «өлеше» зур: «Татарстан яшьләре» газетасы, «Идел», «Сөембикә», «Түгәрәк уен» журналларының... Төрле елларда бу редакцияләрдә рәссам-бизәүче булып эшләгән Алсу рухи яктан байый – татар дөньясына якыная. «Әйтик, «Түгәрәк уен»да эшләмәсәм, фольклор мотивлары белән кызыксынмас идем, этнографиягә кереп китмәс идем, – ди ул. – Милли бизәкләр мине бу кадәр үзенә тартмас иде. Аларны хәзер бөтен җирдә күрәм... Менә бу «Икебез дә матур» дигән эшем дә язылмас иде. Рәсемдәге кызлар өстендә – Урал татарлары костюмнары. Альяпкычлардагы бизәкләр чигелмәгән – тукымага тукылган. Әтием фантаст-язучы Адлер Тимергалинның туганнары шундый алъяпкычны музейга тапшырганнар иде кайчандыр. Мәктәп укучысы гына идем әле. «Миңа гына бирегез», – дип шундый сорадым... Сары төсенә кадәр хәтерлим. Тарттырылган киндер каршына утыруга күз алдымда шул алъяпкыч килде...» (Аның бу сүзләренә өстәп: «Татар дөньясыннан ерак торса, XX гасыр башы шәһәр күренешләрен сурәтләгән «Иске Казан», «Казан» кебек серияләре дә булмас иде», – диясе килә. Тын урамнар, агач йортлар... Шул картиналарга карап, иске Казан урамнарына кереп адашырга теләүчеләр бер мин генә түгелдер ул!)

Алсу – һәрвакыт яңалык эзли. Газета-журналлардан Татарстан китап нәшриятына баш рәссам булып күчә: китаплар бизи (шунда ук Шүрәлесен искә төшердегезме?!), батик ысулын өйрәнә (аның яулык-шарфлары кемнеңдер гардеробында әле дә бардыр), милли киемле курчаклар иҗат итә, рәссамнарның Казакъстанда, Төркиядә, Кипрда узган халыкара симпозиумнарына чыгып китә (андагы күргәзмәләрдә Алсу Тимергалина эшләрен очратсагыз шаккатмагыз!)... Соңгы вакытта исә ул керамика белән мавыга.

– Күптәнге теләк бу, – ди Алсу. – Ул мине гел үзенә тартып торды. Борис Шубин дигән керамист заманында Казанның төзелеш материаллары комбинатында сәнгать керамикасы цехы ачуга ирешкән иде. Аның авторлык эшләрен зур партияләрдә чыгардылар. Ә минекеләр – бердәнбер. Әзер формалар – тәлинкә, чынаяклар сатып алып, шуларны гына да бизәргә мөмкин булыр иде. Тик миңа балчык белән эшләү ошый. Аны әвәләү... Җаным, күңелем ял итә шул вакыт. Мин иҗат иткән тәлинкәләрдә – халкыбызның күңел бизәкләре. Кайсын – күчереп алам, кайсысын, шул мотивларга ияреп, үзем ясыйм. Балчыктан үзем яндырып ясаган кружкаларга да Казан күренешләре төшкән...

Үзе нәрсә ярата – шуның белән генә шөгыльләнүен яшерми ул. Ә яратудан матурлык тууы гаҗәп түгел.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА







■ Казакъ риваяте

■ Икебез дә матур

■ Бакчада

## АЛСУ ТИМЕРГАЛИНА

ТАССР

Празднование 100-летия Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

1920-2020



Лена КОЛЕСНИКОВА,
Чиләбе татар конгрессы рәисе,
Чиләбе өлкәсе Кануннар
чыгару җыелышы депутаты,
Чиләбе өлкәсенең Иҗтимагый
палата әгъзасы

Мөхтәрәм Рөстәм Нургали улы!
Кадерле милләттәшләр!
Хөрмәтле Татарстан халкы!

Татарстан Республикасы оешуга 100 ел тулу уңаеннан Чиләбе өлкәсе татар конгрессы һәм өлкәбезнең бөтен татар җәмәгатьчелеге исеменнән сезгә ихлас котлауларымны юллыйм!

Без уртак ватаныбызның бөек тарихы һәм күренекле чынбарлыгы белән чын мәгънәсендә горурланабыз. Алдынгы идеяләр, технологияләр үсеше белән беррәттән, монда гореф-гадәтләр, телебез, әдәбиятыбыз кадерләп саклана. Татарстанның иң кыйммәтле байлыгы – халкы. Республикабыз ирешкән зур казанышлар – аның күпмилләтле халкы тырышлыгы нәтиҗәсе. Лев Толстой һәм Габдулла Тукай, Федор Шаляпин һәм Салих Сәйдәшев, Максим Горький һәм Муса Җәлил, Александр Бутлеров һәм Каюм Насыйри, Владимир Ульянов һәм Мулланур Вахитов – бу исемнәр халыклар язмышының уртаклыгына иң ачык мисал.

Чиләбе өлкәсе – Татарстан Республикасының стратегик партнеры. Безнең төбәкләрнең үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерү өчен потенциалы гаять зур. Рухи, мәдәни һәм икътисади бәйләнешләребез алга таба да дәвам итәр, элемтәләр елдан-ел үсә һәм ныгый барыр дип ышанам.

Олуг Татарстаныбызга һәм аның халкына саулык, иминлек, алгарышлар һәм уңышлар телим!

